Самарские татары
Самар татарлары
ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР
№ 1 (42), ЯНВАРЬ–МАРТ, 2024
ВЫПУСКАЕТСЯ С 2012 ГОДА



ПЫЛЬ ПОВСЕДНЕВНОЙ ЖИЗНИ С ДУШ СМЫВАЯ



КЕШЕНЕҢ ҮЗКЫЙММӘТЕ АНЫҢ ЭШЕНДӘ ҺӘМ ТОРМЫШЫНДА АЧЫК КҮРЕНӘ



ИНОГДА ЧЕЛОВЕКА НАДО ПРОСТО ВЫСЛУШАТЬ, И ЕМУ СРАЗУ СТАНЕТ ЛУЧШЕ



«ЛӘЙСӘН» БАШКОРТ БИЮ АНСАМБЛЕНӘ – 20 ЯШЬ!



Дания Тулова:

# «Юмартлыгының чиге юк, риясыз күңеленә барысы да сыя...»

6+

# ВАША РЕКЛАМА
# В ТАТАРСКИХ СМИ РЕГИОНА

По вопросам размещения обращаться по телефону 8-917-104-44-45

информационный
медиапортал

Самарские татары
Самар татарлары

samtatnews.ru

Самарские татарские новости

**Ждем ваших предложений по созданию самарского татарского интернет-телевидения.**

**ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР**

**ПРИОБРЕСТИ НОМЕРА ЖУРНАЛА «САМАР ТАТАРЛАРЫ» МОЖНО ПО СЛЕДУЮЩИМ АДРЕСАМ:**
Самара, ул. Революционная, д. 142
(магазин «Кулинария на Революционной»),
пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),
в Соборной мечети Самары.

Телефон для связи 8-917-104-44-45 **Сайфиев ДаниярИрекович**

Адреса электронной почты – **Samartatarlary@bk.ru, ilyas65@mail.ru**

Самара өлкәсе татарларының
иҗтимагый-сәяси газетасына — 33 яшь!

Заманалар үзгәрә –
Бердәмлек
газетасы кала

- 33 ел буе газета өйләрегезгә котлаулар, мәкаләләр, очерклар, яңалыклар китереп тора
- "Бердәмлек"геройлары – сез үзегез, күршеләрегез һәм якташларыгыз!
- "Бердәмлек"не язучылар – сез үзегез, күршеләрегез һәм якташларыгыз!
- "Бердәмлек"– Самара татарлары арасында иң популяр газета!
- "Бердәмлек"кә ел әйләнәсендә почта бүлекләре, "Россия почтасы" сайтындагы онлайн-язылу һәм "Урал-пресс Поволжья" җәмгыяте аша язылырга була

Индексы П4778

КАЛЕНДАРЬ
ПАМЯТНЫХ ДАТ И СОБЫТИЙ
2024

**ЕЖЕГОДНЫЙ ТАТАРСКИЙ КАЛЕНДАРЬ**

рассказывает о значимых исторических датах в жизни татар Самары и России

# Хөрмәтле дуслар!

Күркәм гадәт буенча, “Самар татарлары” журналының язгы санын без хатын-кызларыбызга багышлыйбыз. Һәм бу очраклы түгел, яз – табигатьнең ямьле чоры, күңелнең уяну чагы һәм гүзәл затларыбыз үз бәйрәмнәрен билгеләп үткән вакыт бит ул.

Тормышта үзләреннән соң якты эз калдырган һәм бүгенге көндә төрле өлкәләрдә уңышлы эш алып барган туташ-ханымнар турындагы мәкаләләр укучыларыбыз күңеленә хуш килер, дип уйлыйм. Шатлыкка, татар хатын-кызлары арасында шундый лаеклы геройларыбыз күп – укытучылар, эшкуарлар, күпбалалы аналар, кайгыртучан әбиләр, оста җитәкчеләр, җәмәгать эшлеклеләре... Аларның барысы да мактауга һәм соклануга лаек.

Әлбәттә инде, басмабызда башка әһәмиятле темаларга да лаеклы урын бирелде. Менә инде өченче ел махсус хәрби операция дәвам итә. Күп ир-егетләребез, кулларына корал тотып, илебез ихтыяҗларын яклыйлар, күпләр исә хәрбиләргә һәм аларның гаиләләренә гуманитар ярдәм күрсәтүгә үз өлешләрен кертәләр.

Әлеге санда, мәсәлән, махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен гуманитар ярдәм җыеп җибәрүне оештыручы “Ихсан” яшь волонтерлар берләшмәсе һәм аның җитәкчесе Равил Фазлетдинов, берничә тапкыр Донбасста командировкада булып кайткан табиб Эдуард Шәкүров турында укый аласыз. Гомумән, арабызда мондый кешеләр аз түгел. Киләчәк саннарыбызда шушындый шәхесләр турында мәкаләләр урнаштыруны дәвам итәчәкбез.

Гадәттәгечә, материалларның бер өлеше халкыбыз тарихына, Самар татарлары тормышындагы әһәмиятле вакыйгаларга багышланды.

Барлык язмаларны да кызыксынып укырсыз, дип ышанам.

Безнең белән бергә булыгыз!

# Дорогие друзья!

По сложившейся доброй традиции каждый весенний номер журнала «Самар татарлары» мы посвящаем нашим женщинам. И это не случайно, ведь весна для многих из нас ассоциируется с пробуждением жизни, красотой и, конечно же, праздником 8 Марта. Материалы о наших прекрасных соплеменницах, оставивших свой яркий след, и тех, кто сегодня успешно проявляет себя в разных сферах жизни, уверен, не оставят наших читателей равнодушными. И хорошо, что героев для таких публикаций среди татарских женщин немало. Это – учителя и предприниматели, многодетные мамы и заботливые бабушки, ответственые руководители и общественные деятели... Все они заслуживают самого глубокого уважения и признательности. Но этот номер журнала не только о них.

Третий год продолжается специальная военная операция. Многие наши земляки отстаивают интересы страны с оружием в руках, и также многие оказывают гуманирную помощь нашим героям и их семьям. В этом выпуске мы вам расскажем о молодежном волонтерском движении «Ихсан» и его лидере Равиле Фазлутдинове, которые занимаются сбором и доставкой гуманитарных грузов в зону проведения СВО. Здесь же вы найдете публикацию о замечательном враче Эдуарде Шакурове, за плечами которого несколько командировок в Донбасс. Таких людей среди нас немало. Уверен, что все они рано или поздно займут свое достойное место на страницах журнала.

Как всегда, часть наших публикаций посвящена истории нашего татарского народа и, конечно же, наиболее ярким событиям в жизни самарских татар. Искренне надеюсь, что все публикации найдут живой отклик у наших читателей. Будьте с нами!



**Данияр СӘЙФИЕВ,**
*“Самар татарлары” журналы мөхәррире*


РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ

**Шакуров Ильяс Гумерович** – президент СОТО «Туган тел»; председатель правления НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», член Общественной палаты г.о. Самара

**Хазиев Артур Ахатович** – председатель Центра Стратегических Исследований «Платформа XXI»

**Сайфиев Данияр Ирекович** – гл. редактор журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»)

**Нуретдинова Римма Равильевна** – главный редактор сайта samtatnews.ru

**Вакказов Расих Ахметшамилович** имам-хатыб мечети «Булгарское наследие»

**Ибятова Ляйсян Замиловна** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Надиров Азат Камилович** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Сафин Иршат Халилович** – старший имам-хатыб Соборной мечети г. Самары

**Хузин Ривгат Туктарович** – председатель комиссии Общественного совета при ГУ МВД России по Самарской области

**Мифтахов Искандер Фуадович** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Рамазанова Гюзяль Ибрагимовна** – директор СОТО «Туган тел»

**Юсупов Рамиль Закряриевич** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Юсупов Фагим Ханифович** – член Совета СОТО «Туган тел»

РЕДАКЦИОННАЯ КОЛЛЕГИЯ

**Биктаев Наиль Данисович**
**Варфоломеева Эльмира Мугаммаровна**
**Галимов Шамиль Хайдарович**
**Мифтахов Искандер Фуадович**
**Файзуллов Рустам Ильясович**
**Салахова Лилия Акрямовна**
**Шириязданов Фарид Хамитович**
**Шарипов Руслан Кабирович**

# Содержание:

Областной ифтар объединил народы ....7
Уртак кайгы берләштерә ....9
Җир сату - ул туган илне сату ....11
Яшьлеккә кайткандай ....15
Оешманың данлы еллары ....18
Ерактан яхшырак күренә ....23
Кешенең үзкыйммәте аның эшендә һәм тормышында ачык күренә ....25
Иногда человека надо просто выслушать, и ему сразу станет лучше ....29
Юмартлыгының чиге юк, риясыз күңеленә барысы да сыя... ....34
Денис авылы тарихы ....52
Веками хранимые названия ....56
Огромны были ее стремленья ....58
Пыль повседневной жизни с душ смывая ....69
Не сетуя на превратности судьбы ....78
Фәрид Шириязданов: “Туган авылым табигате – мине иҗатка рухландыручы илһам чыганагы” ....89
География Салькина ....93
Открытие Аркаима – это чудо ....106
«Ләйсән» башкорт бию ансамбленә – 20 яшь! ....108
Хәситә эзләре буйлап ....111
Певец идеалов и нравственности ....115
Верен своим жизненным принципам ....117
Счастливое число в этническом названии ....118
Культура оленеводства на Севере и в Самаре ....119
Пусть сериал «Слово пацана. Кровь на асфальте» станет не руководством к действию, а своеобразной прививкой... ....121



44 МИННИСА САДЫКОВА: «ЛЮБУЮ РАБОТУ НУЖНО ДЕЛАТЬ С ЛЮБОВЬЮ»



40 «НИКАХ КИЛЕШҮЕ ГАИЛӘ ИМИНЛЕГЕН САКЛАРГА ЯРДӘМ ИТӘЧӘК»



49 РАДУЖНАЯ ФОРЕЛЬ РОДОМ ИЗ НОВОГО БУЯНА



96 АК ӘБИ – АВЫЛ БИЗӘГЕ

## Уважаемые друзья!

***Приобрести журнал «Самар татарлары» можно по следующим адресам:***

- **Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»)**
- **Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),**
- **Самара, ул. Стара Загора, 54 (в магазине внутри Соборной мечети).**

**Стоимость текущего номера с доставкой – 300 рублей, стоимость номеров за 2023 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей.**

**Доставка журналов по Самаре – тел.: 8-937-64-044-77.**

Издатель «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», адрес: 443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28

**Главный редактор:** САЙФИЕВ Данияр Ирекович
**Корреспонденты:** Миляуша ГАЗИМОВА, Фарид ШИРИЯЗДАНОВ, Шамиль ГАЛИМОВ, Рашид ШАКИРОВ, Нурсина ХАКИМОВА
**Дизайн-макет, верстка:** Александр ГОРБАЧЕВ, Юрий ШВЕЦ
**Фото:** Миляуша ГАЗИМОВА, Аняс МИНГАЛЕЕВ
**Корректоры:** Миляуша ГАЗИМОВА, Вадим ОЛЕНИН

**Адрес редакции:**
443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28
**Телефон редакции:** 8-917-104-44-45
**Электронная почта:** samartatarlary@bk.ru
**www.samtatnews.ru**

**Отпечатано в ООО «СЛОВО»,**
443070, Самарская область, г. Самара, ул. Песчаная, 1, офис 310, тел. (846) 267-36-82

**Журнал «Самар татарлары»** («Самарские татары»), № 5 (42), январь–март, 2024 г.
**Учредитель:** «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области»
Журнал зарегистрирован Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Свидетельство о регистрации СМИ: ПИ №ТУ63 – 00628 от 15.10.2013 г.
Дата выхода 8 апреля 2024 г.
Тираж 1000 экз. Цена свободная



# РЕКОРДНЫЙ РЕЗУЛЬТАТ И ИСТОРИЧЕСКАЯ ЯВКА

***www.kp.ru***

По итогам обработки 100% бюллетеней Владимир Путин победил на выборах президента России. Согласно данным ЦИК РФ, действующий глава государства набрал 87,28%. На втором месте оказался представитель КПРФ Николай Харитонов – 4,31%. Следом идут кандидат от «Новых людей» Владислав Даванков (3,85%) и лидер ЛДПР Леонид Слуцкий (3,20%).

Явка на выборах президента России оказалась рекордной – 77,44%. Больше 87 млн избирателей отдали свой голос.

Выборы президента России в 2024 году стали уникальными не только из-за формата проведения. Впервые в них участвуют четырех регионах России – Донецкая и Луганская народные республики, Херсонская и Запорожские области. Несмотря на то что власти Украины угрожали местным жителям, они активно шли делать свой выбор, и явка в этих регионах оказалась выше общей.

Херсонская область – 83,87%
Луганская народная республика – 87,12%
Донецкая народная республика – 88,17%
Запорожская область – 85,02%

ВЫБОРЫ ПРЕЗИДЕНТА РОССИИ
15–17 МАРТА 2024

## 123 МЛН РУБЛЕЙ НА ВОЗРОЖДЕНИЕ «АНА ТЕЛЕ»

В Татарстане на создание и техническое сопровождение информационной образовательной системы дистанционного обучения татарскому языку «Ана теле» будет выделено 123,3 млн рублей. Об этом сообщает пресс-служба Минфина РТ.

***tatar-inform.ru***



Средства из республиканского бюджета будут выделены Министерству образования и науки РТ в текущем финансовом году, отмечают в ведомстве.

В начале июня прошлого года бесплатная онлайн-школа татарского языка «Ана теле» сообщила о закрытии. Причиной было названо то, что иностранная компания EF Education First, совместно с которой был реализован образовательный проект, приняла решение об уходе с российского рынка.

Позднее, в августе, глава Минобрнауки РТ Ильсур Хадиуллин заявил, что онлайн-школа изучения татарского языка «Ана теле» будет спасена от закрытия благодаря переносу на отечественную платформу.

Для переноса контента тогда выбрали российскую онлайн-платформу JetClass от образовательной компании DenizSchool. Основным оператором и координатором проекта назначили Министерство образования и науки РТ. Тогда, в августе, предполагалось, что на перенос контента понадобится шесть или семь месяцев.

Онлайн-школа татарского языка «Ана теле» работала с 2013 года. Она была создана по поручению Раиса Татарстана Рустама Минниханова. Образовательный курс включал девять уровней сложности.

## ТАТАРСТАНСКИЙ ФИЛЬМ «АЛЬМАНДАР» СТАЛ ПОБЕДИТЕЛЕМ IV МОСКОВСКОГО ДЕТСКОГО КИНОФЕСТИВАЛЯ

Картина «Альмандар», созданная объединением «Татармультфильм» и снятая по мотивам произведения татарского драматурга Туфана Миннуллина «Альмандар из Альдермыша», стала лучшим анимационным фильмом IV Московского международного детского кинофестиваля.

***tatar-inform.ru***



«Мы были уверены, что наш фильм про семейные ценности, любовь к жизни, приправленные толикой татарской хитрости, найдёт отклик и у российского зрителя. Мы искренне благодарны всем, кто помог нам реализовать этот проект», – рассказал директор студии «Татармультфильм», продюсер фильма Азат Ганиев.

Фильм снят при поддержке Раиса РТ Рустама Минниханова, комиссии при Раисе РТ по вопросам сохранения, развития татарского языка и родных языков представителей народов, проживающих на территории республики, и компании «Татнефть».

В этом году на кинофестивале представили 78 работ из 18 стран. Участниками могли стать картины, снятые взрослыми для детской аудитории, а также фильмы, которые снимают дети и подростки.

Гран-при ушел фильму «Класс искусств» Чжана Чжунхуа (Китай), лучшим полнометражным детским фильмом признана работа Филиппа Дмитриева «Гостья из космоса» (Россия), лучшим короткометражным детским фильмом – лента Джульет Бушени «Ативио» (Франция).

## СКАЖИ ЭТО ПО-БАШКИРСКИ!



В Доме дружбы народов Самарской области состоялось мероприятие в рамках Международного дня родного языка, посвященное башкирскому языковеду, основоположнику башкирского языкознания Г.Я. Давлетшину – уроженцу деревни Таш-Кустьяново Большеглушицкого района Самарской области.

*Samddn.ru*

Организаторами выступили Общественная организация «Курултай (конгресс) башкир г. Самары» при поддержке Правительства Самарской области и Дома дружбы народов Самарской области.

Языковед Габбас Давлетшин преподавал в Башкирском государственном педагогическом институте имени К.А. Тимирязева. В учебнике башкирского языка он впервые использовал кириллицу, а не смесь арабских символов и латиницы, которой до этого писали башкиры. Племянница языковеда Маргуба Давлетшина смогла собрать его рукописи и издать многотомный труд.

На мероприятие приехали родственники языковеда Гульниса Ильясовна Габитова и Самат Ахатович Давлетшин, которые участвовали в съемках фильма.

Участники показали всю красоту и колорит башкирского языка и культуры. Башкирский ансамбль танца «Ляйсан» (руководитель Рауда Шаймарданова) и фольклорный детский ансамбль «Заман» (руководитель Мидхат Аминов) представили яркие и красочные выступления.

## В КАЗАНИ НАШЛИ КИНОСЦЕНАРИЙ АВТОРСТВА АМИРХАНА ЕНИКИ

Документ обнародован по инициативе литературоведа и педагога Милеуши Хабутдиновой.

*milliard.tatar*

В Доме татарской книги состоялась дискуссия о наследии Амирхана Еники, 115-летие которого отмечается в 2024 году. На встрече с участием студентов, журналистов и писателей обсуждались вопросы интерпретаций наследия потомка татарских мурз и его нереализованные проекты. Воспоминаниями о писателе поделились нынешние аксакалы татарской литературы Рабит Батулла и Марсель Галиев, ставился вопрос об отсутствии государственной поддержки работы над генеалогическим древом писателя.

Под занавес дискуссии была представлена машинописная рукопись киносценария «Бер генә сәгатькә» («На один час») авторства самого Амирхана Еники. Она хранится в фондах Национального музея РТ – автор лично передал ее в 1983 году.

Документ обнаружила в онлайн-перечне музейных экспонатов литературовед Милеуша Хабутдинова, когда искала материалы для своей статьи по поводу премьеры фильма по мотивам трех новелл Еники «823-й километр». На своей странице в соцсети она выступила с резкой критикой в адрес создателей фильма, обвинив их в том, что не удосужились более тщательно изучить творчество писателя и этот сценарий. «Боль в душе не затихает… Стыдно мне за деятелей нашей культуры…» – написала она и предложила изучить сценарий самого автора. «Есть же творческие деятели и артисты, готовые с душой снимать татарские фильмы! Почему раз за разом гранты выигрывают те, кто не желает изучать родную культуру, художественный мир писателя. Почему мы не служим, а пользуемся татарской культурой для наживы, самости и др.?» – сказала она.

Музей предоставил артефакт для участников дискуссии. Еще предстоит выяснить, при каких обстоятельствах и в каком году написан этот сценарий. Но известно, что сценарий автор писал для татарского телевидения и собирался предложить его режиссеру Ахтаму Зарипову.

Документ содержит более 23 страницы и рукописные правки. «Были ли это правки самого автора, лично ли он передал это в фонды музея, нам предстоит еще выяснить», – сказала Хабутдинова.

## КАЗАНДА 6 ТОМЛЫ «ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ» ТӘКЪДИР ИТЕЛДЕ

Сүзлек Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә лаек булган.

***Татарстан Фәннәр академиясе вице-президенты, филология фәннәре докторы Айнур Тимерханов:***

«Сүзлек киң даирә укучылар өчен исәпләнгән. Аңлатмалы сүзлек – иң еш мөрәҗәгать ителә торган фәнни чыганакларның берсе. Бу хезмәт халык өчен гаять дәрәҗәдә файдалы эшнең нәтиҗәсе булып тора. Татарның мондый сүзлеге, гасырларга сузылган сүзлек төзү тарихы бар. Бүгенге уңышыбыз – ул зур мирасны өйрәнү нәтиҗәсе. Аңлатмалы сүзлекне туган телебезгә һәйкәл дисәк тә була. Бу эш безнең 20 ел элек башланып киткән иде. Сүзлекне төзүдә, аны басмаханәгә әзерләүдә 15 белгеч катнашты».

Татар теленең 6 томлы аңлатмалы сүзлегендә 80 меңгә якын сүз һәм фразеологизм кергәне билгеле. Татарстан Фәннәр академиясе сайтының электрон китапханә өлешендә электрон варианты да бар. Шул ук сайтта электрон сүзлекләр фонды урнаштырылган. Димәк, биредә башка сүзлекләр белән дә танышу, аларны куллану мөмкинлеге бар.

«Әгәр, 21 гасыр сүзлекләре турында бәян итсәк, 2000нче еллардан исәпләсәк, институт хезмәткәрләре авторлыгында яки катнашлыгы белән 50 артык хезмәт бастырылган. Шуларның күпчелеге Татарстанда дәүләт телләрен һәм башка телләрне өйрәнү һәм үстерү дәүләт программасы кысаларында. Әлеге сүзлек тә шушы программа белән нәшер ителде. Соңгы елларда бездә шулай ук терминологик сүзлекләр булдыру дәвам итә» ***дип өстәде Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Ринат Сәфәров.***



# УКРЕПЛЯТЬ И РАЗВИВАТЬ

Продолжается проведение выездных совещаний Региональной общественной организации «Союз народов Самарской области», в которых принимают участие представители органов власти, национально-культурных объединений и религиозных организаций.

*samddn.ru*

5 марта очередное совещание состоялось в Доме дружбы народов Самарской области. Председатель Союза народов Самарской области, член Общественной палаты Самарской области Ростислав Ерастович Хугаев поблагодарил участников совещания за огромный вклад, внесенный в укрепление межнациональной дружбы народов Самарского региона, сохранение традиционных духовно-нравственных ценностей и национальных традиций.

Особое внимание на совещании было уделено вопросам сохранения культурного наследия, духовных ценностей, укреплению внутринациональных и межнациональных связей, проведению воспитательной работы с молодым поколением. Затронули вопросы проведения патриотических мероприятий, а также гуманитарной помощи бойцам СВО.

Отдельно обсуждался вопрос профилактики межнациональных конфликтов на территории Самарской области.



Участники совещания отметили, что в Год семьи приоритетными направлениями в деятельности общественных организаций станут мероприятия по сохранению традиционных ценностей, преемственности поколений, сохранению семейных традиций, культуры и языков народов Самарской области.



# В МОСКВЕ ПРОШЕЛ МОЛОДЕЖНЫЙ ИФТАР

Молодежный ифтар, организованный молодежным движением Автономии татар Москвы, молодежным сообществом «Яшьләр» при содействии Совета молодежи при Полпредстве РТ, прошел в Татарском культурном центре.

*avtonomiya.tatar*

Гости вечера окунулись в атмосферу мусульманского праздника, который длится весь месяц мусульманского поста Рамадан и сопровождается различными видами общественной активности, когда мусульмане собираются вместе, чтобы в теплой дружеской атмосфере заняться духовным самосовершенствованием.

Перед началом мероприятия собравшихся приветствовали первый заместитель полпреда РТ Эмиль Файзуллин и глава Автономии татар Москвы Фарит Фарисов.

В ТКЦ была подготовлена специальная программа, включавшая духовное наставление Асхата хазрата Гиматдинова, лекцию об истории татарской общины Москвы историка Марата Сафарова, выступления артистов и викторину на знание основ ислама. Ее победители получили призы, а все присутствующие – заряд душевной бодрости и чувства духовного единения.




# САМАРСКИЕ УЧЕНЫЕ ПРИДУМАЛИ НОВЫЙ СПОСОБ ЛЕЧЕНИЯ РАКА

В Самаре разработали уникальный метод лечения онкологических заболеваний. За основу терапии взяли трансплантацию натуральных клеток-киллеров, также известных как NK-клетки, полученных из пуповинной крови.

*www.63.ru*

Новый метод опробовали в клиниках СамГМУ для лечения множественной миеломы (злокачественной опухоли кроветворной и лимфоидной тканей). Это заболевание прогрессирует именно из-за дисфункции естественных клеток-киллеров.

– NK быстро уничтожают инфицированные клетки, а также принимают важное участие в работе противоопухолевого иммунитета. Кроме того, NK практически не оказывают токсического действия на нормальные клетки, что снижает вероятность побочных эффектов лечения. Иммунотерапия на основе NK-клеток, полученных из пуповинной крови, позволяет активировать естественные механизмы иммунного ответа и уничтожения опухолевых клеток, – рассказал профессор Игорь Давыдкин.

Ученые уже провели исследования на 10 пациентах. У 8 добровольцев выявили положительный ответ на терапию. У 2 пациентов зафиксировали слабый ответ, что может указывать на более сложный ход заболевания.

Сейчас в клиниках СамГМУ разрабатывают документацию, чтобы включить новый метод в перечень своих медицинских услуг.

# В РИМЕ ОТКРЫЛСЯ VI МЕЖДУНАРОДНЫЙ КУЛЬТУРНЫЙ ПРОЕКТ «НУРЕЕВСКИЕ СЕЗОНЫ»

14 марта в Русском доме в Риме открылся VI Международный культурный проект «Нуреевские сезоны». Он приурочен к 86-летию со дня рождения артиста и хореографа Рудольфа Нуреева, который весь мир отмечает 17 марта.



*tatar-congress.org*

Проект проводится совместными усилиями ООО «Компания Свой почерк», Ассоциацией культуры «Татары в Италии» и Русского дома в Риме при поддержке Всемирного конгресса татар.

Русский дом в Риме – место притяжения широкой общественности Италии. «Нуреевские сезоны» не стали исключением. На открытии зал был полон зрителей. Дарья Пушкова, директор Русского дома в Риме, подчеркнула, что у Нуреева с Италией – помимо профессиональной – была глубокая эмоциональная связь, поэтому и документальный фильм, снятый кинокомпанией «Свой почерк», «Рудольф Нуреев. Нездешний остров» получился очень теплым и искренним. «Нуреев здесь еще жив, благодаря ярким воспоминаниям о нем друзей, коллег, учеников и всех, кто имел возможность прикоснуться к его Вселенной. Именно этим можно объяснить восторг итальянской публики, пришедшей на премьеру фильма в Русский дом в Риме. И эта связь, основывающаяся на безмерной любви к русскому балету, воплощением которого стал великий танцовщик, в Италии, по-прежнему очень сильна».

От имени татар, проживающих в Италии, Международный фестиваль «Нуреевские сезоны» приветствовали председатель Ассоциации культуры «Татары в Италии» Зугра Мажитова и поэтесса Алия Султан, которая прочитала стихотворение, посвященное Рудольфу Нурееву, собственного сочинения.

# В ТАТАРСТАНЕ ВЫДЕЛИЛИ ПОЧТИ 2,8 МЛН РУБЛЕЙ НА ОБУЧЕНИЕ ДЕТЕЙ СБОРКЕ И УПРАВЛЕНИЮ БПЛА

Республика Татарстан выделила 2 млн 788,47 тыс. рублей на реализацию пилотного проекта по обучению детей сборке и пилотированию беспилотных летательных аппаратов.



*tatar-inform.ru*

Средства, выделенные из республиканского бюджета, пойдут на обеспечение расходов по созданию необходимой научно-образовательной и инновационной инфраструктуры. Проект реализуется на базе Икшурминской кадетской школы-интерната имени К.С. Байкиева.

Ранее стало известно, что на оборудование для обучения сборке БПЛА в школах в Татарстане собираются потратить по национальному проекту «Беспилотные авиационные системы» более 244,1 млн рублей федеральных и свыше 57,2 млн рублей региональных средств. В октябре прошлого года в Татарстане была создана Правительственная межведомственная комиссия по реализации национального проекта «Беспилотные авиационные системы». До этого, в начале августа, республика подала заявку на создание научно-производственного центра беспилотников. Президент РФ Владимир Путин в начале сентября заявил, что уверен – в регионе появятся коптер-парки.

# В КРАСНОЯРСКЕ ПРОШЕЛ «МИЛЛӘТ ҖЫЕНЫ»

В краевом Доме дружбы народов Красноярского края «Родина» прошел форум «Красноярск крае татарлары “Милләт җыены” – “Национальное собрание” татар Красноярского края».

*tatar-congress.org*

В работе Форума приняли участие представители 27 городов и муниципальных районов края. Участников «Милләт Җыены» тепло поздравил Губернатор Красноярского края М.М. Котюков. С приветственным письмом губернатора края и добрыми пожеланиями выступили начальник Управления по связи с общественностью Губернатора края Р.Г. Баринов и муфтий Красноярского Г.Т. Фаткуллин. Р.Г. Баринов также вручил благодарственные письма губернатора Красноярского края, которыми были награждены шесть татарских активистов.

Участники заслушали доклад о работе и планах за прошедшие семь лет и об основных направлениях деятельности татарского актива на предстоящие пять лет. Пленарному заседанию предшествовала работа круглых столов.

Представители городов и муниципальных районов с компактным проживанием татар также рассказали о своей работе.

Участники Собрания приняли резолюцию, в которой призвали красноярцев принять активное участие в всенародных президентских выборах и избрать достойного лидера страны.

Завершилось мероприятие концертной программой от творческих коллективов и исполнителей.





# ОБЛАСТНОЙ ИФТАР ОБЪЕДИНИЛ НАРОДЫ

***20 марта на стадионе «Самара Солидарность Арена» впервые в нашем регионе прошел областной ифтар-меджлис.***

***Данияр Сайфиев***

Забегая вперед, скажу, что первый блин, как это часто бывает, не вышел комом. Даже, наоборот, своей организацией и наполнением он сумел многих удивить и порадовать, а также еще раз подтвердить, что самарские мусульмане умеют достойно проводить масштабные мероприятия. Для этого достаточно просто объединиться и вместе делать общее дело. Тем более, когда речь заходит о богоугодных мероприятиях. Будь то детские праздники, Ураза или Курбан-байрам, которые ежегодно проводятся на очень высоком уровне, сборы помощи нашим военнослужащим в зоне СВО или, как сегодня – проведение областного ифтара, собравшего почти полторы тысячи гостей. Ведь не случайно основной целью этого мероприятия было показать единение народов, говорящих на разных языках, но скрепленных мусульманской верой, основанной на общечеловеческих ценностях. И эти идеи в сегодняшних непростых реалиях востребованы и актуальны, как никогда ранее. Наверное, в том числе и поэтому прийти на ифтар-меджлис и поздравить мусульман нашего региона с наступлением Священного месяца Рамадан посчитали своим долгом губернатор Самарской области Дмитрий Азаров и руководитель Администрации губернатора Самарской области Дмитрий Холин, недавно вернувшийся из зоны СВО.

– *В истории Самарской области такое мероприятие Региональным духовным управлением мусульман проводится впервые,* – обратился к собравшимся Дмитрий Азаров. – *Важно, когда люди из разных уголков Самарской области собираются вместе для того, чтобы поддержать друг друга, объединить усилия, подумать о самых главных делах, свершениях, обратиться к Всевышнему. Я здесь, чтобы выразить вам свое уважение и благодарность за то, что вы проявили такое же единение во время выборов президента, за вашу гражданскую позицию, патриотизм, помощь нашим защитникам и их семьям, за ваш вклад в нашу общую победу. Особое спасибо муфтию Талипу хазрату за проявленную активность и за те*



*нужные слова, которые он сумел найти, чтобы убедить людей прийти проголосовать, поддержать нашу страну в это непростое время. В том, как состоялись выборы и какую поддержку на них в Самарском регионе получил наш национальный лидер и верховный главнокомандующий Владимир Владимирович Путин, – это наш общий вклад,* – подчеркнул губернатор.

Глава региона объявил, что председатель РДУМСО Талип Яруллин за заслуги в сохранении и развитии духовных традиций, укрепление дружбы между народами






Указом президента РФ награжден медалью ордена «За заслуги перед Отечеством» II степени. Муфтию губернатор вручил копию этого Указа, отметив, что сама награда будет вручена до конца этого месяца. Также Дмитрий Азаров также вручил благодарственные письма губернатора людям, которые внесли наибольший вклад в организацию и проведение выборов.

В ответном слове Талип хазрат поблагодарил губернатора за теплые поздравления и подчеркнул важность сохранения традиционных духовных ценностей.

*– Сегодня представители разных народов собрались здесь, чтобы совершить разговение и вместе порадоваться. Я благодарю всех тех, кто принимал участие в проведении этого праздника, и гостей. Радует, что в наших мусульманских семьях основы традиционного ислама передаются от взрослых детям, что наши семьи многодетные и что воспитание в них основывается на уважении своей духовной культуры, сохранении национальных традиций и любви к своей стране. Сегодня наши братья вместе с представителями других народов и вероисповеданий отстаивают интересы нашей страны в зоне проведения СВО. Хочу сказать огромное спасибо им и их родителям, которые сумели привить им чувство ответственности за судьбу своей страны,* – отметил Талип Яруллин.





Что-что, а награждений в этот день было много. Благодарственные письма губернатора Самарской области были вручены многодетным активистам самарской мусульманской общины. Благодарственные письма Совета Федерации Российской Федерации за сохранение национальных традиций, укрепление межнационального и межконфессионального согласия в Самарской области, гуманитарную помощь военнослужащим были вручены президенту Самарского областного татарского общества «Туган тел» Ильясу Шакурову и предпринимателю Арслану Байбулатову.

Мусульманским активистам, принявшим участие в организации и проведении первого областного ифтара вручались награды Центрального духовного управления мусульман РФ и Регионального духовного управления мусульман. И о них нужно сказать отдельно. Основными организаторами этого праздника выступили волонтеры мусульманского молодежного объединения «Ихсан» под руководством Равиля Фазлетдинова. Участники этой группы уже второй год организовывают и проводят выездные ифтары в татарских селах нашей области, участвуют в сборах и отправке гуманитарных грузов в зону проведения специальной военной операции и многое другое. И когда они обратились к муфтию Талипу хазрату с предложением провести ифтар областного уровня, сомнений в том, что это у них получится, не было. За достаточно короткое время ребятам удалось решить многочисленные организационные вопросы, разработать сценарий, пригласить артистов и ведущего, дополнительно привлечь волонтеров. В итоге получился яркий и содержательный праздник с конкурсами и викторинами, исполнением мунаджатов (духовных песнопений) и, конечно же, вкусным угощением.



# УРТАК КАЙГЫ БЕРЛӘШТЕРӘ

***Минә инде ике елдан артык махсус хәрби операция темасы барыбыз өчен дә иң актуаль, иң борчыган тема булып тора. Украинада ыгы-зыгы башлануга, бөтен илебез халкы, берләшеп, көч-куәте җиткән кадәр илебез сакчыларына ярдәм итә башлады. Россия буйлап меңләгән волонтер оешмалары барлыкка килде. Самар татарлары да әлеге уртак бәладән читтә калмады, билгеле. Мәкаләмдә сүз киң күңелле, мәрхәмәтле актив яшьләребез, Региональ Диния нәзарәте каршында эшләп килүче «Ихсан» волонтерлар берләшмәсе турында барачак. Әлеге изге күңелле милләттәшләребез бик тыйнак булганлыктан, үзләре һәм башкарган эшләре турында сөйләргә яратмыйлар. Ә, алар кебек, башкалар кайгысына битараф булмаган кешеләр турында өлкә халкы белергә, алардан үрнәк алырга һәм шундыйларга тиңләшергә тиеш, дип уйлыйм.***

***Эльмира Сәйфуллина***



Самар шәһәр округының Киров районы депутатлар Советы депутаты Равил Рәифович Фазлетдинов җитәкчелегендәге волонтерлар махсус хәрби операция башланганнан бирле Донецк, Луганск Халык Республикаларында һәм Херсон өлкәсендә хезмәт итүче ир-егетләр өчен гуманитар ярдәм җыеп җибәрүне оештыралар, йөкне билгеләнгән урынга кадәр Равил һәрвакыт үзе озата бара, барлык посылкаларны үзе тапшыра, шул ук вакытта хәрбиләрнең проблемалары, аларга беренче чиратта нәрсә кирәклеге турында шәхсән белешә.

– Бу ел башында чираттагы гуманитар командировкага җыенганда 2023 елны каршы алган төндә Макеевкада һәлак булган мөселман хәрбиләр истәлегенә обелиск кую идеясе туды. Бу хакта Самарның «Нур» мәдрәсәсе мөгаллиме Ринат хәзрәт Ногманов белән уртаклаштым. Ул да, Самар өлкәсе мөселманнарының Региональ диния нәзарәте рәисе, мөфти Талип хәзрәт Яруллин да ниятемне хупладылар. Шуннан мин вайбердагы «Ихсан» төркеменә шушы тәкъдимемне яздым. Аллаһы ярдәме белән, бу игелеклե эштә булышырга теләүчеләр табылып, тиз арада



кирәкле сумма да җыелды. Танышлар аша белешеп, тимердән постамент ясаттык. Ә менә граниттан җитештерелгән мемориаль ташка язу төшерүчене табуы кыенрак булды. Бу эшкә шушы фаҗигадә якын кешесен югалткан рус егете алынды һәм, бөтен эшен читкә этәреп, аны өч көндә башкарып чыкты. Ташка: «В память павшим воинам 01.01.2023 года. Ваша гибель не напрасна. Мы помним вас и чтим в наших сердцах и молитвах. От мусульман Самарской области», дип язылган. Әйтергә кирәк, постамент ясаган һәм мемориаль ташка язу төшергән егетләр бер тиен дә акча алмадылар. Бу изге эштә катнашкан һәр адәмгә Аллаһының рәхмәтләре яусын, – дип сөйли Равил Рәифович.

Шулай итеп, киң күңелле, миһербанлы кешеләрнең күмәк тырышлыгы нәтиҗәсендә як-







ташларыбыз һәлак булган урынга обелиск куела. Равил әфәнде сүзләренчә, киләчәктә фаҗига булган урында кәстәнә (каштан) агачларыннан торган аллея ачарга һәм кәшәнә (часовня) төзергә планлаштырыла икән.

– Бәлки, мөселман ир-егетләребез истәлегенә куелган обелиск Яңа ел төнендә шәһит киткән башка дин кешеләре истәлеген дә читләп узмаска ярдәм итәр, – ди Равил.

Шушы баруында Равил Фазлетдиновның командасы, ничәмә-ничә шәһәрдә булып, барлыгы 1000гә якын чакрым ара узып кайта. Бу юлы алар алгы сызыктагы сугышчыларны коткаручы медицина батальонына ике «Нива» автомобиле, медицина препаратлары, мобиль портатив җиһазлар, бинтлар, дизель генераторлары, тимер мичләр, Мариуполь шәһәрендәге балалар йортына коляскалар, җылы киемнәр, уку әсбаплары һәм башка кирәк-яраклар илткәннәр.

– Хәзерге вакытта якташларым махсус хәрби операциядә катнашалар һәм бөтен ил берләшкәндә мин берничек тә читтә кала алмыйм. Без аларга хәлебездән килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз. Самар шәһәренең Зубчаниновка бистәсендәге Мәдәният йортында төрле түгәрәкләрдә шөгыльләнүче балалар хәрбиләргә изге теләкләр язылган хатлар әзерлиләр. Әмма иң мөһиме – әйтерсең лә без сугышчыларга туган йортларының җылысын тапшырабыз... – дип аңлата Равил Фазлетдинов.

2024 елның феврале азагында «Ихсан» төркеме махсус хәрби операциядә катнашучы якташларыбызга чираттагы гуманитар ярдәмне илтеп кайткан. Равил Фазлетдиновның командасы бу юлы да, ничәмә-ничә шәһәрдә булып, ике атна дәвамында барлыгы 1000нән артык чакрым ара узган. Алгы сызыктагы сугышчыларны коткаручы медицина батальоннарына кирәкле препаратлар, мобиль портатив җиһазлар, бинтлар, дизель генераторлары, тимер мичләр, җылы киемнәр һәм башка кирәк-яраклар белән шыплап тутырылган ике «Газель» машинасының берсе – Луганск, икенчесе Донецк Халык Республикаларына киткән.

Сәфәр кысаларында Равил Фазлетдинов җитәкләгән төркем вәкилләре Макеевкада һәлак булган хәрбиләребез истәлегенә куелган стелла янында да булганнар, мәрхүмнәр рухына дога кылганнар. «Безнең стелла янында әле генә куелган чәчәкләр һәм такыяларны күреп, нык куандык, – дип сөйли Равил. – Димәк, егетләребезне монда онытмыйлар».

Равил Рәифович бу юлы гуманитар ярдәм белән бергә, Макеевкада туганын югалткан рус дусты үтенече буенча, андагы чиркәүгә һәм хәрбиләргә тапшыру өчен ике икона да алып барган. Иконаны рәхмәт әйтеп кабул иткән рухани Георгий Яңа ел төнендә һәлак булган барлык егетләр рухына дога укыган. «Тәңребез догаларыбызны әрвахлар рухына үзе белеп юллар. Аеруча сугыш вакытында, синең дин дә, минем дин, дип аеру юк ул, мондый авыр заманада бу чикләр юыла сыман, без барыбыз да, дөньяда тынычлык урнашсын, дип дога кылабыз», – дип аңлаткан рухани. Шул рәвешле, «Ихсан» командасы хәрбиләргә гуманитар ярдәм күрсәтеп кенә калмый, ә милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга да зур өлеш кертә.

Чыннан да, хәрби операциядә катнашучылар белән аралашканда алар һәрвакыт сугыш кырындагы дуслык, бердәмлек, ярдәмләшү турында сөйлиләр. «Мөселманнар намаз укыганда христиан динендәгеләр аларның тынычлыгын саклый һәм киресенчә. Сугыш сызыгына якынрак булган саен хәрбиләр арасында гаплэшүләр, үпкәләшүләр юк, диярлек. Алар һәрбер минутның кадерен белеп яшәргә тырышалар. Ә тылда кешеләрне күбрәк матди проблемалар борчый, юкка-барга талашалар, һаман нидер бүлешәләр. Кызганыч, әмма рухи кыйммәтләрнең мөһимлеген бик авыр хәлдә калгач кына аңлыйбыз шул», – дип ассызыклыйлар утны-суны кичкән егетләр. Бу сүзләргә колак салырга кирәктер, дип уйлыйм.

*Авыр тормышта яшәсәләр дә, бабаларыбыз киләчәкне дә кайгырта белгәннәр. Авыл җирләре халыкны сыендыручы да, туендыручы да, төп яшәү чыганагы булганга да, алар, аның кадерен белеп, авыл табигатенә рәхмәтле булып яшәгәннәр.*

***Фәрид Шириязданов.***

# ҖИР САТУ – УЛ ТУГАН ИЛНЕ САТУ

Хәзерге хәлгә килгәндә, ни күрәбез? Элгәре тулы сулы булган елгачыклар-күлләр кипкәч, аларның инде исемнәре дә онытылган. Ярларыннан ташып аккан Сок елгасы да торган саен ерганакка әверелеп бара. Авыллар тирәсен урманнар, әрәмәләр каплаган урыннар хәзер шыр ялангач хәлдә.

Әлбәттә, монда уйланырлык нәрсәләр күп. Авылны үсеш юлына бастырып, сокланырлык хәлгә китергән колхоз тар-мар килде. Хәзер авылны яшәткән һәм әби-бабаларыбызны, ата-аналарыбызны үз куенына сыендырган, авылның төп байлыгы булган җирләрне чит-ятларга сату башланды. Иң аянычлысы – фермерлар арендага алып эшкәртә торган җирләрнең сатылуы.

Бу хакта Иске Ярмәк авылындагы хәлләр һәм аның мисалында башка авыллар язмышы турында сөйләшкәндә төрле кешеләрнең төрле фикерләре тупланды.



**Мөбин улы Мөхәммәт Фәтхетдинов** – авыл хуҗалыгы белгече, тәҗрибәле җитәкче, шәхси хуҗалык башлыгы:

– Элгәре җирләрне эшкәртүдә, кырчылыкны, малчылыкны алып баруда бөтен авыл халкы актив катнашып, зур җиңүләр яуланды, бай табыш алынды, һәм авыл тормышы гөрләп торды.

Ил язмышы кискен борылыш ясап, алда упкын баскач, бездә дә колхозны таркату юлында күп этлекләр эшләнде. Нәтиҗәдә халыкның рухы сынды, күңеле суынды.

Авыл җирләрен эшкәртергә алынган хезмәткәрләргә теләктәшлек күрсәтү урынына хәзер шуларга карата булган хөсетлек, аяк чалулар ачыктан-ачык эшләнә. Инде алар арендага алып эшкәрткән җирләрне читләргә сатуны оештыручылар да бик актив эшчәнлек алып баралар. Боларның үз авылдашларыбыз булуы – авыл тарихында күренмәгән хурлык бит.

Җирләрне читкә сатып, табышлы булу һәм вак-төяк проблемалардан котылу – шул җирләрне булдырып, саклап калган бабаларыбыз һәм Аллаһы Тәгалә алдында зур җинаять.

Авылга нинди бәла килүен аңлау, аның киләчәктә ни хәлгә каласын күз алдына китерү өчен хәзерге көндә күренгән мисаллар да җитәрлек. Мәсәлән, җирләреннән колак каккан авылларда:

- кырлар рәхимсез рәвештә агулангач, умарталар үлә, авыл табигатенә һәм кешеләр исәнлегенә зур зыян килә,
- фермерларны кысрыклап, җирләрне читләр яулап алгач, авыл ташландык хәлдә кала;
- җирсез калган авыл таркалгач, андагы җирләрне вахта белән килеп эшкәртәчәкләр.

Бу сүзләр уйдырма түгел. Мондый ачы хакыйкать хәзер инде байтак җирдә ачык күренә башлады. Эшләр болай барса һәм җирләр сатылып бетсә – безгә дә мондый хәлне күтәргә озак вакыт калмаячак.



**Әлмир Нигъмәтуллин** – фәнни-гамәли оешма җитәкчесе, фәннәр кандидаты:

– Авылларның мескен хәлгә калуы халыкның рухи зәгыйфьлегеннән, тулы хәтерсез һәм бар нәрсәгә битараф булуыннан килә. Бу – коточкыч зур фаҗига.

Татарлар гомергә, һичбер авырлыкларга бирешмичә, бердәм, көчле рухлы, эшкә батыр, баш имәс һәм горур халык булып яшәгәннәр. Ә хәзер ни күрәбез?! Тормышта бар нәрсә дә җитәкчедән килә – уңышлар да, чарасызлык, мескенлек тә. Кайда җитәкче, көчле булып, халыкның рухын үстереп, үз артыннан ияртеп бара ала икән – анда эшләр уңышлы була, һәм тормыш гөрләп бара. Менә шундыйлардан үрнәк алып яшәргә тырышканда гына, тормыш нәтиҗәле була.

Ә хәзер киресенчә, күп җирдәге хәерсезлекне күреп, халык үзе дә шул агымга иярә. Ә җитәкчеләре – беренче чиратта!

Мин үзем шәһәрдә яшәп, зур фәнни-гамәли оешманы җитәкләп, җаваплы эштә эшләсәм дә, үземнең туган ягымдагы Балыклы авылында фермер хуҗалыгы алып барам.

Эш авыр, ә ярдәм булмаганга, минем белән эшли башлаган фермерларның хезмәткә дәрте сүнә ба-

руына йөрәгем әрни. Ирексездән шул хакта уйланып, нәтиҗәләр ясыйм. Минем төпле фикеремчә, иң элек, авыл җитәкчесенең киләчәккә реаль планы, төгәл максаты булуы кирәк. Ул кич яткада да, иртән торуга да, шуларны гамәлгә ашыру өчен бар көчен, бар булдыгын биреп, шул исәпләр белән яшәргә тиеш.

Элгәре халык көнкүрешен, аның рухи халәтен кайгыртучы оешмалар күп иде. Хәзер болар артта калды. Монда ирексездән мәчет уйга килә. Элгәре бөтен мәсьәләләр дә мәчеттә, дингә таянып хәл ителгән: җир, хокук, әхлакый тәрбия, гаилә тормышы, үзара ярдәм, гыйлем бирү һәм башка тормыш мәсьәләләрен бабаларыбыз уртага салып хәл иткәннәр.

Элгәре мәктәп, Мәдәният йорты һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмасы, китапханә кебек оешмаларда да авыл хәлләрен кайгыртуда зур тәҗрибә тупланган иде.

Хәзер авылда эшләгән фермерларга карата хөсетлек, үги караш булуы, теләктәшлек һәм ярдәм күрсәтелмәве дә күңелне борчый. Шулай ук аларның, бер бәйләмдә булып, ярдәмләшеп эшләвен авыл администрациясе оештыра алмый икән – авылның киләчәге, андагы җирләрнең язмышы турында сөйләнүләр буш сүз булачак.

Ни кызганыч, әлегә бу мәсьәләләр таркау һәм җансыз хәлдә. Ә иң мөһиме – авылдан читтә яшәүче интеллектуаль көчләр, елына бер тапкыр булса да, бергә җыелып, нәтиҗәләр ясарга, уйланырга тиешләр. Әйтик, яңа елда, бәйрәм вакытларында.



**Фәһим Хәниф улы Йосыпов** – җәмгыять эшлеклесе, «Туган тел» оешмасы Советының әгъзасы, югары органнарда эшләгән тәҗрибәле җитәкче:

– Алга нинди генә катлаулы мәсьәләләр басса да, гыйбрәт алу өчен бай тарихыбыз бар. Мәсәлән, борынгы төркиләрнең кодрәтле ил башлыгы Җания Бахадур хакимлек иткән «кан заманнан» ук дәүләтнең төп идеологиясе, сәясәте, ил белән идарә итү тәртибе – барысы да тулысынча җир биләүгә нигезләнгән була.

Аннан соң һуннар, гуннар империяләре, төрки каганатлар, Болгар, Хәзәр һәм Алтын Урда дәүләтләренең бөеклеге һәм кодрәте алар кулындагы җир байлыгы белән бәйләнгән.

Җир белән уйламыйча эш итү нәтиҗәсендә килеп чыккан фаҗигаләрне тарихта күп күреп була. Мәсәлән, Алтын Урда, дөньядагы иң көчле дәүләткә әверелеп, югары үсеш ноктасына җиткәч, Үзбәк хан, дәүләт конституциясен үзгәртеп, җирләрне сатуга юл ача.

Нәтиҗәдә Кырым, Мәскәү дәүләте, Себер һәм башка олысларның җирләре тора-бара үз карамагына күчкәч, алар акрынлап аерылуга, мөстәкыйльлеккә юл тоталар. Алтын Урданың таркалуы шуннан башлана да инде.

Тарихтан күргәнебезчә, Казан ханлыгы басып алынып, татарлар үз дәүләтчелеген югалткач та, алар, мәхәлләдә берләшеп, бар булган авырлыкларны бергә җиңеп яшиләр. Башка халыклар да шундый ук рәвештә общинада берләшеп яшәгәннәр.

Бу бердәмлекне җимерү өчен, патша хөкүмәте, җир реформасы үткәреп, аны сатуны оештыра. Моның нәтиҗәсендә патша идарәсенең нигезе какшый башлый, һәм төрле революцияләр башлануга юл ачыла.

Патшаның үз биләмәсе булган Аляcканы буш хакка сатуы да хәзер тарихтагы хурлыклы бер күренеш булып тора.

Америка, Япония һәм Европадагы авыл хуҗалыгы югары үсеш алган илләрдәге хәлләрне алсаң, анда фермерларның тулысынча хөкүмәт сагында торуы күренә. Зур корпорацияләр йотып, үзләрен юк итмәс өчен алар җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясенә дотация бирелә. Бу ул илләрдәге дәүләт куркынычсызлыгының нигезе булып санала.

Инде үзебезнең Иске Ярмәк авылындагы хәлләргә килгәндә, узган елда җирләрне читләргә сату буенча сәер агитация эшләре башланган иде. Бу уңайдан авылның Мәдәният сараенда зур җыелыш уздырылды. Анда җир сатуның ахырында ни буласы турында җитди сөйләшү булды. Фермерларга авыл халкы һәм тәҗрибәле белгечләр тарафыннан ярдәм һәм теләктәшлек күрсәтү һәм аларның эшчәнлеген берләштерүче оешма булдыру турында карар кабул ителде. Бу килешү авыл администрациясе алып барган протоколда теркәлде. Ә хәзер ни күрәбез? Фермерларга ярдәм итү, алар арасында үзара ярдәм оештыру урынына аларның арендага алынган һәм кулланышта булган җирләрен тартып алып, шуларны читләргә сату бара.

Монда авыл язмышына битараф булмаган кешеләр, фермерларның мөмкинлекләрен һәм планнарын төгәл белеп, авылның киләчәген хәл итүче җирләренең язмышы турында тирәнтен уйланырга кирәк. Авыл администрациясенең бу хакта реаль планнары юк икән, димәк, монда кичекмәстән кискен чаралар кабул ителергә тиеш.



**Габдулла хәзрәт Мөхәммәткәримов** – Иске Ярмәк авылының имам-хатыйбы:

– Дөньяда беренче мөселман дәүләте – хәлифәт барлыкка килү белән, аның идарә системасы Шәригать кануннарына нигезләнгән була. Ә анда иң алгы планга хокук һәм җир биләү мәсьәләләре куела.

Коръәни-Кәримдә дә Җирнең Аллаһы Тәгаләнең бөтен тереклек ияләре өчен яралткан иң зур байлыгы икәнлеге һәм Аның милке булуы турында ачык әйтелгән.

Хәлифәт дөнья тарихында иң гадел, социаль дәүләтләрдән саналган. Җирләр аерым кешеләр кулында тупланып, кемнәрдер баеп, калганнар бөлгенлеккә төшмәсен өчен анда гадел законнар каралган.

Шул исәптән ятимнәргә, ялгыз картларга, мөмкинлеге булмаган мескеннәргә җәмгыять тарафыннан мәрхәмәт күрсәтү зур изгелек саналган.

Аллаһы Тәгалә милке булган җирне сатуның үз анаңны сатуга тиң гөнаһ булуы турында Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) хәдисләрендә дә әйтелгән. Гарәп хәлифәтенең аббасидлар хакимлек иткән чорга кадәрге үсеше тарихта «Золотой век ислама» дип атала.

Тик аббасидлар чорында җирләр сатылып, эреле-ваклы феодаллар күбәйгәч, хәлифәтнең кодрәте кимүгә һәм ахырда аны таркалуга китерә.

Заманалар үзгәреп, хәзерге вакытта безнең илдә дә җирләр шәхси милеккә әверелде. Бу хәл, киләчәктә җирләр аерым кулларга күчеп, халыкны җирләреннән мәхрүм итеп, түбән хокуклы мескеннәргә әйләндерү рәвеше түгелме? Ваучерлар заманында ил байлыгын талау өчен халыкны чарасыз калдыру ачыктан-ачык эшләнсә, хәзерге этлекләр хәйләкәррәк рәвештә башкарыла.

Заманында бабаларыбыз илле ел түләү исәбеннән бу җирләрне кредитка алганнар. Аны күмәкләп эшкәртеп көн күргәннәр, Столыпин реформасына кадәр.

Ә хәзер халыкларга җир милкен сату мөмкинлекләре ни өчен бирелгән соң? Бу буталган заманны тагын да бутап, халыкны бөтенләй чарасыз калдыру рәвеше түгелме соң?

Ул җирләр һәркемнең ата-бабасыннан калган шәхси мирасы да түгел ләбаса. Ул – авыл җәмгыяте милке. Шуңа да бу авыр вакытта Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән бер сынау рәвеше түгелме икән соң? Бу хәл авыл җәмгыятенең тамырын балта белән чабу түгелме?

Киләчәктә җирләр авыл кулыннан китә икән, аның юкка чыгуы – билгеле хәл. Борынгыдан яшәп килгән, данлыклы тарихы булган авылның югалуына юл куйган, бигрәк тә моны тизләтүне оештырган кешеләр Аллаһы Тәгалә каршында нинди җавап тотарга җыеналар икән соң?



**Фәрит Гыйлаҗев** – Дәүләткол авылында эшмәкәр:

– Зур тизлек белән алга барган тормышта авыл хуҗалыгында да шактый үзгәрешләр күренә. Төрле корпорацияләр, холдинглар барлыкка килүе дә – хәзер инде табигый хәл.

Бу өлкәдә югары уңышларга ирешкән илләрнең эш тәҗрибәсен алганда, алардагы вак фермер хуҗалыкларына да зур әһәмият бирелүе һәм аларның эшчәнлеге тулысынча хөкүмәт сагында торганлыгы күренә. Бу мәсьәлә хәтта аларның дәүләт куркынычсызлыгы сәясәтенә дә нигезләнгән.

Андагы фермер хуҗалыкларының эше тулысынча кооперацияләнгән булуы да безнең өчен аеруча зур игътибарга лаек. Инде бездәге хәлләргә килсәк, мондый мәсьәләләр әлегә безнең өчен баш җитмәслек зур проблема булып тора. Алда тулы билгесезлек торган заманда аерым хуҗалык алып баруның никадәр авыр хезмәт булуын әлегә фермерлар тик үзләре генә беләләр шул.

Дөрес, татарларга беркайчан да, һичнинди дәүләт тарафыннан да тулы ireклек бирелмәгән һәм бернинди ярдәм дә күрсәтелмәгән. Тик басым аз гына җиңеләю белән, алар, тормышның төрле өлкәсендә зур уңышларга ирешеп, көчле күтәрелеш булдыра алганнар. Әлбәттә, бу – мәхәллә тирәсендә берләшү һәм оешканлык нәтиҗәсе.

Дөрес, хәзер дә үзидарә системасында булган мөмкинлекләрне куллану өчен киң мөмкинлек бар. Ни кызганыч, тик алар әлегә яхшылап кулланылмый.

Хәзер татарларны дөньяга таныткан уңганлык, бердәмлек, туганлык, оешканлык югалып, үзара хөсетлек, үчлелек, дошманлык һәм бар нәрсәгә тулы битарафлык гадәткә кереп бара. Авылларда бик күп кенә акыллы һәм тормышта уңышлы кешеләр тәрбияләнгән. Ни кызганыч, тик аларның күбесе хәзерге вакытта читкә сибелеп яшиләр. Төрле җирләрдә һәркем тик үз мәнфәгатен генә кайгыртып көн күрә.

Минем төпле фикеремчә, туган авылы хәлен кайгыртырга сәләтле кешеләр үзара киңәшергә тиеш. Елына бер мәртәбә булса да, бергә җыелып, үткән, бүгенге һәм киләчәк турында уйлану өчен «Общественный совет» булдырырга кирәк, дип уйлыйм.

Хәзерге көндәге иң мөһим мәсьәлә – халык кулындагы җирләрне читләр кулына бирмәү. Авылларның яшәве дә, юкка чыгуы да тик шуңа бәйләнгән.

Ахыр чиктә, авыл җирләрен тулысынча эшкәртү мөмкинлекләре бөтенләй табылмый икән, читтән ышанычлы инвесторларны табарга кирәк, дип уйлыйм, тик сатуга гына юл куймаска. Җире саклана икән – авыл яшәячәк, булмаса, аның юкка чыгуы – билгеле хәл.



**Фаил Нурфатыйх улы Гарифуллин** – Яр Чаллы шәһәрендәге «Стройтехком Холдинг» оешмасының директоры урынбасары:

– Иске Ярмәк авылында туып,

аның гүзәл табигате кочагында үскәнгә, эти-әнием, балачагым, үсмер чорлары һәм мәктәп еллары турында үз гомеремә иң якты истәлекләр саклап яшим. Аена бер тапкыр булса да, туган якларыма кайтып әйләнергә тырышам.

Авылдагы гөрләп торган колхоз таралуын мин авыр кичердем.

Дөрес, хәзер илебез авыр чирдән арынырга тырышучы кешене хәтерләтә.

Татарстандагы Яр Чаллы шәһәрендә яшәгәнгә күрә, мин андагы хәлләргә кагылышлы гыйбрәтле мисаллар китерәсем килә. Мәсәлән, ул якларда «землячество» дип аталган гыйбрәтле бер хәрәкәт бар. Анда якташлар, дуслар, гомумән, үз авыллары язмышына битараф булмаган, авылларының хәзергесен һәм киләчәген кайгыртырга сәләтле кешеләр җыелып, киңәшү гадәте бар.

Анда бәйрәмнәр үткәрүгә ярдәм күрсәтү кебек һәм башка төрле мәсьәләләрне уртага салып сөйләшәләр. Дөрес, Татарстанда төрле биеклектә түрәләр тарафыннан да авыллар хәлен кайгырту сизелә. Тик төп авырлыкны, төп җаваплылыкны авыл башлыклары үзләре күтәрәләр.

Авыл халкын һәм аннан читтә яшәгән кешеләрне берләштереп, бер оешма булдырырга сәләтле башлыклар яисә моны оештырырга сәләтле кешеләр бар икән, димәк, ул авыл бәхетле һәм аның киләчәгенә дә өмет баглап була, дигән сүз.

Татарлар нинди генә изелү астында яшәмәсен, җәмгыять язмышын гомергә абызлар, хәлле кешеләр һәм муллалар җитәкләгән, ә халык аларга ияргән. Хәзер инде киң мөмкинлекләре булган кешеләрнең күбесе читкә сибелгән. Авыл бүген үзе үстергән шундый кешеләр ярдәменә дә бик нык мохтаҗ.

Киңәшле эш – уңышлы эш, диләр. Татарстанда җирләрне читләргә сату кебек ахмаклык булуы әлегә ишетелгәне юк. Үзләрендә тәвәккәл кешеләр булмаган очракта алар читтәге булдыклы кешеләргә арендага биреп эшләтәләр. Күп авыллардагы җирләрдән югары уңыш алына. Заман таләпләренә туры килгән малчылык комплекслары төзелә. Шуңа да авылларның күбесе инде яңа шартларда тулы канлы тормыш алып баралар.



Мин эшләгән оешма да Татарстандагы төрле районнарда өчәр мең баш сыерга исәпләнгән сөтчелек комплекслары төзи. Алардагы бар булган эшләр механизацияләнгән, автоматлаштырылган һәм компьютерлар ярдәмендә идарә ителәчәк. Әлегә эшчеләрне вахта белән ташыйлар. Торак йортлар төзелеп беткәч, яшь көчләрне туплау планлаштырыла. Таркалу юлына баскан авыллар, яңа сулыш алып, үсеш юлына баса баралар. Мондый эшләрдә Мәскәүдән һәм башка җирләрдән килгән инвесторлар да катнашалар.

Халыкка күпләп эш урыннары ачыла, ә җир пайлары хуҗаларына югары табыштан өлеш чыгарыла. Гомумән, Татарстандагы күп авыллар хәзер үсеш юлында. Чөнки анда киләчәкне кайгырта белгән, тере җанлы кешеләр җитәклиләр, һәм хезмәт ияләре аяк терәп эшли беләләр.

Йомгаклау. Бәхетсезлеккә тарып, чарасыз калгач, үзләренең имана җирләрен сатучы мескеннәр элгәре дә булган. Шулай ук ахыр чиккә җитеп, хәтта үз җирләрен сатып эчкән сукбайлар, «зимагорлар» булуы да билгеле.

Ләкин аек акыллы кешеләр чиксез авырлыклар кичергән вакытта да, үз җирләрен арендага биреп, читтә ялланып булса да, үз җаннарын саклап, авылның, үз балаларының киләчәген кайгырта белгәннәр.

Ә хәзерге тук заманда күпләрнең, төрле сылтаулар табып, үз җирләрен сатарга керешүе – коточкыч зур фаҗига. Бераүләр: «Үзебез исән вакытта җирне сатып, рәхәтен күреп калыйк», – диләр. Икенчеләр үз баласын өйләндерергә телиләр, өченчеләр, оныкларына җир акчасын бүлеп биреп, аларның «мәхәббәтен» яуламакчылар.

Мондый хакка корылган никахларның берәгәйле булуы мөмкинме?! Ә оныкларының мондый халява тәэсирендә туган «хөрмәте» озакка барырмы икән соң?!

Авыл җирләрен сатып, аннан котылгач, бернинди файдатабыш китерми торган авылны кем асрар – хөкүмәтме яисә әллә кайларда утырган билгесез җир хуҗаларымы? Үз җирләрен үзләре саткан кешеләрнең балалары, оныкларымы?

Мондый очракта туган якка карата мәхәббәт хисләре хакында, гореф-гадәтләргә, милләткә, телгә, ата-бабаларыбыз рухына карата хөрмәт турында хурланмыйча сөйләргә урын каламы икән соң? Моның каргышлы кәсеп икәнлеген уйлап карауучылар бармы соң?

Бу хәлне Р. Рысаев шигыре юлларын укыганда күз алдына китереп була:

*Җир сату – ул туган илне сату.*  
*Җир сатарга, диләр, туган җирне,*  
*Безне туендырган җирләрне.*  
*Безнең туфрак шундый*  
*уңдырышлы,*  
*Шуңа кызыктыра ул читләрне.*  
*Җир сатылса – халык нишләр?*  
*Хәер, халык хәле ник кирәк!*  
*Комсызларга фәкать акча кирәк,*  
*Алар өчен акча – төп терәк.*  
*Җан бирмәсме изге Җир-Анабыз,*  
*Кыз-уллары моңа юл куйса,*  
*Корымасмы кулы андыйларның,*  
*Шул язуга уйсыз кул куйса?!*  
*Җир сату – ул туган илне сату,*  
*Ә ил сату – иң зур җинаять!*  
*Тарих белә – һич тә бәхет түгел —*  
*Каһәрлекләр туплый хыянәт!*



# Яшьлеккә кайткандай

## Елховка районы Тупли авылы мәктәбенең беренче чыгарылышы 50 ел элек булган

***Балачак, мәктәп еллары - кеше күңелендә мәңге саклана торган матур хатирәләр. Шуларны әледән-әле яңартып тору өчен илнең, кайвакыт хәтта дөньяның да төрле почмакларына таралып яшәүче сыйныфташлар очрашулар үткәрәләр.***

***Эльмира Сәйфуллина***



2 мартта Самарның "Белоснежка" хәләл кафесында моннан 50 ел элек Тупли мәктәбен тәмамлап чыккан сыйныфташлар очрашты.

- Без беренче сыйныфка 1964 елда китапханә бинасының бер читендә урнашкан кечкенә генә мәктәпкә килгән идек. Ул вакытта авылда тагын ике мәктәп бар иде. 1972 елда, без сигезенче сыйныфны тәмамлагач, авылда урта мәктәп ачылды.

Ул вакытта балалар саны күп



иде. Алмалыдан да безнең авылга килеп укучылар бар иде. Ике сменада укыганлыктан, иртәдән кичкә кадәр мәктәп гөрләп торды, - дип искә ала Мәсгут ага Харисов. – Яшь, укымышлы укытучылар килделәр. Алар аңлаткан темалар әле дә истә. Аеруча рус теле укытучысы Гали абый Сатдаровның дәресләре күңелдә уелып калган. Класста утырган 24 бала да теманы яхшы аңларлык итеп укыта белә иде.

Ләлә апа Вәлиәхмәтовага, Алия апа Аләветдиновага, Гөлсинур апа Гәрәевага, Гөлфия апа Гайсинага, гомумән, барлык укытучыларыбызга да без бик рәхмәтлебез. Арабыздан югары белем алып чыгучылар да байтак булды. Кызга-

ныч, хәзерге вакытта мәктәбебез ябык, мөгаллимнәребезнең күбесе арабызда юк инде, ә менә безне чыгарылышка кадәр укыткан Валентина Чугунова исән-сау, Рождествено авылында яши.

Әңгәмәдәшем сүзләренчә, Тупли авылы мәктәбен 1974 елда тәмамлап чыккан сыйныф ул вакытта да, бүген дә бик тату, һәр биш ел саен очрашып-күрешеп торалар, юбилейлы туган көннәрне дә бергә билгеләп үтәләр.

Быелгы очрашуны Мәсгут Харисов, Венера Латыйпова, Мәрьям Гарифуллина оештырганнар.

Мәҗлес бакыйлыкка күчкән укытучылар һәм сыйныфташлар рухына дога кылудан башланган.

“Арабызда Рәфыйк Сабиров кебек дустыбыз булуына бик шатбыз. Ул һәр очрашуны Йасин, Коръән сүрәләре укып башлый. Мәңгелеккә күчкән дусларыбыз рухына догалар укыгач, күңелдә ниндидер җиңеллек сизәбез. Кылган догаларыбыз кабул булсын иде”, - диләр сыйныфташлар.

- Аттестат алып чыгуыбызга 45 ел тулгач оештырылган очрашуга утыздан артык кеше җыелган иде, ә быел барлыгы егерме кеше генә килә алды, - дип авыр сулый Венера Латыйпова. – 40 елдан соңгы очрашуда мин бер дә күрешмәгән сыйныфташым белән очраштым. Ул мәктәпне тәмамлагач, БАМ төзелешенә киткән иде. Олыгайган саен сыйныфташлар ныграк сагындыра, барысын да күрәсе килә. Шуңа күрә һәр очрашуга ашкынып киләбез, ныклап әзерләнергә тырышабыз.

Быел, мәсәлән, Мәсгут истәлеккә мәктәп һәм сыйныфташлар фотосы төшерелгән кружкалар бүләк итәргә тәкъдим итте, мин стена газетасы ясадым. Безнең идеяләр барысына да бик ошады.

Мәсгут чараның мәдәни ягын да кайгырткан – яраткан гармунчыбыз Мидхәт Әминовны чакырган. Рәхәтләнеп сөйләштек тә, биедек тә, җырладык та.

Кыскасы, бик күңелле булды. Алга таба да шулай, дуслык җепләрен өзмичә, тату яшәргә, очрашып-аралашып торырга сүз бирешеп таралыштык.

- Барыбыз исеменнән дә «Белоснежка» хәләл кафесы җитәкчесе Тәлгать Мортазинга, телеңне йотарлык итеп тәмле ризыклар әзерләгән пешекчеләргә зур рәхмәтләребезне җиткерәбез, - дип йомгаклады сүзен Мәсгут ага.

Чәчләренә инде чал кереп баруына карамастан, күңелләрендә яшьлек дәрте сүнмәгән, көндәлек мәшәкатьләр арасында балачак дуслары белән очрашырга вакыт тапкан актив сыйныфташлар яшьләр өчен үрнәк булып торалар. Афәрин!



















*35 ел элек Куйбышевта оешкан татар җәмгыятенең беренче утырышы алдыннан булган оештыру гамәлләре турында тарихчы һәм журналист Шамил Галимов язып чыккан иде. Хәзер сезнең игътибарыгызга “Туган тел” җәмгыяте аксакалы Азат ага Надировның хатирәләрен тәкъдим итәбез. Ул алдагы теманың дәвамы булып бара.*

*Азат Надиров*

# ОЕШМАНЫҢ ДАНЛЫ ЕЛЛАРЫ



### Учредительләр конференциясе

1989 елның 27 маенда рухи күтәренкелек мохитендә үткән учредительләр конференциясендә “Туган тел” өлкә татар җәмгыяте гамәлгә керә. Оешманың беренче рәисе итеп – Рәшит Абдуллов, ә Советка Шамил Әхмәров, Азат Надиров, Әхмәт Нәфыйгин, Гөлсинә Нуруллина, Асия Ногманова, Мансур Ямалетдинов һәм башкалар сайланды. Конференциядә өлкә җитәкчелеге һәм ТОЦ вәкиле – фольклорчы Рәшит Ягъфәров катнаштылар.

### Өлкә Сабан туе

1989 елның 24 июнендә, минем тәкъдимем буенча, Самар ипподромында меңләгән кеше катнашында өлкә Сабан туе үткәрелде. Шул вакыттан бирле татар тормышында Сабан туе, Нәүрүз, Сөмбелә, Боз озату, Балалар фестивале, Яңа ел бәйрәмнәре лаеклы урын алдылар. Анда Самарның “Ялкынлы яшьлек”, “Идел” “Яктылык” мәктәбенең “Йолдыз” ансамбльләре, өлкә районнарыннан үзешчән сәнгать коллективлары чыгыш ясыйлар. Бу аларны үсешкә этәрә, милли сәнгатебезне үстерүгә юл яра. Соңгы елларда балалар фестивале “Мирас” исеме астында үткәрелеп килә. Бу чаралар, журналист һәм тарихчы Шамил Галимов сүзләренчә, тормыш сөючән һәм җаваплы халкыбызның массакүләм иҗаты, актив кешеләрнең инициативасы. Берәүләре, шәхси тормышын читкә куеп, халык өчен хезмәт итә, икенчеләре хәйрия ярдәме күрсәтә, өченчеләре оештыру эшләре белән мәшгуль. Шулай, Хәбил һәм Илшат Бикташевлар, Наил һәм Хәйдәр Гәрәевлар, Рәфыйк Әбдиев, Марат Гыйбадуллин, Ринат Шәрифуллин, Рәфыйк Шәфигуллин, Салих Вәлиәхмәтов, Әсфәндияр Вәлитов, Фәһимә Рәҗәпова Сабан туйларында спорт ярышларын бик оста итеп оештыралар; Фәрхәт һәм Альбина Мәхмүтовлар, балалар мәйданчыгында көнозын мәш килеп, конкурслар һәм ярышлар оештырдылар, кичен Фәрхәт җитәкчелегендә яшьләр өчен дискотека булды.

### Авиазаводка рәхмәт

Совет заманында мин, Авиазавод җитәкчелеге белән очрашып, “Родина” Мәдәният сараенда татар җыры түгәрәге оештырырга рөхсәт алдым. Аның җитәкчесе итеп музыка белгече Әлфия Гыйниятуллина билгеләнде, Румия Валькаева “Сабый” түгәрәген алып барды. Түгәрәк җитәкчеләренә Авиазавод җитәкчелеге акча да түләп торды. Моның өчен заводның икътисад бүлеге җитәкчесе Асия Хәбибуллинага рәхмәтлебез. Оешма җыелышларын да шунда үткәрә идек. “Туган тел” оешмасы эшчәнлегенә мөмкинлекләр тудырган өчен завод җитәкчелегенә Рәхмәт хаты да язган идем. Тора-бара Мәдәният йортларын арендага алган өчен акча сорый башладылар. Башта безнең оешмага “Заря” Мәдәният йорты канаты астына күчәргә

туры килде. Хәзер инде күп еллар буе элеккеге “Родина” клубы нигезендә барлыкка килгән Халыклар дуслыгы йортында яшибез. Бу да – без башлаган эшнең дәвамы, чөнки безнең үрнәктә башка милли-мәдәни оешмалар барлыкка килде, бергәләшеп хөкүмәт белән конструктив хезмәттәшлек иту нәтиҗәсенә ирештек. Ул вакытта “Родина” клубы директоры булып эшләгән Е. А. Никулинага да, хәзерге җитәкчеләренә дә чиксез рәхмәтләребез.

СССР таралу фаҗигасе, Ак йорт баррикадалары, халыкны тәмам бөлгенлеккә төшергән реформалар, халыкка кирәк булмаган чечен сугышы чорында “Туган тел”нең милләтебезне саклап калырга тырышуы халык күңелендә өмет уята иде.

## Тарих дәресләре

“Туган тел” оешкач, оешма активистлары өчен су юлы буйлап Болгарга сәяхәт оештырылды. Шуннан соң пароходта сәяхәт итүләребез даими була башлады. Аларны “Болгар мирасы” тарихи-мәдәни фонды рәисе, Ширяевоның Поп тавы башында болгар бабаларыбыз истәлегенә “Ак барс” сынын куйган Гомәр Мулланур улы Батршин тормышка ашыра. Соңгы елларда аңа “Туган тел” өлкә татар җәмгыяте президенты Ильяс Гомәр улы Шәкүров та кушылды, һәм ел саен “Яктылык” мәктәбе укучылары һәм ата-аналар өчен безнең өчен изге булып саналган урында тарихи дәресләр, күңел ачу чаралары оештырыла.



Шулай ук борынгы бабаларыбыз яшәгән Муром шәһәрчегенә дә экскурсияләр була. Анда әледән-әле археологик казыну эшләре алып барган урыннарда чүлмәк кыйпылчыклары табыла, балалар өчен бу борынгы тарихыбыз белән очрашуга тиң зур вакыйга булып исләрендә кала.

Гомәр Батршин, Ильяс Шәкүров, Әнвәр Горланов – Идел буенда болгар цивилизациясе, татар авыллары һәм мәчетләре турында язылган күпсанлы китапларның спонсорлары да бит әле. Күпчелек китапларның авторлары – туган як тарихын өйрәнүче Шамил Галимов, Фәрид Шириязданов, мәрхүм Идеал Галәветдинов һәм башкалар.

Мансур Ямалетдинов инициативасы буенча, Болгар татарлары Ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1000 еллыгына багышлап, фәнни-практик конференция уздырылган иде. Тарихчыбыз Шамил Галимов та Идел буе татарлары тарихына багышлаган конференцияләрне даими рәвештә уздырып тора.



## «Бердәмлек»

1990 елның 25 апрелендә “Бердәмлек” өлкә татар газетасының беренче саны басылып чыкты. Ул “Туган тел” оешмасы һәм Өлкә башкарма комитеты тырышлыгы белән дөнья күрде. Аның беренче редакторы итеп журналист Рәфгать Әһлиуллин сайланды. Газета бүген дә өлкә татарлары арасында популярлыгын югалтмаган, атна саен шимбә көнне чыгып тора. 2019 ел башында татар җәмәгатьчелеге аның 1500 саны чыгу уңаеннан укучылар конференциясе оештырган иде. Анда газетаның авыр хәле тикшерелде, хөкүмәт органнарына субсидияләрне арттыру буенча мөрәҗәгать хаты язып җибәрелде.

## Камышлы районы кайтарылды

Рәшит Абдуллов һәм Шамил Бәһаутдинов «Туган тел» оешмасы бүлекләрен Тольяттида, Похвистневода һәм Сызранда ачарга булыштылар. Соңрак, шулай ук безнең оешма ярдәмендә, башка милли оешмалар да гамәлгә керде, барыбыз да бер юнәлештә



эшләдек – татар милли бәйрәмнәре оештырдык, үсеп килүче буынны тәрбияләү өчен мәчетләр белән хезмәттәшлек иттек.

1991 елда, өлкә татарлары үтенече буенча, Камышлы районы яңадан торгызылды. Бу эш буенча “Туган тел” оешмасы да күп тырышлык күрсәтте. 1991 елның 4 мартында районны кайтару Указы чыгу шатлыгыннан инициатив төркем әгъзаларыннан менә шундый эчтәлекле телеграмма килеп төшә:

“Самар шәһәре, «Туган тел» татар мәдәни мәркәзе рәисе

Рәшит Фатыйх улы АБДУЛЛОВКА!

Хөрмәтле Рәшит әфәнде! Сезгә һәм сезнең белән бергә «Туган тел» татар мәдәни мәркәзенә, «Бердәмлек» өлкә татар газетасы редакциясенең бөтен әгъзаларына һәм хезмәткәрләренә яңадан торгызылган Камышлы районы сайлаучылары исеменнән районыбызны кайтаруда күрсәткән ярдәмегез өчен йөрәгебез түреннән чыккан зур рәхмәтләребезне белдерәбез. Киләчәктә эшләрегездә зур иҗади уңышлар телибез!”

### Җәмигъ мәчете

Вазыйх Кадыйров инициативасы буенча, Самарда Җәмигъ мәчете төзү буенча зур эш башлана. Рәшит Абдуллов һәм Шамил Баһаутдинов, мәчет төзелешенә каршы булучылар белән мөселманнар арасында гауга купкач, митингларны зурга җибәрмичә, туктата алдылар. Шулай итеп, безгә Стара-Загора урамындагы гаражлар урыны бирелде, һәм Вазыйх Мөхәммәтшинның “Прогресс” төзү компаниясе, өлкә хөкүмәте һәм бөтен татар халкы сәдакалары һәм физик көче белән мәчет төзелеп бетте һәм 1998 елда сафка басты.

### Туган телебез һәм милләтебез сагында

Россиянең федератив төзелешен, төрле милләт халыкларының таянычы булган республикаларны, шул исәптән Татарстанны да, саклап калу ул вакытта да, хәзер дә һәр аңлы гражданинның изге бурычы. “Туган тел” оешкан заманда милләтчеләр күп иде. Телебезне һәм мәдәниятебезне саклап калу өчен безгә көрәшкә күтәрелергә туры килде. Мәсәлән, Рәшит Абдуллов Югары Совет депутаты Ю. А. Юдинга каршы чыкты. Депутат аны, Татарстанда референдум уздырылган көннәрдә суверенитетка каршы булуын белдереп, телевидениедән чыгыш ясарга мәҗбүр итмәкче иде. Ләкин милләттәшебез катгый рәвештә каршылык күрсәтте. Депутат йодрык күтәреп өстенә килде, сүгенде, казакларның винтовкаларын алып, татарларны атып үтерәм, дип акырды...

Без, бу хәлдән соң Ельцинга протест хаты язып, кайбер депутатларның милләтара ызгыш тудырырга маташуы турында белдердек. Татарстанның төрле милләт халыклары, үзара ихтирам саклап, үзләренә якын булган уртак фикергә килә алачакларына ышаныч белдердек. Республика халкы күпчелек тавыш белән суверенитет өчен тавыш бирде һәм Россиядә, беренчеләрдән булып, икътисад ягыннан көчле республикаларның берсенә әверелде.

### Православ дин нигезләре

Үткән гасырның туксанынчы елларында мәктәпләрдә О. Харитонова һәм А. Бородина авторлыгында басылып чыккан “Православ дин нигезләре” китабы буенча балаларга дин дәресләре укыта башладылар. Бу уңайдан без, “Туган тел” җәмгыяте активистлары, хөкүмәткә, мәгариф һәм фән министрлыгына, ризасызлык белдереп, хатлар юллый башладык. Бу – Конституцияне бозу гамәле, балалар дин турында фәнни яктан тикшерелгән мәгълүмат кына алырга тиешләр, Грабовой ише мошенниклар аларны туры юлдан яздыра алмасын. Дәреслекләрдә болай да дин турында мәгълүмат бар, традицион диннәрнең тәрбия-әхлак темалары, тарихы һәм мәдәнияте турында гына өстәргә кирәк, дигән фикеребезне белдердек.

### Рус һәм татар теле – ике канатыбыз

Рус баласына ана телен мәҗбүри рәвештә укып өйрәнү бәхете бирелгән. Бу бик әйбәт, дип исәплибез. Ә менә руслар белән бергә бер илдә яшәүче рус булмаган милләт балаларына “бик тә демократик” юл, үз телен теләсә – укый, теләсә – укымау хокукы бирелгән. Бу – рус булмаган телләрне бетерүгә китерә торган юл. Без татарлар күмәкләшеп яшәгән авылларда һәм шәһәр бистәләрендә туган телләрне мәҗбүри рәвештә укыту өчен шартлар тудырырга кирәк, дигән фикерне алга сөрдек. Мәктәпләрдә милли-региональ компонент юкка чыгып бара, үзәкләштерелгән мәктәпләргә күчерелгән мәктәпләрдә ана теле укытучылары да булырга, ана теле дәресләре укытылырга тиеш. Ә авылдан үзәкләштерелгән мәктәпләргә балаларны автобусларга утыртып җибәрү юл һәлакәте куркынычы белән яный, дип язылган хатларыбыз астына чуаш, мордва, башкорт милли оеш-

малары җитәкчеләре кул куйды. Мәктәп юк икән – авыл да юк, диган сүз ул. Авыллар – тел, моң, халык җыры һәм гореф-гадәтләре саклагычы бит. Нәтиҗәсен бүген күрәбез инде – мәктәбе булмаган авылларны алабута белән кычыткан басып китте, ә шәһәрләрдә үскән балалар татарча бер кәлимә сүз белмиләр.



## “Яктылык” яктылыкка илтә

“Туган тел” җәмгыятенең иң күренекле казанышы – Самар шәһәрендә “Яктылык” татар мәктәбен ачу. Бу – татар җәмагатьчелегенең өлкә хөкүмәте органнары белән конструктив хезмәттәшлеге нәтиҗәсе. Ишелер дәрәҗәгә җиткән балалар бакчасы бинасын мәктәп итеп үзгәртеп кору, соңрак аңа янкорма төзеп кую да “Туган тел “ җәмгыятенең оештыру сәләте һәм тырышлыгы белән эшләнгән бик зур эш булды.

“Туган тел” оешмасының беренче утырышларының берсенә ут кебек килеп кергән урта яшьләрдәге укытучы хатын үзенең татар мәктәбе ачу идеясе белән уртаклашкач, барыбыз да аны күтәреп алдык. Бу Пермь өлкәсеннән Куйбышевка килеп, эшче яшьләрнең кичке мәктәп директоры булып эшли башлаган Харидә Габдулҗан кызы Дашкина иде. Шул утырыштан соң күп елларга сузылган зур эш башланды – өлкә хөкүмәте һәм мәгариф министрлыгы арасында чабулар, йорт саен йөреп, татар балаларын мәктәпкә җыюлар, татар газетасына белдерүләр бастырулар, “Иделкәем-илкәем”, “Ак бәхет” радиосы аша сөйләп торулар, бәйрәмнәрдә агитация алып барулар юкка булмады, башта кичке мәктәп каршында – якшәмбе мәктәбе, аннан – кичке мәктәпнең көндезге бүлеге, ә ремонт тәмамлангач, аерым мәктәбебез дә эшләп китте.

Нәүрүз һәм Сабан туе бәйрәмнәрендә мин, “Туган тел” оешмасы җитәкчесе буларак, гел татар мәктәбе кирәклеге турында сөйләп тордым. Мәктәпне төзекләндерү өчен өлкә һәм шәһәр бюджетына керә алуыбыз безнең өчен зур уңыш булды. Бу – безнең абруйлы җитәкчеләребез – Әнвәр Бульхин һәм Вазыйх Мөхәммәтшин казанышы, дип саныйм. Баштагы проектны тикшергәндә миңа, Вазыйх Мөхәммәтшинга һәм Шамил Баһаутдиновка мәктәпнең янкормасы бик кечкенә булып тоелды, бары тик 280 бала гына укый алыр иде. Йөри торгач, 2 катлы мәктәпкә тагын бер этаж өсти алдык. Шулай итеп, 450 укучыга исәпләнгән мәктәп үсеп чыкты.

Мәктәпне ремонтлау һәм янкорма торгызу эшендә Вазыйх Гатовичның тырышлыгы һәм үҗәтлеге зур булды. Ул хәтта үз акчасын да күмәк эшкә күп тотты, вакытын җәлләмәде. Өч ел буе оператив утырышларга йөрдек, энәсеннән җебенә кадәр барысын да тикшереп эшләдек. Нәтиҗәсе дә куандыра – балалар һәм укытучылар йөзендә бүген шатлык балкый.

2013 елда “Яктылык” Россиянең 100 иң яхшы мәктәбе исемлегенә керә алды. Анда үскән талантлы балаларыбыз шәһәр бәйрәмнәрендә, Россия шәһәрләрендә чыгышлар ясыйлар, татар теле олимпиадаларында катнашалар, спортта да, иҗтимагый эшләрдә дә сынатмыйлар.

Татар җәмәгатьчелеге Самарда тагын бер татар мәктәбе ачу турында хыяллана, тик аның өчен Харидә Габдулҗановнадай лидерның һәм татар оешмаларының бертуктаусыз эше кирәк булачак.

## “Таң йолдызлары”

«Таң йолдызлары» – Советлар заманында Пионерлар йортында Халидә Вәлиева җитәкчелегендә барлыкка килгән татар балалары коллективы. Без Рәшит Абдуллов белән мәгариф һәм мәдәният идарәсендә балалар коллективы җитәкчесе өчен бер ставка алу бәхетенә ирешкән идек. Бу коллектив күп татар балаларын үз мәдәниятенә җәлеп итүдә булышты. Тик гомере генә озын булмады, Халидә ханым декрет ялына китү сәбәпле, эшчәнлеге туктатылды.



## Яшьләр канаты

Татар яшьләре “Туган тел” оештырган чараларда, мәчет оештырган өмәләрдә, зиратларны чүп-чардан арындыруда бик теләп катнашалар. Шулай ук Болгарга сәяхәткә бару, Татарстан оештырган яшьләр лагерьларында ял итү кебек күңелле чаралардан да калмыйлар.

Араларыннан иң актив булганнары Бөтендөнья татар конгрессы, Федераль милли-мәдәни автономиясе корылтаенда да, Татар яшьләре форумнарында да катнашалар.

“Туган тел” әгъзалары, югарыда әйтеп үтелгәнчә, милләте, халкы өчен бушлай эшләделәр һәм эшлиләр. Төрле елларда “Туган тел” һәм автономияләр рәисләре булып эшләгән Рәшит Абдуллов, Вазыйх Мөхәммәтшин, Илгиз Колючев, Әнвәр Бульхин, Ильяс Шәкүров, Әнвәр Горланов, Минәхмәт Хәлиуллов, Рифкать Хужин, Фәхретдин Канюкаев, Җәмил Вәлиуллин, Гомәр Батршин, Расих Латыйпов, Фәрхәт Мәхмүтов үз вакытларын, иксез-чиксез энергияләрен һәм акчаларын кызганмадылар.

2012 елдан бирле “Туган тел” җәмгыятен И. Г. Шәкүров җитәкләп килә. Аның килүе белән, “Туган тел” эшчәнлеге җанланып китте.





Самар өлкәсендә гөрләп үткән Бөтенроссия “Түгәрәк” уен фестивале, Федераль дәрәҗәдә үткән Сабан туйлары, “Чаян” журналы юбилее, татар теле олимпиадалары, “Татар кызы” конкурсы, караоке-конкурс, Гакыйль Сәгыйровның 80 еллык юбилее, даими эшләп килүче “Самар татарлары” сайты һәм журналы, татар календаре, татар телен яхшы белгән укучылар өчен Алия Аләветдин кызы Шәкүрова премиясе һәм башкалар – аның казанышлары. Боларның барысы да гаиләсеннән өзеп бирелгән акчага эшләнә.

## Төрле булсак та, ят түгелбез

1993 елдан бирле милли оешмаларга ярдәмне өлкә хөкүмәте һәм шәһәр администрациясе дә бирә. Идел буе округы җитәкчеләре катнашында милли сәясәт мәсьәләләренә багышланган конференциядә башта мин, аннан чуаш милли оешмасы җитәкчесе Валентина Калмыкова чыгыш ясаганнан соң, бераз акча бирелә башлады. Ләкин бу ярдәм генә җитми, чаралар уздыру өчен спонсорлар табарга да кирәк.

Беренче Сабан туйларына керү түләүле булса, Гагарин паркына күчкәч, бу ысулдан баш тартырга туры килде, ул һәр яктан да ачык. Ә бинаяларда уза торган чараларны түләүле ясасак, оештыручыларга җиңелрәк булыр иде. Әле бит конкурсларның җиңүчеләренә бүләкләр, читтән килүчеләр өчен чәй өстәле корырга кирәк. Шуңа күрә халык аңлар, тамаша кылып кына китмәс, арзан бәягә билет алып, оешмаларыбызга бераз ярдәм күрсәтер иде, дип исәплим. Бергә булсак кына, татарлыгыбызны саклап кала алачакбыз. “Туган тел” җәмгыяте 35 ел буе башка милли оешмаларга үрнәк күрсәтеп килә һәм яңа гражданнар җәмгыяте төзелешенә саллы өлешен кертә.

Катлаулы, ләкин халкыбыз өчен бик тә кирәк булган җаваплы эшебездә иң мөһиме – Татарстан Республикасын саклап калу, балаларыбызны татар теле, мәгарифе, мәдәнияте мохитендә тәрбияләү, татар оешмалары тирәсендә күбрәк битараф булмаган милләттәшләребезне туплау, милли эшләр белән кызыксындыру. Аңы булган һәр татар кешесе оешмаларыбызга килсен, үзе өчен нинди дә булса мавыктыргыч юнәлешне сайласын. Эшлим, дигән кешегә эш бар безнең оешмаларда. Уян, татар! Бергә булсак кына, без милләт буларак сакланып кала алачакбыз.

# ЕРАКТАН ЯХШЫРАК КҮРЕНӘ

## Татар телен һәм мәдәниятен саклап калуны колачлаган милли хәрәкәте башы

***35 ел элек, 1989 елның 21 гыйнварында, Куйбышев шәһәрендәге Яшьләр йортында, яңа тарихта беренче мәртәбә татар җәмәгатьчелеге җыелышы уздырылып, “Туган тел” милли-мәдәни оешмасына нигез салынды. Залда ике йөзләп татар активистлары җыелган иде.***

***Шамил Галимов***

“Хөрмәтле иптәшләр, сезне бу җыелышка чакыруыбызның сәбәбе - Куйбышев өлкәсендә татар теле һәм мәдәнияте торышы. Өлкә татарлары проблемаларына башка күзлектән чыгып карарга һәм аларны хәл итү юлларын табарга тиешбез...

Әлеге җыелыш татар җәмәгатьчелеге эшчәнлеген координацияли алсын өчен, бердәмлек һәм оешканлык күрсәтеп, милләтебез өчен хезмәт итә алуыбызны өлкә җитәкчелеге каршында исбатларга тиеш булачакбыз...” – дип башлады сүзен инициатив төркем җитәкчесе, юрист Шамил Әхмәров.

Милли үзаң Михаил Горбачевның социалистик системаны үзгәртеп кору программасы нигезендә күтәрелеп китте - бөтен тарафларда да иҗтимагый оешмалар барлыкка килә башлады, Урта Азия, Кавказ республикаларында хәтта милләтара ызгышлар да килеп чыкты. Милли интеллигенцияне аз санлы халыкларның телләрен саклап калу һәм укыту проблемасы борчый иде. Бу турыда без “Бердәмлек” газетасының үткән елгы 49 санында язып чыккан идек инде.

Куйбышевның Яшьләр йортында узган беренче җыелыш аннан алда булган берничә вакыйгага бәйле. 1988 елның җәендә тарих факультеты доценты М.А. Мөлеков (1930 - 1997) җитәкчелегендәге Казан фәнни интеллигенциясе “Үзгәртеп кору хәрәкәтен хуплаучы Татар иҗтимагый үзәге”н оештыру тәкъдиме белән чыкты.

Куйбышевта исә халык хәрәкәте төптән башланды. Аның башында “Ялкынлы яшьлек» ансамбле һәм Малый тупиктагы мәчет мәхәлләсе тора иде. Шул ук 1988 елда ике мөстәкыйль инициатив төркем берничә ай буе җыелышлар үткәрәләр, татар халкының ихтыяҗларын билгелиләр, киләчәккә планнар коралар, ләкин аларны тормышка ашыру өчен өлкә хөкүмәтенә мөрәҗәгать итәргә кирәк булуын да яхшы аңлыйлар.

Бишенче декабрьдә Аврора урамы, 169 йорт адресы буенча яшәгән Фаикъ Фәрукшин фатирында бу ике төркемнең берләштерелгән утырышы уза. Анда һәм декабрь – гыйнвар айларында узган җыелышларда үткәреләчәк чаралар планы, КПССның өлкә комитетына һәм өлкә Башкарма комитетына татар милли-мәдәни җәмгыяте максатлары һәм бурычлары күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм ярдәм күрсәтүләрен сорап язган хат кабул ителә һәм тиешле инстанцияләргә җиткерелә. Оештыру комитетының беренче рәисе итеп Шамил Әхмәров сайлана. 1989 елның 21 гыйнварында оештыру комитеты Яшьләр йортының актлар залында узачак татар җәмәгатьчелегенең беренче зур утырышына әзерләнә башлый.

Унынчы гыйнварда заводлар проходнойларында, шәһәр транспорты тукталышларында татар җәмәгатьчелеге утырышы уздырылачагы турында афишалар эленә. Аларны Азат Надиров ясап күбәйтә. 18 гыйнварда җомга намазында бу турыда имам Вагыйз хәзрәт Яруллин да хәбәр итә, халыкны җыелышта катнашырга чакыра.

Ул вакытта әле татар газетасы да, радиосы да юк иде. “Волжская коммуна”, “Волжская заря”, “Волжский комсомолец” газеталары гына татарлар тормышын яктыртып торалар иде. Бүген сезнең игътибарыгызга Рәфгать Әһлиуллинның 1989 елның 9 февралендә “Волжская коммуна” газетасында басылып чыккан язмасы оригиналын тәкъдим итәбез.

«Деятельность татарского культурного центра предполагается развернуть по нескольким целевым направлениям: научно-исследовательской, учебно-воспитательной, производственно-бытовой, организационно-пропагандистской и т.д.

Выступившие на собрании инженер Азат Надиров, журналист Шамиль Галимов, руководитель ансамбля «Ялкынлы яшьлек», заслуженный работник культуры РСФСР Ильгиз Колючев, имам-хатыб религиозного общества мусульман города Куйбышева Вагиз Яруллин и многие другие горячо поддержали идею, цели и программу татарского национального культурного центра при Доме молодежи, высказали свои мнения и предложения. Среди самых актуальных называлась проблема изучения родного языка. Во многих селах преподавание татарского языка пошло на убыль, наметилась тенденция к сокращению числа национальных школ. А в областном центре и других городах, несмотря на актуальность, эти вопросы даже не поднимались...

На собрании также говорилось об изучении возможности создания в области национальных газет или приложения к областной газете, организации и регулярных радио- и телепередач на татарском и других языках народов Поволжья. Уже сейчас, оказывается, есть возможность для того, чтобы хотя бы в субботние и воскресные дни показывать куйбышевцам и жителям других населенных пунктов передачи татарского телевидения. Но для технического решения вопроса требу-

ются определенные средства».

КПСС өлкә комитеты газетасында басылып чыккан язмага карап, татарларны нинди проблемалар борчыганы, тормышыбызны үзгәртеп кору эшләренең нәрсәдән башлануы турында фикер йөртә һәм соңгы 35 ел эчендә нинди нәтиҗәләргә ирешүебезне күзаллый алабыз.

Җыелышта Куйбышев өлкә комитеты консультанты Рәшид Шакиров, беренче секретаре Владимир Сластенин, Яшьләр йорты директоры Владимир Петров, Яшьләр үзәге директоры Александр Мескин, өлкә мәдәният бүлеге начальнигы урынбасары С. А. Бевзенко, өлкә мәгариф бүлеге баш белгече Дамир Гатин, өлкә яшүсмерләр китапханәсе директоры Разия Букина һәм башка мәдәният учреждениеләре һәм хөкүмәт органнары вәкилләре катнашты. Алар татар мәдәнияте үзәге булдыруны хупладылар һәм ярдәм күрсәтергә әзер булуларын белдерделәр. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк - алар сүзләрендә тордылар.

Шулай ук газетада басылып чыккан мәкаләдә Казан тапшыруларын трансляцияләү турындагы юлларына туктальп үтәсе килә. Эш шунда ки, әле 1987 ел ахырында “Прогресс” заводының һәм ЦСКБның берничә хезмәткәре - М.Сәгыйров, Ш.Галимов һәм М.Ямалетдинов бу мәсьәлә буенча Телевидение һәм радиовещание буенча Куйбышев өлкә комитеты җитәкчесе Ю.В. Котовка һәм өлкә радиотапшыруларын трансляцияләү техник үзәгенә мөрәҗәгать иткәннәр иде. Анда телетрансляцияләр өчен абонент түләү формасын тәкъдим иттеләр. Шул чакта ук Куйбышев өлкәсендә Казан тапшыруларын күрсәтү мөмкинлеге булган бит! Бу турыда сөйләшүләр бик озак, беренче җыелышка кадәр алып барылды һәм залда җыелган халыкка да бу турыда хәбәр итәргә мөмкин булды. Дөрес, инициатива бу этапта без теләгән нәтиҗәгә китермәде.

Бер генә яхшы ягы булды – без Куйбышев радиоүзәге директоры Николай Бакумов белән таныштык һәм нәтиҗәдә, безнең соралуыбыз буенча, күпмиллләтле “Радио-7” тапшырулары эфирга чыга башлады.

...Беренче җыелышка кайтыйк инде. Шул көнне үк закон буенча кирәк булган бөтен юридик чаралар күрелде һәм “Туган тел” өлкә татар мәдәният үзәге теркәлде. Аның Советына юрисконсультлар Ш.Әхмәров, Д.Субеева һәм Ә.Әбдерәфыйков, инженерлар - Р. Абдуллов, Э.Кәбиров, А.Надиров, Ә.Нәфыйгин, укытучылар Л.Галиева, Р.Сәйдуллаев, “Прогресс” заводы газетасы хәбәрчесе Ш.Галимов, ЗиМ хезмәткәре А.Вәлишев, журналист Ф.Давыдов, авиаотряд штурманы Ф.Фәрукшин, “Сезон” кооперативы рәисе урынбасары Р.Яһудин, табиб Г.Сәйхетдинов, автобус йөртүче М.Сафин һәм пенсионер Ф.Вәлиева керделәр.

Икенче көнне үк, 22 гыйнварда, Үзәк эшләп тә китте. Яшьләр йортының 26 санлы бүлмәсендә татар телен һәм мәдәниятен саклап калырга һәм үстерергә теләгән татарлар җыелды.

Мансур Ямалетдинов, Эльсор Кәбиров, Равил Яһудин, Асия Ногманова һәм башкалар. Шулар арасында, әлбәттә, милли хәрәкәт башында торган активистлар да бар иде.

17 – 18 февральдә Вагыйз Ярullин, Идеал Галәветдинов, Әлфия Гыйниятуллина, Мурат Сафин, Фаикъ Давыдов, Шамил Әхмәров, Равил Яһудин һәм Диларә Габбасова Казанның Галиәсгар Камал театрында рух күтәренкелеге мохитендә узган Бөтенсоюз иҗтимагый үзәге җыелышында катнаштылар. Куйбышевта татар милли үзәге оешу турындагы хәбәр киң җәмәгатьчелеккә җиткерелде. Союз татарлары бу хәбәрне көтеп алынган могҗизадай каршы алдылар.

3 февральдә “Аврора” клубында узган беренче очрашу кичәсенә 200ләп кеше килгән булса, 27 февральдә инде меңләгән татар Куйбышев Авиация заводы спорт сараенда оештырылган Кышкы Сабан туенда күңел ачтылар. Шул ук вакытта, Харидә Дашкина тәкъдиме буенча, кичке татар мәктәбен, татар газетасын ачу буенча эшләр алып барылу турында хәбәр ителде.

1989 елның язында “Туган тел” оешмасына Минәхмәт Сәгыйров, Әлфия һәм Фәрхәт Мәхмүтовлар, Гөлсинә Нуруллина, Марат Гыйбадуллин килеп кушылдылар, 16 апрельдә Киров Мәдәният сараенда гөрләп үткән “Уйна, гармун!” фестивален алып барган Шамил һәм Наилә Баһаутдиновларның дебюты булды. Шуннан соң алар егерме ел буе бөтен татар чараларын алып бардылар, “Радио-7” тапшырулары өчен сценарийларын яздылар, режиссерлар һәм алып баручылар булдылар. Ә беренче чараларның берничәсен Әлфия Гыйниятуллина, Идеал Галәветдинов, Раилә Галәмова-Сафиналар алып барганнар иде.

Оешмага яңа әгъзалар даими рәвештә килеп тордылар: Илгиз Колючев, Шәүкәт Хәйбуллов, Рәфыйк Әбдиев, Гали һәм Хәйдәр Гәрәевлар, Илшат Каюмов, Асия Әхмәтова, Марат Әхтәмов, Наил Хәлиуллин, Гүзәл Ямалетдинова, Лилия Әбдерәфыйкова, Наилә Зимукова, Резеда Бадыйкова, Вилия Хәйбуллина, Нияз Хәбибуллин, Раушания Минһаҗева, Рәисә Гыйбадуллина, Ринат Шәрифуллин, Нил Шамаков, Назыйф Ибраһимов, Мәзгуть Шакмаев, Фәһимә Рәҗәпова, Розалия Хәлилуллова, Әкълимә Кантемирова, Сәрия Маннанова, Салих Вәлиәхмәтов, Әсфәндияр Вәлитов, Җәүдәт Борһанов, Рәфыйк Шәфигуллин, Флорида Локманова һәм башкалар. Өстә атап үтелгән кешеләрнең бер өлеше бүген дә, милли чараларда катнашып, татар тормышына күпмедер өлешен кертеп торалар.

Ерактан яхшырак күренә, дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр картлар. Вакыт узгач кына, 35 ел элек булган беренче җыелышның әһәмиятен күзалларга мөмкин.

Чираттагы иҗтимагый оешма ачылу гына түгел иде ул, Самар өлкәсендә татар телен һәм мәдәниятен саклап калуны колачлаган татар милли хәрәкәте башы иде.

***Иске Ярмәк авылы үзендә туып-үскән кешеләр арасында тормышта һәм хезмәттә дан казанган шәхесләрнең күплеге белән дә горурлана ала.***

***Шуларның берсе - Нурфатыйх улы Фаил Гарифуллин. Әле җитмеш яшендә дә ул зур җаваплылык таләп иткән җитәкче вазыйфасын башкара.***

*Фәрид Шириязданов*



# Кешенең үзкыйммәте аның эшендә һәм тормышында ачык күренә

Хәзерге вакытта Фаил Гарифуллин Яр Чаллы шәһәрендәге «Стройтехком Холдинг» дип аталган компанияләр берләшмәсендә башкарма директор урынбасары булып эшли.

Юбилее уңаеннан шул шәһәрдә чыгып килгән «Строительная газета»ның бер саны тулысынча аның хөрмәтенә багышланган. Монда алар башкарган зур-зур корылышлар турында да язылган. Фән һәм техника нык алга киткәндә зур корылышларның күз иярмәслек тизлектә баруы хәзер инде гадәти күренешкә әверелеп бара. Үткәндә туздырып ташланган илебезнең, аякка басып, зур һәм кыю проектларны гамәлгә ашыруына да күнегә башлаган идек.



Эш урынында

Ләкин дә сугыш барышында илле алты бай, гайрәтле илләрнең санкцияләре астында тиз арада зур әһәмияткә ия булган заводлар төзелеп, аларның тылсымга тиң тизлек белән эшли башлавы - әкияттәй гаҗәеп күренеш. Фаил Гарифуллин эшләгән оешма менә шундый зур эшләр башкаручы данлыклы компанияләр исәбендә.

Юбилей вакытында яисә башка тантаналы көннәрдә хөрмәткә лаеклы кешеләрне зурлау - күркәм гадәт. Бу газетада да дәрәҗәле кешеләр һәм якыннары тарафыннан Фаил Гарифуллинга тирән ихтирам, олы хөрмәт хисләре белән сугарылган сүзләр язылган:



«Стройтехком Холдинг»ның элгәреге генераль директоы **Харис улы Илдар Фәйзерахманов:**

“Фаил Нурфатыйхович Гарифуллин безгә 2004 елда эшкә килде. Үзендәге кешелек һәм эшчәнлек сыйфатлары белән ул баштан ук минем игътибарны үзенә җәлеп итте. Менә инде егерме ел аның белән бергә эшләү дәверендә без көчле коллектив тупладык һәм югары нәтиҗәләргә ирештек.

2023 елда безнең компания үзенең 25 еллыгын билгеләп үтте. Без эшли башлаган чор - зур-зур төзү компанияләре, төзү оешмалары күплеге белән танылган вакыт. Мондый көчле конкуренция шартларында югалмас өчен без, гадәти булмаган эш тәртибе, яңа алымнар кулланып, эшне тамырдан үзгәртеп кору максаты куйдык.

Хәзер инде безнең «Стройтехком Холдинг» компаниясенең эшчәнлеге Краснодардан алып, Владивостокка кадәр уңышлы бара.

Ә безнең уңышларның төп сере - эшебездә «командный подход» булуы. Һәр кешегә, монда үз хезмәтенә иҗат күзлегеннән карап, акыл белән эш итү өчен киң мөмкинлекләр бирелгән. Кемне дә кулыннан тотып, төрткәләп йөртү юк. Әлбәттә, һәркемнең үз эшен белеп эшләргә әзер булуы да монда зур роль уйный.

Эшебез уңышлылыгының икенче сере, иң элек, дөрес максат куя белүгә бәйләнгән. Ә максат куелдымы, бар куәткә аны гамәлгә ашыру өчен төгәл план булдыру кирәк.

Монда без килешүләрне, аларны үтәү мөмкинлекләрен, срокларын, материаллар булдыру графигын

һәм башка мөһим мәсьәләләрне команда белән, бергәләп хәл итәбез. Бөтен планнар, графиклар һәр җирдә күз алдына эленгән.

Без үзебездә тупланган тәҗрибәне, мөмкинлекләребезне тагын да үстерү һәм аларны уңышлы куллану өчен яңадан-яңа эш алымнары булдырырга да тырышабыз.

Иң мөһиме - нинди генә катлаулы объект булмасын, без аны тулысынча үзебез эшләргә тырышабыз. Безнең төп максатыбыз - корылган заводның яисә башка корылышның ачкычын тантаналы рәвештә заказчиклар кулына үзебез тапшыру.

Нинди генә эш объекты алсак та, машина төзүгә бәйләнгәнме, малчылык комплексымы, медицинага кагылышлымы – без, иң элек, бу эш тармагының нечкәлекләрен өйрәнәбез.

Эш дәверендә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе - куркынычсызлык таләпләрен төгәл үтәү. Шулай ук башлаган эшне ахырынача югары сыйфатлы итеп башкару.

Шуңа да КамАЗ, Соллерс кебек заказчиклар безгә иң зур һәм җаваплы эшләр башкаруны тулы ышаныч белән тапшыралар. Мәсәлән, Алабуга, Яр Чаллы, Ульяновск, Владивосток шәһәрләрендә без автопром системасындагы за-




водларны иң кыска срокларда төзедек.

Хәзерге вакытта «Стройтехком Холдинг» бер үк вакытта Алабуга, Ижау, Калуга, Казан, Мәскәү, Яр Чаллы, Түбән Кама, Ульяновск һәм башка шәһәрләрдә 14 - 15 проект буенча җитди эшләр алып бара".

**Рөстәм Шәгитович Сабиров -**



**«Стройтехком Холдинг» компанияләр берләшмәсендә баш инженер:**

"Фаил Гарифуллинның җаваплылыгы һәм бар булдыгы белән үз эшенә бирелгән булуы, кешелеклелеге турында күп мисаллар китерергә була. Илебезнең кайсы өлкәләрендә генә эшләсәк тә, аңа иң җаваплы эшләр йөкләнә иде. Барысыннан да алда килеп, иң ахырдан киткү, күп вакытта кунакханәгә дә кайтмыйча, эш урынында куна ятып эшләү аның өчен гадәти күренеш иде.

Хезмәткә бирелеп, үзеңне аямыйча эшләү - ул бер хәл. Ә менә үзең җитәкләгән коллективны уңай эшкә көйләп, югары нәтиҗәләргә ирешү өчен бик күп нәрсә кирәк. Бигрәк тә эшнең бөтен нечкәлекләрен белү, бай эш тәҗрибәсе булу, коллективта уңай микроклимат тудыру һәм башкалар.

Фаил Нурфатыйховичта бу сыйфатларның барысы да мул тупланган. Кирәк вакытта ул акыл өйрәтерлек «мулла» да, нәтиҗәле эшләр башкарырга рухландыручы «парторг» та, җиңеп булмастай авырлыкларны җиңүгә әйдәп баручы батыр командир да.

Объектка килү белән, бер карауда, ул бар булган, хәтта күзгә күренмәгән җитешсезлекләрне дә күрә белә. Шуңа да аның янында буш сүзләр сөйләү, нигезсез аклanулар булуы һич тә мөмкин түгел.

Моның өстенә, ул проблемаларны алдан күрә белгән һәм катлаулы мәсьәләләр чишелешен дә алдан күрә белүгә сәләтле җитәкче һәм остаз.

Хәзерге вакытта зур һәм катлаулы конструкцияләр төзегәндә җитәкчегә аеруча зур җаваплылык йөкләнә. Моны мин хирург эше белән чагыштырыр идем. Кемнеңдер тарафыннан эшләнгән, кечкенә генә күренгән җавапсызлык та монда зур фаҗигаләргә китерергә мөмкин бит.

Кайсы гына җиргә барып, нинди генә халыклар белән эшләмәсен - ул бар җирдәге эш урыннарында да төгәл тәртип урнаштыра. Эш куркынычсызлыгының кагыйдәләрен төгәл үтәүне катгый таләп итә.

Фаил Нурфатыйхович һәрнәрсәнең чамасын төгәл белеп эш итә: авыр чакта рухландыра да, кирәк чакта таләпчән булып хурландыра да. Шул ук вакытта ул киң күңелле, үз кеше булып аралаша да белә. Ул әле юморны да оста куллана.

Шул ук вакытта ул - акча белән



КамАЗ кабиналары заводы

төгәл эш итә белгән хуҗа да. Кысмыр булып күренсә дә, кирәк вакытта тәвәккәлли дә белә. Мәсәлән, Ерак Көнчыгышта Соллерс автомобиль корпорациясе биналарын төзегәндә, иң кирәкле материаллар булмау сәбәпле, аларны хәтта самолёт яллап Мәскәүдән китерергә туры килә.

Без кайвакытта ташланган биналарны да ремонтлап һәм киңәйтеп, аларны яңадан эшкә җибәрәбез. «Искегә тимә, исең китә», - диләр. Монда күзгә күренмәгән җитешсезлекләрне дә белеп, искергән биналарны нык тикше-










реп эш итәргә туры килә.

Безгә элгәре су асты көймәләре төзегән заводның ташланган биналарын яраклы хәлгә китереп, аңа өстәмә корылма төзү бурычы куелган иде. Бинаның су асты өлешен тикшергәч, аның металл конструкцияләре шактый черегән булуы беленде. Салкыннар башланган булса да, водолазлар яллап, шактый күп сварка эшләре башкарырга туры килде.

Гомумән, Фаил Гарифуллин - җаваплылыкны үз өстенә алып, зур эшләр башкарырга сәләтле белгеч һәм оста җитәкче.

Илдәге төрле җирләрдә ул башкарган эшләрнең географиясен картадан карасаң - аның Краснодардан алып, Владивостокка кадәр җәелгәне күренә.

Ул һәрвакытта үз-үзенә дә, башкаларга да таләпчән, әйткән сүзенә тугрылыклы була белде һәм белә.

Нинди генә буталчык, авыр заманнар булмасын - ул үз кыйбласын югалтмады һәм үзе сайлаган юлдан тайпылмады.

«Бер көнлек», алдакчы фирмалар күбәйгәндә дә ул эшләгән фирма 20 елдан артык дәвердә үз исемен дә алыштырмады, телефоннары да шул ук калды. Димәк, монда аның ышанычлылыгы турында артык сүз дә кирәкми.

Аның җитмеш яшендә дә шундый җаваплы эштә булуы да күпне аңлата. Аны без әле дә үзебезнең тәҗрибәле остазыбыз һәм акыллы киңәшчебез, дип саныйбыз һәм лаеклы рәвештә хөрмәт итәбез".

Хыяллар да колачлый алмастай үзгәрешләрне күргәндә халкыбызның үҗәтлеге аеруча куандыра.

Мәсәлән, «Стройтехком Холдинг» компанияләр берләшмәсенә Владивостокта «иномарка» машиналар эшләп чыгару заводы төзү йөкләнә. Бу эшне башлаганда ук, Рәсәй Президенты В.В. Путин Италия башлыгы Антонио Берлускони белән әңгәмәсендә аңа заводны дүрт ай эчендә сафка бастырып, машиналар чыгара башлау планнары турында сөйли.

Италия президенты бу хыялның чынбарлыкка туры килмәвен белдереп көлгәч, алар «пари» төзиләр. Нәтиҗәдә дүрт айдан соң В.В. Путин чиксез гаҗәпләнгән А. Берлусконига конвейердан чыккан беренче автомобильне бүләк итә.


Ерак Көнчыгышта Соллерс җыю цехы

Алабуга махсус икътисади зонасында (LCV) Ford Transit маркалы җиңел йөк машиналары чыгарганда АКШтагы Ford Motor Company фирмасы монда катнашып эшләүдән баш тарта. Производство туктагач, бер мең кеше эшсез кала.

Мондый авыр хәлдә дә бу холдинг югалып калмый һәм Алабугада тиз арада яңа бренд - LCV моделеның «Соллерс» маркасын быел ук чыгара башлау күз алдында тотыла.

Санкцияләр тудырган мондый һәм башка юнәлешләрдәге эшләрне тамырдан үзгәртеп кору барышындагы иң җаваплы корылыш эшләрен гадәттә «Стройтехком Холдинг» компанияләренә ышанып тапшыру аның репутациясен төгәл билгели.

Татарстан Республикасының югары үсеш юлында булуы һәм аның төрле өлкәләрдә ирешкән казанышлары хәзер инде бөтен дөньяга билгеле. Рәсәйдәге илле «Махсус икътисади зона» арасында Татарстандагы Алабуга икътисади зонасының (свободная экономическая зона) хәзер иң алгы позициядә торуы аеруча шатландыра. Анда Сингапурдан килгән



Иске Ярмәктә. Әнисе, балалары, оныклары белән




Тантаналы җыелыштан соң

«Экономическое чудо»ның «атасы» Ли Кван Ю, исе китеп:

«Кыска вакытта сезнең мондый прогресска ирешүегезгә мин хәйран калдым. Үз резидентларыгызга киң мөмкинлекләр бирү сезне әле тагын да югарырак нәтиҗәләргә китерәчәк!» - дигән.

«Стройтехком Холдинг» компаниясенең төрле регионнарда башкарган җитди эшләре бик күп. Тик Рәсәй күләмендә иң хәлиткеч һәм зур әһәмияткә лаек булган тө-




зелештә катнашуы турында телгә алмыйча булмый.

Ул - «Этилен 600» проектына кергән Ден Сяо Пин исемендәге Рәсәй күләмендәге иң зур логистика комплексы.

Биредәге төяү-бушату өчен каралган мәйданның озынлыгы бер километр тәшкил итә. Ул бер елга 100 мең контейнерлар составы кабул итәчәк. Монда тулы составларны берьюлы төяү-бушату һәм сортировка эшләре алып бару мөмкинлеге каралган.

Ден Сяо Пин логистика комплексы кергән “Этилен 600” терминалы - Рәсәйдә бердәнбер индустриаль парк.

Бу проект Алабуга икътисади зонасы һәм ПАО Камнефтехим берләшмәсе арасындагы килешү нигезендә төзелгән. Ул, Кытай белән турыдан-туры элемтәдә булып, анда нефтехимия товарлары җибәреп, аннан безнең илгә кирәкле товарлар ташылачак.

Ден Сяо Пин логистика проекты 2024 елның июнь аенда беренче составны кабул итәчәк. «Стройтехком Холдинг» компанияләр берләшмәсе монда да иң җаваплы эшләр алып бара.

Рәсәйдә автопром системасын яңа эзгә салучы «Соллерс» һәм «Аурус» компанияләре эшчәнлеге монда аеруча зур игътибарга лаек. Андагы нәтиҗәле эшләрне шулай




ук Яр Чаллы шәһәрендәге «Стройтехком Холдинг» компанияләре эшчәнлегендә дә ачык күреп була. Бу корпорациядә якташыбыз Нурфатыйх улы Фаил Гарифуллинның директор урынбасары булып эшләве безгә көтелмәгән матур яңалык булды.

Ул, Төньяк Себердә, Бурятиядәге Лебединоозёрск ГЭСын төзүдә һәм Рәсәйнең башка төбәкләрендәге зур корылышларда бай тәҗрибә туплаган җитәкче, оста белгеч булырак, әле дә алыштыргысыз остаз булып исәпләнә.

Үз тәҗрибәсен яшьләргә дә җиткерүен сорагач, ул әле бүген дә, җитмеш яшендә, җиң сызганып эшләп йөри.

Аңа киләчәктә дә уңышлы эшләр, исәнлек-саулык телибез.



# Иногда человека надо просто выслушать, и ему сразу станет лучше

***В Самаре 19 февраля прошло очередное заседание регионального Совета главврачей местных клиник, на котором присутствовал губернатор Самарской области Дмитрий Азаров. Помимо актуальных вопросов реформирования системы здравоохранения региона, на Совете прошло награждение врачей, работавших на СВО, почетным знаком Самарской области «За служение людям». Этот знак из рук губернатора получил и заведующий отделением неврологии Самарской городской клинической больницы № 8 Эдуард Шакуров, у которого за плечами несколько командировок в Донбасс в качестве врача одной из клиник под Донецком.***

Сейчас Эдуард Хабибович без всякой доли лукавства говорит, что все его самые несбыточные, казалось, мечты осуществились и давно пора ставить новые, недостижимые жизненные ориентиры, а ведь когда-то он и не планировать связывать свою жизнь с медициной. Стремился, как и многие его сверстники, изучать компьютеры и программирование. Но вмешался несчастный случай…

Впрочем, обо всём по порядку.

– Родился я в феврале 1986 года в Бугуруслане Оренбургской области, но тот период своего детства совсем не помню, поскольку я был ещё младенцем, когда родители переехали в Камышлу, – вспоминает наш собеседник. – Там, собственно, жил и рос до окончания школы.

***– С детства мечтали стать врачом?***

– Нет. Хотел стать компьютерщиком и даже поступил в местный техникум, но попал под машину и очутился в областной больнице, ныне им. Середавина. Долго пролежал, делали операцию, спасали ногу после ДТП. И там я стал замечать, как люди относятся к врачам, смотрят на них словно на спасителей, некую миссию. С большим уважением. Там-то программист во мне и умер. Я действительно захотел стать врачом, и конечно же, травматологом. Поступить в Самарский медуниверситет не получилось, да я и не питал на этот счет никаких надежд. Вырос в простой семье: мама – повар в школьной столовой, отец – электрик в Камышле, откуда деньги на престижный вуз? Поэтому окончил я медицинский колледж, и первая запись в моей трудовой датирована 2003 годом – младший медбрат отделения реанимации кафедры травматологии, ортопедии и экстренной хирургии того самого медуниверситета. Потом перешел фельдшером на скорую помощь, где в общей сложности проработал 12 лет. Это грандиозная школа для молодого специалиста. Там я на практике приобрел, по сути, сразу





несколько квалификаций – и травматолог, и терапевт, и невролог. На скорой я впервые себя почувствовал, как говорят, мастером разговорного жанра, что впоследствии и сыграло главную роль в выборе профессии невролога. Ведь нам очень важно наладить тесный контакт с пациентом, понять – как он мыслит, что его беспокоит, пропустить его эмоции и переживания через себя и найти правильные слова для снятия этого волнения. Иногда человека надо просто выслушать, и ему сразу станет лучше.

***– А как стали дипломированным специалистом?***

– Тема института постоянно витала в воздухе. Я понимал, что для построения нормальной карьеры врача нужен диплом о высшем образовании. Но годы шли, а поступать я так и не решался, видимо, работал какой-то штамп недосягаемости этого диплома, пока на очередной медицинской конференции, заведующая Кировской станцией скорой помощи Валентина Ивановна, меня строго так не спросила: «Ты вообще собираешься получать высшее образование?» И даже после этого были сомнения. Я думал, когда окончу университет – мне будет уже 31 год, но 31 мне всё равно исполнится, только если поступлю, то буду с дипломом, а если откажусь – без него. В итоге – решился.

***– Почему поступили именно в университет «Реавиз», а не в классический медицинский?***

– Дело в том, что там разрешали совмещать работу и учебу. Точнее, смотрели на это лояльно. А позволить тогда себе чистое обучение я не мог. Нужно было что-то кушать и во что-то одеваться. В моей группе почти все учились и работали. Получали, так сказать, помимо знаний еще и практический опыт. В итоге в 2017 году я окончил факультет «Лечебное дело» в «Реавизе», а еще через два года ординатуру Самарского медуниверситета по специальности «Неврология». С этого времени тружусь с горбольнице № 8 с небольшими перерывами и принимаю также в клинике «Доверенный доктор». К слову, в этом году мне впервые нужно будет пройти переаттестацию, поскольку прошло 5 лет после ординатуры. Вроде срок не сильно большой, но за это время в отделении сменилось уже два состава врачей. Текучка какая-то аномальная, народ приходит,



нарабатывает какой-то минимальный опыт и уходит либо на повышение, либо в частную медицину. Сейчас идет серьезная борьба за кадры. Практически во всех городских клиниках огромный дефицит специалистов. Про село и говорить нечего.

***– Вы постоянно работаете в горбольнице № 8. Второй дом?***

– Можно и так сказать. Эта больница изначально называлась «Первая медсанчасть», потом девятая, а потом вошла в состав восьмой клинической больницы, когда в нашей медицине был тренд на укрупнение и слияние. Наша больница считается одной из самых больших в Самаре, если судить по коечному фонду, и обслуживает два самых населенных района города – Кировский и Промышленный. То есть потенциальных клиентов под 700 тысяч человек. Только в нашем неврологическом отделении 60 коек.

***– Практически сразу после вашего выпуска планету накрыл ковид. Какая уж тут неврология?***

– Нет, мы в основном работали по своему профилю. Конечно, была переориентация на ковидный госпиталь. Нам буквально за три дня до часа «Х» объявили: делаем ковидарий. Собрали весь персонал и сказали: кто согласен работать в «красной зоне» одной из семи больниц, пишите заявления. Составили списки. Практически все согласились. Прошли экстренное

обучение по работе на ИВЛ, по лечению инфицированных больных, но работы по основному профилю только прибавилось. Ковид это такая штука, которая постоянно дает осложнения. Поэтому были инфаркты, инсульты, нарушения функции памяти, пропадало обоняние и т. д. Все эти случаи проходили через наше отделение. Через какое-то время первая волна вируса отступила, и мы начали нормально работать, но в 2022-м снова пришлось менять ориентацию. Сейчас вроде ковидные войны остались в прошлом.

***– Но подоспела другая военная реальность.***

– Да. Мне часто задают вопрос – как я оказался в зоне СВО? Все было довольно прозаично. Был набор тех, кто хочет поработать в ДНР, врачом. Можно было добровольно записаться. Я написал и забыл. Через какое-то время звонок из министерства – когда готовы поехать? Да хоть сейчас! Сейчас не надо, нужно через три дня. Не вопрос – собрался и поехал. Предварительно меня здесь уволили (таков порядок) и зачислили в отделении для оказания помощи на СВО. Там практически все идейные врачи были. Хотели в первую очередь помочь людям, стране, но и прочувствовать всё изнутри, увидеть своими глазами. Работали в клинике под Донецком. Это гражданская больница, раненных с фронта привозили редко, в основном лечили мирное население. Там сразу замечаешь разницу в качестве медицинской помощи. Медицина в том городе, где мы работали осталась на уровне восьмидесятых годов прошлого века. Диагностику я проводил в основном посредством молоточка, которым вам невролог по коленке стучит. Что бы сделать глубокое обследование с рентгеном, МРТ, КТ, УЗИ – нужно больного вести в Донецк, где есть вероятность попасть под бомбежку. Вот и думаешь: МРТ пациенту сделать или живым остаться. У меня была ситуация, когда я отправил больного на анализы, а он там под обстрел попал. Приехал и говорит: доктор, вы меня лечите или наоборот?

***– Получается, в пригородах Донецка сейчас безопаснее, чем в городе?***

– Да. Даже в самом Донецке есть по районам градация по безопасности. В тех, которые ближе к Авдеевке и Работино, прилеты чаще, чем в других. Хотя канонада слышна везде, но на повседневную жизнь горожан это практически никак не влияет. Здесь люди по звуку могут определить – вот пусковая на той стороне сработала, вот ПВО включились и сбили ракету или дрон, а вот ПВО не справилась – будет прилет, но не сюда, километра 2–3 в сторону, значит, и волноваться не стоит. Но все равно страшно. Как-то летом, в одну из моих командировок, ВСУ постоянно целили в местный комбинат, где располагался арсенал с боеприпасами. Атаки долгое время отражали, но в какой-то момент они пробили ПВО, и ракета взорвалась рядом с арсеналом. Вокруг нас дрожала земля, был ужасный грохот, снаряды взрывались несколько часов, а мы, несмотря на страх, всё это пытались заснять на видео. Наверное, какая-то отличительная черта самарского менталитета, когда интерес перевешивает всё остальное.

***– Долго оставались в зоне СВО?***

– В общей сложности около полугода. Одна командировка длится 2 недели. В первый приезд я сразу остался на два срока, потом на семь. Так правильно, пациенты к тебе привыкают, команда









врачей складывается, курсы лечения иногда затягиваются и нужно людей довести до полного выздоровления. Ко мне там претензий не было, наоборот, все были довольны моей работой. Да и я сам переключился немного и отдохнул от своих самарских забот. Ты там живешь по сути, как в скаутском лагере. Всё расположено на территории больницы. Медгородок такой. И стационар, и поликлиника. Пришел человек на прием, если нужна госпитализация – тут же определили. Жили мы в палате хирургического отделения, а в соседнем корпусе я работал. Периодически выезжал на вызовы в другие населенные пункты к тяжелым больным. В принципе, нормальная работа врача, только иногда бомбы взрываются. Если же говорить об эмоциональных впечатлениях, то это, конечно, восхищение людьми. Несмотря на практически десятилетнюю войну они запредельно добрые, открытые, общительные, отзывчивые. И хорошо откликаются на открытость и доброжелательность с твоей стороны. Даже лучше выздоравливают на позитиве. А здесь, в Самаре, иногда надо прямо биться за человека, и всё равно пациент останется недовольным. Потому что избалованные. Там в первый раз, когда приехал, чуть ли не на руках носили. Очень хорошее отношение. Огромное количество друзей приобрел. Уговаривали остаться, предлагали, квартиру, отделение, карьерный рост. Но нет, мне сюда надо было вернуться, к семье, к дочке Еве. Ей шесть лет.

***– Вы вернулись в свою же больницу?***

– В первый раз да. После второй командировки пригласили в дорожную клинику, но там я всего месяц проработал. Позвонили из восьмой больницы и предложили возглавить неврологическое отделение. Я не стал отказываться. Это случилось год назад, и теперь 85% времени я провожу здесь. Занимаюсь всем подряд и ремонтом, и подбором персонала, и хозяйственными вопросами, и коммуникациями с главврачом. Хочу выстроить работу по самому высокому стандарту. Но это очень тяжело. Нагрузка колоссальная. В подчинении сейчас 22 человека, и вся ответственность на мне. Раньше отвечал только за себя, теперь этот номер не пройдет. Но энтузиазма и сил добавляет позитивная атмосфера, которая установилась здесь в клинике. Во-первых, у нас почти все молодые – в районе 40 лет, во-вторых – мы, в отличие от других клиник, работаем фактически как одно отделение все вместе. Когда я только сюда пришел, такого и представить было невозможно. Чтобы ты, например, пошел с какой-то просьбой в другое отделение – это целое приключение было, а сейчас такая камерная обстановка, что ли. Мы как одна семья. Допустим, ко мне попадает человек с условным неврологическим головокружением, а потом выясняется, что у него еще и пневмония. Мы его тогда технично переводим в терапию. Или в терапии у пациента случился инсульт, они его направляют ко мне. Думаю, от такой синергии в первую очередь выигрывают наши подопечные.

***– А почему всё-таки неврология? Выбор был осознанным?***



– Да. Я когда поступал в университет, изначально хотел быть неврологом. Работая на скорой, я научился быстро находить подход к пациенту, а это очень ценное качество для невролога. Если честно, поначалу выбирал – кем быть: неврологом или психиатром? Но потом подумал, если стану психиатром, то буду заниматься только психиатрией, а если выберу профессию невролога, то смогу практиковать сразу в двух направле-

ниях. Да и с точки зрения нашего русского пациента, всё-таки не каждый решится пойти к психиатру, есть определенное клише. А невролог более привычный специалист. Поэтому от недостатка спроса у пациентов не страдаю. Очередь на два месяца вперед. При этом неврология – эта сейчас самая неизученная область. Здесь всё: и мышечный тонус, и сосуды, и работа мозга, и отдельных систем организма – нервные окончания у нас везде. Хочешь – изучай деменцию, сейчас очень распространенное явление, хочешь – занимайся психосоматическими неврозами, гипнозом или мануальной терапией. К тому же невролог может принимать клиентов практически в любом месте, без привязки к кабинету. Как-то раз купался на городском пляже, ко мне подплывает человек, говорит: Эдуард Хабибович, моя мама у вас лечилась, можно спросить совета? Я ему отвечаю – давайте сначала до берега доплывем, а там сможем пообщаться. В общем, всё очень интересно.

***– Опять же легко можно выбрать тему для диссертации.***



– С кандидатской пока решил повременить. В планах получение ученой степени, конечно, есть, но не сейчас. Пока все силы отдаю



отделению. Много занимаюсь организаторской работой. Надо коллектив собрать, ремонт сделать, настроить работу. Сделать так, чтобы отделение могло стабильно и качественно работать в мое отсутствие. Пока так не получается. Я несу рабочую нагрузку 350–360 часов в месяц, остальные пока так не смогут. Выходных нет совсем. Можно сказать, что за последний год я отдыхал один раз – когда в Донбасс ездил.

***– При такой загрузке удается как-то соблюдать татарские традиции, ходить на национальные праздники, поддерживать знание родного языка?***

– Язык я знаю хорошо. Скажу больше – это знание мне очень помогает в работе. В наше отделение недавно привезли пожилую татарку, в упадническом настроении, чуть ли не умирать собралась. Я с ней начал разговаривать на татарском. Она тут же повеселела, настрой совсем другой, можно сказать, сразу пошла на поправку. Я считаю, что с пожилыми людьми, особенно в болезненном состоянии, удобнее разговаривать на родном языке. А у нас здесь такой район, где очень много живет татар, которые периодически становятся нашими пациентами.

Если говорить о традициях и праздниках, то стараюсь соблюдать. Считаю себя мусульманином. Уже больше 10 лет держу уразу, постоянно хожу в мечеть.

***– Какие эмоции испытали, когда получали награду из рук губернатора?***

– Было волнительно. Я не первый награжденный этим знаком, но чтобы вручили его перед всеми главврачами региона – это почетно, и, конечно, гордость переполняла. Прежде губернатор приглашал ребят на торжественный ужин и там награждал, а я всё время не попадал на церемонию. Но получилось даже торжественнее.

***– Очень много из того, что Вы себе наметили в жизни, уже сбылось. Думаю, работу отделения с таким-то настроем тоже сможете наладить. Есть о чем мечтать?***

– Даже не знаю. Хочу когда-нибудь вернуться в родное село и поработать там. Ну, допустим, главврачом в местной больнице. У нас в Камышле шикарная большая ЦРБ, которую я сам своими руками строил. Когда еще в школе учился, подрабатывал там разнорабочим. Может быть, в то время у меня где-то глубоко зародилась мысль приехать сюда в новом статусе и показать, что парень из простой семьи может стать уважаемым, успешным человеком, крепким профессионалом. Возможно, это что-то из серии – закрыть гештальт? А может, от желания поднять сельскую медицину на принципиально иной, более высокий уровень? Применить всё, чему научился в Самаре, собрать хороший профессиональный коллектив, наладить качественную работу, чтобы люди могли получать квалифицированную медицинскую помощь у себя в Камышле.

***– Думаете, хватит на это сил и возможностей?***

– Поживем – увидим.


Дания Тулова

# Юмартлыгының чиге юк, риясыз күңеленә барысы да сыя...

**_Миләүшә Газимова_**

*Үзең укыган мәктәпкә*
*Ярдәм иттең иң элек.*
*Мәдрәсәгә күп булыштың,*
*Гөрләп эшләсен, диеп.*
*Күңел төпкелләрең тирән,*
*Изгелектә уйларың.*
*Тик бәхет китерсен сиңа*
*Һәр туачак таңнарың.*
*Хәер-сәдака өләшеп,*
*Киңәя торсын колачың.*
*Һәрчак чәчәккә күмелсен*
*Ярдәмчел киң кочагың.*
*Син кылган изгелекләрне*
*Бармак җитми санарга.*
*Синдәй кешеләр барында,*
*Гали үсә, яңара!*

Шушы матур шигъри юлларны Похвистнево районының Гали авылында гомер итүче Саимә апа Морзаханова үзенең авылдашы – Дания Әсхәт кызы Туловага (кыз фамилиясе – Хәсәншина) багышлап язган.

Әлеге шигырьнең һәр сүзенә мөһер сугарлык!

Чыннан да, Дания ханымның игелекле гамәлләрен дә, аның күркәм сыйфатларын да санап бетерерлек түгел.

Гали авылының һәр кешесе язмам герое турында бары тик җылы хисләр белән, рәхмәт белдереп сөйли.

Хәйриячелек инде күптән Дания Тулованың – яшәү рәвешенә, ә "мәрхәмәтлек кыл" сүзләре аның тормыш шигаренә (девиз) әйләнгән.

Гомумән, миһербанлы милләттәшебез, бихисап изге эшләр башкарып, олы хөрмәткә, мактауга, соклануга лаек булып гомер кичерә. Акча-малын, шәригать кушканча, хәерле нәрсәләргә кулланудан ләззәт алып, сөенеп, Аллаһы ризалыгы өчен башкаларга ярдәм итә ул.

Дания исеме гарәпчәдән "танылган, күренекле, данлы" дип тәрҗемә ителә. Әйе, шәфкатьлелеге, мәрхәмәтлелеге белән дан тота Дания апа. Кешегә хас булган асыл сыйфатларның берсе – юмартлык аның канына сеңгән. Димәк, ул Ал-



лаһы Тәгаләнең сөекле бәндәләре исемлегендә. “...әүвәл юмартлар Җәннәткә керсеннәр...”, – дип әйткән бит Раббыбыз.

Ә Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.: “Юмартлык – ботакларын дөньяның эченә сузган Җәннәт агачларыннан берседер.

Кем бу агач ботакларының берсенә тотынса, ул аны Җәннәткә тартыр...”, – дигән.

Әйтергә кирәк, Дания Тулова никадәр юмарт булса, шулкадәр тыйнак та. “Уң кулың биргәнне сул кулың күрмәсен” дигән гыйбарәне истә тотып яши ул. Кылган игелекләре хакында сөйләргә яратмый. Аның сокланырлык күркәм эшләре турында без башкалардан ишетеп кенә беләбез.



Газиз әнисе - Нәҗибә ханым

Менә үзе белән әңгәмә оештырырга теләгәч тә, милләттәшебез ипле генә итеп сүзне башкага борырга тырышты. Шуңа күрә мин аны яхшы белгән кешеләргә, авылдашларына мөрәҗәгать итәргә булдым. Алар да: “Әйе, Дания ханым искиткеч тыйнак ул, әмма үрнәк йөзеннән аның турында, игелекле гамәлләре хакында башкалар да белсә, яхшы булыр иде”, – диделәр.

Дания апа 1959 елда Әсхәт һәм Нәҗибә Хәсәншиннар гаиләсендә туа. Гали авылының гүзәл табигате кочагында иркәләнеп, саф чишмә суларын эчеп, затлы нәселдә төпле тәрбия алып үсә ул.

Мәктәпне тәмамлагач, кыз Куйбышев шәһәренә укырга китә, биредә заводта да эшләп ала.

Ә 1978 елда гомерлек мәхәббәтен – Рөстәм исемле җитез, уңган, булдыклы егетне очрата.

1981 елда өйләнешеп, яшьләр Түбән Варта (Нижневартовск) шәһәренә юл алалар. Анда аларның кызлары Алия туа. Биредә яшәгәндә Рөстәм эшләгән дә, укырга да өлгергән әле.

Тора-бара, 90нчы елларда, Туловлар үз бизнесларын булдыралар. Рөстәм Американың Нью-Йорк шәһәрендә дә компаниясен ача.

Эшне күбесенчә ире алып бара. Ә Дания, үзенең ныклы терәге, саклаучысы-яклаучысы булган хәләл җефетенә тулысынча ышанып, аңа һәрвакыт ярдәмгә килеп, гаилә учагының җылысын саклый, өй хуҗалыгы белән шөгыльләнә, кызлары Алияне тәрбияли.

95нче елда алар Түбән Вартадан Мәскәүгә күченәләр, ә Америкага эш буенча барып-кайтып кына йөриләр. Кызлары Алия исә Лос-Анджелес шәһәрендә яшәп укый.

Рөстәм белән Дания, миһербанлы, киң күңелле кешеләр буларак, хәләл малларыннан өлеш чыгарып, хәйрия эшләре белән шөгыльләнәләр, туганнарына да, чит-ят кешеләргә дә булышалар.

Бер-берсен яратып, хөрмәт итеп, кадерләп, бик матур тормыш алып барганда, кызганыч ки, бу гаиләнең бәхет күгән кара болыт каплый. Рөстәм авырый башлый, Лос-Анджелес шәһәрендә дә дәвалана ул.

Күңеле яхшыга өметләнсә дә, аек акыл белән тәкъдире җитүен аңлаган ир хатынын бизнес серләренә төшендереп калдырырга тырыша.

Бик иртә, дәрт-дәрманны җигеп, гөрләтеп тормыш котәр, яшьнәп яшәр чагында, 44 яшендә, якты дөньядан китеп бара Рөстәм. Аның вафатына быел 20 ел тула. 23 ел бергә яшәгән булалар Туловлар.

Нишлисең бит, язмышлардан узмыш юк шул. Дания ханым Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сынауны, Раббыбыз кушканча, сабырлык белән кабул итеп, яшәешен дәвам итә.

Татар җанлы Дания апаның күңеле милләттәшләренә, үз халкы мохитенә тартыла, һәм ул, Мәскәүдән күченеп, рухи мәркәзебез – Казанда төпләнергә була.

Иренең эшен үз кулларына алып, аны үстерү өчен зур тырышлык куя һәм бүгенге көндә уңышлы эшмәкәр хатын-кызлар исемлегенә керә Дания ханым.

Әлбәттә инде, бизнесны тәвәккәл, башлы, хезмәт сөючән, булдыклы, үҗәт кешеләр генә алып бара алалар. Әлхәмдүлилләһ, Аллаһы Тәгалә Дания апага бу сыйфатларны мул итеп биргән. Һәм милләттәшебезнең башкаларга карата кылган игелекле гамәлләре, юмарт булганы өчендер инде Раббыбыз аны Үз ярдәменнән ташламый.

Һичшиксез, кешедәге сыйфатларны, иң беренче чиратта, әтиәнисе, әби-бабалары тәрбияли. “Үскәнендә ни күрсә – очканында шул булыр”, дип юкка гына әйтмәгән бит инде татар халкы. Әйткәнемчә, Дания ханым – затлы нәсел җимеше. Аның борынгы бабалары да гыйлемле, абруйлы кешеләр булганнар. Әти-әнисен дә төпле, ярдәмчел, тырыш кешеләр буларак тасвирлыйлар.

Әсхәт белән Нәҗибә Хәсәншиннардан йорт аша гына яшәгән **Саимә Морзаханова** алар турында түбәндәгеләрне сөйләде:

“Әсхәт абый да, Нәҗибә апа да балачактан нужа күреп үскәннәр.

Әсхәт абый биш яшеннән апасы Сәгыйдә белән ятим калган. 1933 ел – иң авыр, ачлык-ялангачлык чоры. Көн күрүе кыен булган. Әсхәт беренче сыйныфны да тәмамлый алмаган, чөнки аның моңа мөмкинлеге булмаган. Ашамлык, кием,

ягулык юк. Ятимлекнең ачысын үзе генә белгәндер инде. Ә кырыс сугыш хәлне тагын да авырайткан.

Әсхәт абый бик чибәр кеше, аның күзләре дә көлеп тора иде. Әти-әнисез үскәнгә, күңеле тулып ташыгандыр инде, ул моңланып җырларга ярата иде.

Нәҗибә апа Яңа Мансур авылында туып-үскән. Җиде сыйныфны тәмамлагач, вербовка буенча Куйбышев шәһәренә эшкә тегү һөнәрханәбез дә тирә-якта дан тотты. Нәҗибә апа башкалар белән бергә тырышып эшләде: кашыклар да ясады, җәймәләр дә текте, ә җәен кырларда бил бөкте. Намуслы хезмәте өчен ул бик күп мактаунамәләргә, бүләкләргә лаек булды. Ә инде Әсхәт абыйның медальләре санап бетергесез!

Әсхәт әфәнде 1992 елда вафат булды. Хәләл җефете белән алар 36 ел бергә гомер иткәннәр.



Дания ханым (уңда) һәм аның сеңелесе Нажия

киткән ул. Сугыш вакытында траншеялар казу кебек авыр эшләрне башкарган. Ә туган авылына әйләнеп кайткач, почтага урнашкан. Кырларда печән дә чапкан, колхозда да көч түккән.

Өйләнешкәч, Әсхәт һәм Нәҗибә Хәсәншиннар Сәгыйдә апалары белән 12 ел бергә яшәгәннәр. Аннан соң, үзләренә йорт сатып алып, башка чыкканнар. Аралары ерак булмаганга, гел күрешеп, аралашып торганнар.

Яшь гаиләдә аллы-артлы балалар туган: Дания, Минәхсән, Нажия, Рәфкать.

Әсхәт абый гомере буе фермада терлекчелектә эшләгән. Ә Нәҗибә апа колхоз кырларында чөгендер үстергән.

Авылыбыз колхозы районда алдынгылар сафында булды. Бездә җитештерелгән агач кашыклар Германиягә кадәр җибәрелә иде,

Раббыбызга шөкер, бүгенге көндә 90 яшьлек Нәҗибә ханым, гыйбадәтләрен үтәп, бәхетле картлыгы өчен Аллаһыга шөкерана кылып, тәүфыйклы балалары, оныклары булуына сөенеп яши.

Дания сеңелесе Нажияне дә, Минәхсән, Рәфкать энеләрен дә, иренең туганнарын да үзе янына, Казанга урнаштырды. Туганлык җепләре нык, бергәләшеп, ярдәмләшеп гомер итәләр алар".

Гали авылының ветеран укытучысы **Суфия апа Сәлимова** язмам герое турында:

*"Ул безнеке, безнең кеше!*
*Гамәлләренә таң калам,*
*Юмартлыгының чиге юк,*
*Күңел киңлегенә сокланам!"* – дигән шигъри юллар язган. Аңардан да мин авылдашы турында сораштырдым.

"Дания миннән бер яшькә генә кече, бергә үстек, бергә кич чыгып йөрдек. Энем Хәйдәр белән бер сыйныфта укыдылар алар. Кара бөдрә чәчле, чибәр, нәфис кыз үзенә җәлеп итеп тора иде.

Тугызынчы класста укыганда Хәйдәр, аягын сындырып, озак вакыт мәктәпкә йөри алмады. Шул вакытта Дания аның янына һәр көнне килеп йөрде, өй эшләрен әзерләргә булышып, уку елын тәмамларга ярдәм итте. Аның матурлыгына гына түгел, тыйнаклыгына да сокланып кала идек.

Мәктәпне бетергәч, төрлебез төрле якка таралышып яши башладык. Берникадәр вакыт Дания турында: "Отрадный егете Рөстәмгә кияүгә чыккан", "Мәскәүдә яши, туганнарына булыша", "Бик бәхетле, хәлле һәм ярдәмчел икән" дигән хәбәрләр ишетелеп торды.

Шул заманда ук, авылыбызның Түбән оч мәчете төзелгән вакытта, мәхәлләнең акчасы бетеп, эшләр туктала гына, дигәндә, алар ире Рөстәм белән зур акчалар бирделәр. Мәхәллә картлары, бик шатланып, төзү эшләрен дәвам иттеләр. Ә мәчет ачу тантанасында бу мәрхәмәтле затларга догалар кылып, үзләренә Коръән бүләк иткәннәр иде. Рөстәм аны бик сөенеп кабул иткән, изге Китапны кадерләп саклап тоткан икән. Әле аннары, инде ире үлгәч, Дания Түбән оч мәчетен тулысынча төзекләндерүгә матди ярдәм күрсәтте. Гыйбадәтханәбез сокланып туймаслык булып, Казанның затлы мәчетләренә охшап калды.

Инде шул вакытлардан алып, бүгенге көнгә кадәр Дания ханым, авылыбызның, гомумән, татар халкының җәмәгать тормышына башы белән чумып, мәчетләр, мәдрәсәләр, мәктәпләргә булыша, чишмәләр торгызуга күп көч куя.

Шуны әйтәсем килә, юмартлык сыйфаты Даниягә һавадан төшмәгән, ул якташыбызның нәселеннән килә. Мин, авылдашым үтенече буенча, аларның нәсел-ыру шәҗәрәсен төзедем. Аның ата-бабалары дини, гыйлемле, ихтирамлы кешеләр булганнар.

Әйтик, Әсхәт абыйның ата-



Әнисе һәм туганнары белән

тыйнак, ярдәмчел, кешелекле булды ул. Беркем белән дә талашмас, каршы сүз әйтмәс иде.

Дания ханым хәләл малыннан татар җәмәгать эшләренә дә, мәчет-мәдрәсәләргә дә, мәктәпләргә дә, картлар йортларына да, мохтаҗларга, ятимнәргә дә, үзенең гаиләсе, туганнарына да мул итеп өлеш чыгара. Юмартлыгының чиге юк, риясыз күңеленә барысы да сыя. Әмма игелекле эшләрен күрсәтеп, алар турында сөйләп йөрергә яратмый ул. Әле күбесен без, авылдашлары, белеп тә бетермибез.

Әйе, Дания кебек шәхесләр турында туктамыйча сөйләргә була. Авылыбызны нык күтәрде ул. Аның күңел киңлегенә сокланам мин", – дип сөйләде Суфия апа.

Гали авылының "Ак калфак" татар хатын-кызлары оешмасы җитәкчесе, ветеран мөгаллимә **Кәүсәрия Шәйхетдинова:**

"Дания – йомшак күңелле, бик тә ярдәмчел кеше, ә инде тыйнаклыгына исләрең китәр!

Аның әти-әнисе дә шундыйлар.

сы – Гайҗан бабай гарәп графикасын, фарсы телләрен белгән. Ә аның хатыны Зәрига күренекле муллалар тәрбияләгән затлы нәселдән булган. Алар матур гаилә корганнар, күршеләренә, туганнарына карата бик ярдәмчел, намуслы, гади, эшчән, пөхтә кешеләр булып авылдашлары хәтерендә калганнар.

Әсхәт абый белән Нәҗибә апа турында да җылы сүзләр генә ишетергә туры килә.

Аларның күршесе, мәрхүм Әминә апа Гыйсмәтуллина: "Әсхәт сабыр, ярдәмчел, эчкерчез кеше иде. Бик матур яшәделәр алар. Хатынын шулхәтле яратты, хөрмәт итте, сокланмыйча мөмкин түгел инде!

Нәҗибә дә – бик уңган, чистапөхтә һәм гадел хатын. Улларыкызларына лаеклы тәрбия бирделәр алар. Бөтен балалары да эшчән, булышучан, тәртипле булып үстеләр.

Без күршеләрем белән бер гаиләдәй яшәдек. Сыенып та, ышанып та, таянып та була иде үзләренә. Өйдә тавыш-фәлән чыкса, әнием белән Әсхәтләрдә куна идек. Бер сәкегә дүрт балалары да, әнием дә, мин дә сыйдык. Мунчага да аларга йөрдек.

Бездә сыер юк иде. Сөт кирәксә, һаман да шул ук күршеләремә чабып керәм. Беркайчан да кире борып җибәрмәделәр, беркайчан да юк, дип әйтмәделәр.

Инде хәзер балалары мине зурлый. Гаетләрдә барысы да киләләр, хәер-садакаларын җибәреп торалар. Аллаһының рәхмәтләре яусын үзләренә" – дип, догалар кылып утыра иде.



Минтимер Шәймиев Дания Тулованы бүләкли

Даниянең үзенә килгәндә исә, чын шәхесләргә генә хас булган сыйфатлар чагыла аңарда: акыллы, нык холыклы, һәрвакыт ачык йөзле, үзен гади тота, беркайчан буш сүз сөйләми, кешеләрне тыңлый-ишетә белә, күңел күзе белән күрә ала. Тыныч, ипле, төпле. Бәләкәйдән үк

Берәрсенә булышырга кирәксә, Әсхәт абый, бөтен эшен ташлап, ярдәмгә чаба торган булган. Әйе, үзләрендәге күркәм сыйфатларны дүрт балаларында да тәрбияли алганнар алар.

Татар җанлы Дания ханым ана телебезгә, гореф-гадәтләребезгә, мәдәниятебезгә мөкиббән, халкы белән горурлана. Кызында да шун-

дый ук хисләр тәрбияләгән, хәзер ике оныгының күңеленә дә милли мирасыбызга мәхәббәт сеңдерә.

Даниянең күркәм холкын башкаларга үрнәккә куярлык. Оялчан, кешелекле, миһербанлы, беркайчан да беркемне тәнкыйтьләмәс, һәрвакыт түземлек күрсәтер. Аның белән аралашуы бик рәхәт, үзеннән илһам, көч, куәт аласың.

Тыйнак кына яши, киенүе дә шундый, үзен күрсәтеп йөрергә яратмый.

Җирдә мәш килә инде ул. Бакчасында ниләр генә үстерми, агачларның да нинди генә төре юк анда! Яшелчәләр, җиләк-җимешләрдән кышкыга төрле кайнатмалар, салатлар әзерләп куя. Уңган кеше һәрьяклап булдыра инде ул, дип әйтәсем килә.

Дания туып-үскән авылы өчен җан атып яши, аны бик ярата, якын күрә, язмышы, киләчәге өчен ихластан борчыла. Балалар күп булсын, авыл яшәсен иде, дип тели ул. Шалтыраткач, һәрвакыт Галидәге хәлләр, мәктәп тормышы, кешеләр турында җентекләп сораштыра.

Ә инде аның авылыбыз үсешенә керткән өлеше бәяләп бетермәслек! 2010 елда беренче Бөтенроссия авыл Сабан туе бездә уздырылды бит. Аңа ничек итеп әзерләнгәнебезне күз алдына китереп буладыр. Елга буйларын чистартырга, агачлар утыртырга, мәртәбәле кунаклар өчен мул табыннар корырга, гомумән, санап бетермәслек зурзур эшләр башкарырга туры килде. Дания ханым Тулова да, әлбәттә, бу хезмәттән читтә калмады, матди яктан зур булышлык күрсәтте. Моның өчен өлкәбез губернаторы Владимир Артяков тарафыннан Мактаунамә белән дә бүләкләнде ул.

Үз акчасына өч катлы мәктәбебезгә капиталь ремонт ясатты. Диварлардагы штукатурканы кирпечкә кадәр куптарганнар иде бит, галәмәт булды ул ремонт! Идәннәрне, түшәмнәрне яңадан ясадылар. Бинаның тышкы ягы да яңартылды, җылытылды. Утүткәргечләрне, сигнализация системасын алмаштырдылар һәм башкалар, һәм башкалар.

Моңардан тыш, уку йортына бик күп җиһазлар да алып бирде бит әле Дания.

Мәктәп йортын тимер койма белән тотып, балалар мәйданчыгы ясатты, агачлар кайтартып, җимеш



Рөстәм Миңнеханов Дания ханымга җылы сүзләрен җиткерә

бакчасы булдырды, ашханәсен төзекләндереп кенә калмыйча, тулысынча яңа кирәк-яраклар белән тәэмин итте. Бу эшләрдә аның энесе, төзелеш буенча бик яхшы белгеч Минәхсән иң беренче киңәшчесе дә, ярдәмчесе дә булды.

Мәдәният йортын, балалар бакчасын, музеебызны яхшыртырга булышты. Мәдрәсә-мәчетләргә дә аның ярдәме гел тиеп тора, төрле чаралар оештырганда катнашмыйча калмый ул. Сәхнәләрдә чыгыш ясаучы балаларыбызга, авылыбызның "Мирас" фольклор төркеме артистларына милли киемнәр тектерер өчен тукымалар, читек-туфлиләр сатып алды. Оста куллы авылдашыбыз Флюра апа Низамова үзешчәннәребезгә күз явын алырлык костюмнар тегеп бирде.

Дания ханым үз авылын гына түгел, каената-каенанасының туган авыллары Мунчәлине дә онытмый, гомумән, Татарстанда да хәйриячелек белән шөгыльләнә. Аның ярдәмендә республиканың Югары Ослан районында урнашкан картлар йорты төзекләндерелгән, заманча җиһазландырылган.

Дания Тулова төрле елларда "Ел иганәчесе" исеменә лаек булып, аңа Татарстан Җөмһүриятенең беренче Президенты Минтимер Шәймиев та, бүгенге Рәисе Рөстәм Миңнеханов та үз куллары белән күкрәк билгесе белән диплом тапшырганнар.

Хәер, якташыбыз кылган игелекле эшләрнең барысын да санап бетерерлек түгел. Раббыбыз үзенә әҗер-савапларын бирсен, изге ниятләрен тормышка ашырырга насыйп итсен иде. Без барыбыз да аңа бик рәхмәтлебез".

Дания апаның классташы, якын иптәше **Әлфия Зарипова** түбәндәгеләрне сөйләп үтте:

"Дания белән без бер сыйныфта укыдык, бик тату идек, һәм шушы дуслыгыбыз бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Ул тыңлаучан бала булып үсте. Сер тотучан, вәгъдәсен үти торган кеше, бөтен нәрсәне төптән уйлап эшли, бик шәфкатьле.

Балачактан ук бер-беребезгә ярдәм итешә идек – дәресләр әзерләгәндә дә, имтиханнар биргәндә дә, өй, йорттагы эшләрне башкарганда да.

Без дүрт иптәш, ике кызыбыз – Самарда, Дания – Казанда, мин Гали авылында яшибез. Өчәү җыенып, Даниягә кунакка китәбез. Ул безгә шәһәрне күрсәтә, яхшылап кунак итеп җибәрә. Менә, Аллаһы теләсә, җәен тагын барырга дип ниятләнеп торабыз әле.

Мин сыйныфташларымның эти-әниләре белән элемтәдә торам, күрешергә, хәлләрен белергә баргалыйм. Даниянең әнисе – Нәҗибә апа белән дә, чәйләр эчеп, рәхәтләнеп сөйләшеп утырабыз без.

Дания үзе дә искиткеч әйбәт холыклы, кызы Алия дә тәүфыйклы, тәрбияле, тырыш. Ике югары белем алган ул. Йосыф исемле акыллы егеткә кияүгә чыгып, ике малай тапты. Әниләренең күңелен күреп, хөрмәт күрсәтеп яшиләр.

Дания авылга кайткан көн минем өчен зур бәйрәм инде. Сөйләшеп, сүзләр бетмәде, серләшеп, серләр кимемәде, дигәндәй, озаклап аралашып утырсак та, һаман да безгә вакыт җитми. Яшь чаклардагы кызыклы хәлләрне барлап, көлешеп тә куябыз, тормыштагы авыр вакыйгаларны искә төшереп, елашып та алабыз.

Аллаһыга шөкер, еллар узган саен дуслыгыбыз ныгый бара, аңлашып, бер-беребезнең кадерен белеп, ярдәмләшеп яшибез.

Минем ирем юк. Балаларымның туйларын уздырганда да Дания миңа бик булышты. Туганнарына да искиткеч мөнәсәбәт күрсәтә, үзләрен кадерле, матди яктан да, рухи яктан да хуплап, ярдәм итеп тора.

Сыйныфташым турында сөйләгәндә хәтта тәннәрем чемердәп китә – шулкадәр әйбәт кеше, шулкадәр тугры, ышанычлы иптәш ул. Аның кебекләр тормышта сирәк очрый.

Дустыма барысы өчен дә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын, үзенә бәхетле гомерләр насыйп булсын".

Гали авылы башлыгының урынбасары **Зәйтүнә Газизуллина:**

"Без Дания белән күршеләр. Мин аңардан өч яшькә олырак. Бергә уйнап үстек, кызлар булып җитешкәч, клубка бергә йөрдек.

Кечкенәдән җаваплы, тырыш, һәр эшне җиренә җиткереп башкара иде Дания. Гаиләдә иң олы бала буларак, өй-йорт эшләренең күбесе аның өстендә булды, сеңелләрен дә карады.

Без кырда чөгендер утаган инәкәйләребезгә ярдәм итәргә бара идек. Шунда Дания минем белән ярыша-ярыша эшли һәм уздырып та китә иде әле. Хезмәт белән чыныгып үсте ул.

Аның белән хәзер дә аралашып яшибез, шалтыратышабыз. Без берничә тапкыр Казанга кунакка да бардык. Үзе авылга кайткан саен күчтәнәчләрен китермичә калмас.

Дания бик әйбәт, ипле, гадел. Сабыр кеше, безне дә түземле булырга өйрәтә.

Кызганыч, ире генә яшьли китеп барды, бик яхшы торалар иде.

Әниләре Нәҗибә апаны кадер-хөрмәттә яшәтәләр алар. Әле Дания, әле сеңел-энеләре кайтып, барысын да эшләп китәләр. Йорты шау чәчкәдә утыра. Газиз инәкәйләрен яхшылап тәрбиялиләр. Нәҗибә апаны авылдашлары да ихтирам итә. Шундый тәүфыйклы балалар үстергән, зур хәрефтән язарлык, сокланырлык Ана ул.

Дания туган җире Галинең үсешенә, халыкның тормыш-көнкүрешен яхшыртуга олуг өлеш кертә. Фельдшер-акушерлык пунктына ремонт ясатты, авылда юл салуда да булышты. Өйләре янган, авыр тормышлы кешеләргә, авыруларга да аның зур ярдәме тия. Вакытын да, малын да кызганмый.

Даниядәй якты күңелле, олы йөрәкле шәхесләр булганда дөнья ямьләнеп китә. Үзенә дә, якыннарына да рәхәт, матур тормышларда яшәргә насыйп булсын".

Менә шундый гаҗәеп шәхес буларак тасвирладылар миңа Дания апа Тулованы. Аның кебек кешеләргә карата ихтирам, соклану, рәхмәт хисләре уяна. Аллаһы Тәгалә җир йөзенә шундый бәндәләрне башкаларга үрнәк булыр өчен дә яралта торгандыр.

Дания ханым Тулова турында аның авылдашлары сөйләгән сүзләрне ишеткәч, әйтерсең лә туган ягыңны тагын да ныграк ярата башлыйсың, башкаларга тагын да ныграк ярдәм итәргә, үзеңдә мөмкин кадәр күбрәк күркәм сыйфатлар тәрбияләргә телисең.

"Туып-үскән җирем миңа шулкадәр якын, Галине бик сагынам, аннан көч алып китәм. Әнием исән вакытта, туган йортта ямь барында рәхәтләнеп кайтам әле", – ди Дания апа үзе газиз авылы турында.

Тормышыннан да канәгать булып яши ул.

"Аллаһыга мең шөкер, эшем уңышлы, әнием исән-сау, кызым белән бер дулкында, туганнарым, дусларым белән аралашып, ярдәмләшеп яшибез. Үземне бәхетле, дип саныйм.

Хыялланып яшим. Хыялсыз кеше – канатсыз кош. Хыялларым күп минем. Мәсәлән, авылдашларым бер-берсен аңларга тырышып, бердәм булып, бер-берсенә булышып, хөрмәт итеп гомер







итсеннәр, һәркем булдыра алганча авылыбызны күтәрергә тырышсын иде. Менә шунда эшләребез җиңел барыр, үзебез көчле булыр идек, сүзебез дә үтәр иде", - ди Дания ханым.

## Юрист Дилфүзә Әсәнова:

# “Никах килешүе гаиләгә иминлеген сакларга ярдәм итәчәк”

***Тышкы кыяфәте генә түгел, эчке дөньясы да матур булган татар хатын-кызлары бигрәк сокландыра да инде! Рөстәм кызы Дилфүзә Әсәнова нәкъ шундый ханымнар исемлегенә керә. Нәзакәтле, ягымлы, мөлаем, елмаючан, йомшак кына сөйләшүче асыл татар хатын-кызы ул. Ә эчке дөньясының байлылыгына исләрең китәр! Үзе гыйлемле, зыялы, милли җанлы, диндәшләре, милләттәшләре, ана телебез, динебез өчен янып-көеп яшәүче шәхес. Һәрнәрсәгә үз карашы бар.***

***Миләүшә Газимова.***



Милләттәшебезнең төрле темаларга кагылышлы төпле, акыллы фикерләрен укучыларыбызга да тәкъдим итәбез.

***– Дилфүзә, ни өчен юрист һөнәрен үзләштерергә булдыгыз?***

– Мин кечкенәдән дөреслекне яраттым. Юкка рәнҗетелгәннәрне гел яклый идем. Гаделлек эзләү, гаделлек өчен көрәшү – миңа балачактан хас булган сыйфатлар. Шуңа күрә, һөнәр сайлау вакыты килеп җиткәч, хокук белгече булырга карар кылдым да инде.

***– Шәһәребездә гаиләләргә ярдәм итә торган “Берләшү” үзәген булдырып, аны җитәкләп киләсез. Оешмагызның максатлары һәм эшчәнлеге турында сөйләп үтсәгез иде.***

– Мин гаилә, аналык, аталык һәм балачакны саклау өлкәсендә юридик хезмәт күрсәтеп киләм. Эш барышында шуны аңладым ки, гаиләдә барлыкка килгән проблемаларны хәл итәр өчен юристка үз хезмәтенә төрле белгечләрне – психолог яисә психиатр, педагог, хәтта дин әһелләрен дә җәлеп итәргә кирәк. “Берләшү” үзәге нәкъ шушы максаттан чыгып булдырылды да инде.

Оешмабызда югары профессиональ юрист, психолог, педагоглар халыкка тиешле ярдәм күрсәтәләр. Шулай ук бездә гаилә клубы эшләп килә. Биредә төрле яшьтәге, төрле караштагы кешеләр, гомуми традицион рухи-әхлакый кыйммәтләр нигезендә берләшеп, гаилә хәлләренә, буыннар бәйләнешен ныгытуга кагылышлы мәсьәләләрне, проблемаларны чишү җаен эзлиләр, фикерләре, тәҗрибәләре белән уртаклашалар, киңәшәләр.

Гомумән, без эшне судка кадәр җиткермәскә тырышабыз. Гаиләдә туган низагларны тыныч юл белән хәл итү – минем принципиаль позициям. Ә конфликтлар төрле була: аерылышу һәм бу очракта баланың әтисеме яисә әнисеме янында калуы турында бәхәсләшү, милек, мирас бүлешү һәм башкалар. Алимент түләү дә үткен мәсьәлә булып тора.

Кайчак безгә ярдәм сорап килгән мөселманнар өчен дин әһелләренең фикере мөһим булып тора. Бу очракта Самар өлкәсе мөселманнарының Региональ диния нә-

зарәтенә, имамнарга мөрәҗәгать итәбез.

Дөресен генә әйткәндә, аерылырга теләүче парлар өчен, иң беренче чиратта, юрист та түгел, ә психолог ярдәме кирәк. Кайберәүләр чынлап аерылышырга да теләмиләр, кызган чакларында хәләл җефетенә үч итеп яисә аны куркытырга теләп кенә шундый карарга киләләр. Шуңа күрә без башта үзләре белән сөйләшү алып барабыз, гаиләне саклап калырга, бер-берсен гафу итәргә үгетлибез.



Әгәр дә инде эш судка кадәр барып җитте икән, бу әле проблема тулысынча хәл ителде, дигән сүз түгел. Суд карарын кулга алгач та, күп мәсьәләләрнең очына чыгарга туры килә. Мәсәлән, приставлар белән эш итү, суд карарларының үтәлүен күзәтүдә тоту һәм башкалар.

Шуны ассызыклап үтәсем килә – аерылышканда ике як өчен дә иң хәерлесе – ул үзара аңлашу килешүе (мировое соглашение) төзү. Шуңа күрә без кешеләрне шушы карарга килергә өндибез. Чөнки гаиләдә низаг чыкты икән, бу бәхәстә җиңүчеләр дә, җиңелүчеләр дә юк, барысы да зыян күрә.

***– Сез кешеләргә шулай ук бушлай юридик ярдәм дә күрсәтәсез икән?***

– Әйе, әйтик, мин менә инде өч ел гаиләдәге җәбер-золымнан җәфа чиккәннәргә булышам. Алар арасында хатын-кызлар, ир-атлар да, картлар, балалар да бар.

Шулай ук өлкән яшьтәге ялгыз кешеләргә төрле мәсьәләләр буенча бушлай консультацияләр бирәм.

***– Самар өлкәсе мөселманнарының Региональ диния нәзарәте һәм шәһәребезнең “Болгар мирасы” тарихи-мәдәни фонды белән берлектә гамәлгә ашырылган проектларыгыз да бар бит?***

– Әйе, без бергәләп “Бердәм эш”, “Буыннар бәйләнеше” проектларын булдырдык.

Мәсәлән, Өлкәннәр көнендә “Ак розалар” исемле акция үткәрелде. Идел яры буенда олы яшьтәге кешеләргә чәчәкләр өләшеп йөрдек. Үзләреннән күпме изге теләкләр, рәхмәт сүзләре ишеттек! Әлеге чара төбәгебездә күркәм гадәткә әйләнеп китәр, дип ышанам.

“Буыннар бәйләнеше” проекты кысаларында исә өлкәннәр белән очрашулар үткәреп, аларның истәлекләрен, акыллы фикерләрен, теләкләрен, тормыш һәм рухи ихтыяҗларын язып алабыз, ягъни яшьләр олыларны яхшырак аңласыннар өчен үзенә күрә бер яңа тарих туплыйбыз.

Россиядә гомер итүче халыкларның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен өйрәнү йөзеннән “Төрле булырга хокуклы” исемле проект өстендә дә эшлибез.

Безнең “Берләшү” үзәге былтыр шәһәребездә узган мөселман форумында катнашты. Бу да – өлкә диния нәзарәте һәм “Болгар мирасы” фонды белән бергә оештырылган чара. Анда традицион гаилә кыйммәтләрен саклауга һәм хокукый нигезләргә кагылышлы мөһим мәсьәләләр каралды.

Форсаттан файдаланып, башлангычларымны, идеяләремне хуплаучы, җәмәгать эшләрендә, социаль проектларны гамәлгә кертүдә миңа зур ярдәм күрсәтүче мөфтиебез Талип хәзрәт Яруллинга, “Болгар мирасы” тарихи-мәдәни фондының Попечительләр шурасы рәисе Гомәр Батршинга, Тарихи мәчет Советы рәисе Усман Илингинга олуг рәхмәтләремне белдерәсем килә.

***– Ә сез форумда нинди темага чыгыш ясадыгыз?***

– Мин күбесенчә хокукый нигезләргә тукталдым. Никах килешүе (сүз мулла укыган никах турында бара – автор искәрмәсе) темасына аеруча басым ясадым. Чөнки, эш тәҗрибәмнән чыгып, мөселманнар арасында ир һәм хатын хокукларына, вазифаларына кагылышлы никах килешүе төзүне актуальләштерергә кирәк, дигән фикергә килдем. Ник дисәгез, бу гаилә иминлеген сакларга ярдәм итәчәк.

Форумда шундый килешү проектын булдыру турында сүз алып барылды. Әлбәттә, ул юридик көчкә ия булмаячак, чөнки закон буенча төзелгән никах килешүе бары тик милек мөнәсәбәтләрен (имущественные отношения) генә үз эченә ала. Әмма һәрхәлдә ир белән хатын вазифаларына һәм хокукларына кагылган никах килешүендәге сорауларга бирелгән җаваплар кияү белән кәләшкә бер-берсенең





холкын тагын да яхшырак аңларга, карашларын, ихтыяҗларын, теләкләрен белергә булышачак. Ягъни киләчәктә гаиләне бәхетсезлектән саклап калу өчен үзенә бер профилактика чарасы булачак. Әлбәттә инде, теләгән кешеләр, никах килешүеннән тыш, юристка мөрәҗәгать итеп, милек мөнәсәбәтләренә кагылышлы килешү дә төзи алачаклар.

***– Дилфүзә, сез бит әле волонтерлык белән дә шөгыльләнәсез? Былтыр әлеге җәмәгать эшегез өчен "Благородство" дип аталган өлкә акциясе лауреаты исеменә дә лаек булгансыз икән.***

– Бу эшчәнлегем шулай ук юридик хезмәтем белән бәйле. Гаиләдәге җәбер-золымнан җәфа чиккән, авыр тормыш хәлендә калган, ата-ана вазифаларын тиешлечә үтәмиләр, дип, нигезсез гаепләнгән кешеләргә булышам.

Быел менә гаиләдә җәбер күргән хатын-кызларга ярдәм күрсәтү юнәлешен көчәйтергә телибез.

***– Сезнеңчә, имин гаилә нинди булырга тиеш?***

– Башта шуны ассызыклап әйтәсем килә – тормышта идеаль кешеләр булмый! Һәркемнең үз кимчелекләре бар. Иң беренче чиратта, гаиләдә үзара ихтирам хөкем сөрергә тиеш. Хөрмәт юк икән, тынычлык та булмаячак. Бер-береңә карата кайгыртучан, кызганучан, сабыр булырга, гафу итә, юл бирә белергә кирәк.

***– Ә үзегез бәхетле гаиләдә үстегезме?***

– Аллаһыга шөкер, татар авылында, зур һәм бик тату гаиләдә тәрбияләндем мин. Әтиәнием, әби-бабам, апам һәм сеңелем арасында көчле мәхәббәт, наз, чиксез бәхет тоеп үстем.

Гаиләбездә буыннар бәйләнеше нык булды. Уртак эш аша әти-әниебез, әби-бабабыз безгә үз осталыкларын, белемнәрен, тәҗрибәләрен тапшырдылар.

Безнең үз гореф-гадәтләребез дә бар иде. Әйтик, әнием белән берәр эш эшләгәндә татар җырларын җырлый идек. Әнкәем безгә башкарган бишек җырларын хәзер мин үз балаларыма җырлыйм.

Ә инде барыбыз бергә кечкенә ашка җыелып, сөйләшеп, серләшеп утыруы нинди күңелле иде! Җанга рәхәтлек, тынычлык иңә, якыннарыңның җылы сүзләреннән бөтен борчуларың юкка чыга...

Әйе, бик бәхетле гаиләдә үстем мин, балачагым ямьле үтте, әлхәмдүлилләһ.

***– Шәхес буларак тәрбияләнүдә әти-әниегезнең йогынтысы нинди булды?***

– Һәр кеше өчен гаилә – тормыш нигезе. Киләчәккә нигез нәкъ гаиләдә салына.

Шәхес буларак формалашуыма әтием белән әнием дә, әби-бабам да бәһасез өлеш керттеләр. Аларның бар максаты барыбызга да лаеклы тәрбия, югары белем бирү, безне кеше итү иде.

Олы апам табиб һөнәрен үзләштерде, мин юристлыкка укыдым, сеңелем фармацевт белгечлеген алды. Һәм бу әти-әниебезнең тырышлыгы аркасында. Алар безнең, гыйлем алып, кешеләргә ярдәм итүебезне теләделәр, үз тамырларыбызны, гореф-гадәтләребезне онытмаска өйрәттеләр.

Бабам мине гарәп алфавиты белән таныштырды. Атларга мәхәббәтем дә нәкъ аңардан күчте. Ул мине атта йөрергә өйрәтте. Әтием сәясәт, тарих турында күп сөйли иде. Әниебез белән әбиебез, әлбәттә инде, безне хатын-кыз булу серләренә төшендерделәр.

Шунысы да мөһим, алар без-

гә ныклы ышаныч белдерәләр, ә без шушы ышанычны тулысынча акларга тырыша идек.

Әти-әниебез, әби-бабабыз бездә үзләрендә булган барлык күркәм сыйфатларны тәрбияләргә тырыштылар. Һәм без аларга гомеребез буе рәхмәтле булачакбыз.

***– Хәләл җефетегез сезгә нинди мөнәсәбәт күрсәтеп яши, ул сезнең башлангычларыгызны хуплыймы, җәмәгать эшләрендә ярдәм итәме?***

– Ирем Илгизәр белән ун ел бергә гомер итәбез һәм, Аллаһыга мең шөкер, бәхет-сәгадәттә яшибез. Ул миңа һәрьяклап булыша. Каенатам белән каенанам да – минем өчен бик якын кешеләр, беркайчан да ярдәмнәреннән ташламыйлар. Алардан һәм хәләл җефетемнән башка тормышта уңышларга ирешә алмас идем. Үзләренә рәхмәтем чиксез.

***– Сез – өч бала анасы. Аларга нинди сыйфатлар сеңдерергә тырышасыз?***

– Әти-әнием мине ничек тәрбияләде, балаларыма шундый тәрбия бирәм. Эш сөючән, гыйлемгә омтылучан булырга, үз хаталарын төзәтә белергә өйрәтәм. Намуслылык, гаделлек, кешелеклелек, миһербанлылык сыйфатларын сеңдерергә тырышам.

***– Гаиләгездә үз гореф-гадәтләрегез бармы?***

– Минем балачактагы гадәт безнең гаиләдә дә дәвам итә – берәр эш эшләгәндә татар җырларын җырлыйбыз.

Шулай ук мин киләчәккә хатлар язып, аларны тартмачыкта саклап тотам. Бу болай башланды – балаларым кечкенә булганда беренче тешләре кайчан чыкканын, беренче адымнарын кайчан ясаганнарын, беренче сүзләре нинди булганын язып бара идем. Аннары киләчәктә, инде алар үсеп җиткәч, үзләренә әйтергә теләгән сүзләремне яза башладым. Ә бервакыт балалар, тартмачыкны табып алып, бу турыда белгәч, үзләре дә киләчәккә хатлар яза башладылар.

***– Белгәнемчә, сез дә, ирегез дә шәригать кануннарын үтәп яшисез. Дингә ничек килдегез?***

– Мин кечкенәдән дини мохиттә үстем. Бабам әйткән азан моңнары әле дә колагымда яңгырый. Иртән торып, аның намаз укыганын күзәтеп тора идем. Инде әйткәнемчә, бабай миңа гарәп алфавитын өйрәтте, дин турында күп сөйли иде.

Гаиләбездә мәҗлесләр гел үткәрелеп торды, ураза тоттылар, корбан чалдылар. Бәләкәй чагыбызда мәчеткә тәравих намазларына да бара идек.



Әнием Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт тәрбияләде. Аның кулында гел тәсбих булды, һәрвакыт догаларын укып торды. Нәкъ әнием миңа доганың көчен аңлау мөмкинлеген бирде. Нәкъ аның изге догалары безгә тормышта ярдәм итте, дип саныйм. “Кайда гына булсагыз да, нәрсә генә эшләсәгез дә, Раббыбыз барысын да күреп тора. Авыр вакытларда Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итегез, шатлыклы чакларыгызда Аңа рәхмәтләр әйтеп торыгыз”, – дия иде ул.

Кызганыч ки, әнием биш ел элек вафат булды. Мин аның: “Үз өммәтеңә файдалы бул”, – дигән васыятен үтәп яшәргә тырышам.

Институтта беренче курста укыганда, шулай кирәклеген үзем аңлап, яулык бәйләдем, озын итәк кидем. Шуннан бирле, әлхәмдүлилләһ, йөрәгемдәге иманымны саклап яшим, намазларымны калдырмаска тырышам.

Балаларыбызга да дин нигезләрен өйрәтәбез. Әмма аларны мәҗбүриләргә ярамый. Иң хәерлесе – үз тормышың, кылган гамәлләрең белән үрнәк булырга кирәк.

***– Кешеләрдә нинди сыйфатларга өстенлек бирәсез?***

– Эчкерсез, туры сүзле, намуслы, рухи яктан көчле, мәрхәмәтле шәхесләрне яратам. Үземнән дә шуны ук таләп итәм.

***– Үзегезгә карата гадел тәнкыйтьләү сүзләрен ничек кабул итәсез?***

– Гадел, файда китерә торган тәнкыйтьләү сүзләре тормышыңа, хезмәтеңә уңай үзгәрешләр кертергә булыша, дип саныйм.

***– Дилфүзә, сезнеңчә, заманча татар хатын-кызы нинди булырга тиеш?***

– Белемле, даими рәвештә гыйлем өстәп торырга, үсештә булырга кирәк, чөнки хатын-кыз – балалар тәрбияләүче.

Рухи яктан көчле булырга тиеш, чөнки ул – ире өчен ышанычлы тыл.

Хатын-кызга иманлы, гел догада булуы мөһим, дип саныйм. Нәкъ күңелдәге иман кешенең рухи сәламәтлеген саклый. Ә ананың баласына кылган догасы кабул була, диелә динебездә.

***– Хатын-кызның бәхете нидә? Сез бәхетлеме?***

– Хатын-кызның бәхете – гаиләдә. Мин бәхетле, Аллаһыга мең шөкер. Ышанычлы терәгем – ирем, газиз балаларым, туганнарым бар.

Тормышта үз урынымны табуым, кешеләргә, диндәшләремә, милләттәшләремә ярдәм итә алуым сөендерә.

Барысы өчен дә Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылам.



## Минниса Садыкова:

# «Любую работу нужно делать с любовью»

***В жизни мы часто слышим выражения – начать всё сначала, с чистого листа, повернуть свою судьбу на 180 градусов, кардинально сменить род занятий, заново расставить жизненные приоритеты и так далее. На эту тему написаны тысячи книг, сняты сотни фильмов и сериалов, обнародована масса биографий известных людей, да и вы сами наверняка пытались не раз резко поменять что-то в своей жизни, но чтобы человек сделал это на шестом десятке – случай уникальный. А чтобы такие повороты еще и были успешными... Но один пример я теперь знаю. Это фермер из с. Новый Буян Минниса Саидгалиевна Садыкова, которой совсем недавно исполнилось 75 лет.***

На протяжении 26 лет Минниса работала учителем начальных классов в куйбышевской школе № 36 (ныне школа № 137 города Самары), где до того сама же училась. Работала с большим удовольствием, любила детей, была им предана и практическими с ними не расставалась. По выходным возила на экскурсии, на прогулки в парк и пр. Дети отвечали ей взаимностью. Молодая учительница смогла найти подход к малышам из начальных классов, даже не имея специализированного образования. Она окончила пединститут как преподаватель русского языка и литературы, но когда пришла работать в школу, директор, хотя и не сразу, но уговорила молодого специалиста скорректировать свою специализацию. Дело в том, что в тот год в Железнодорожном районе был какой-то нереальный наплыв первоклашек. Поэтому в начальной школе образовался дефицит педагогов. На возражения Миннисы о том, что у нее нет профессиональных знаний для работы с детьми такого возраста, в руководстве школы отвечали, ничего страшного. Походите на уроки коллег, посмотрите, как они работают, и быстро научитесь. Но училась Минниса, скорее не на опыте других учителей, а на их ошибках. Видела, как не надо делать. Она сразу поняла, что общаться с детьми высокомерно, а тем более кричать просто недопустимо. Она в такой ситуации мысленно ставила себя



на место ребенка и чувствовала страх, беззащитность перед учителем. Решение было очевидным – никогда она не станет кричать на детей и ругать их. Так и стала работать, сначала со слезами на глазах, от страха, что может не справиться, потом поняла: учить детей – это ее призвание. Старалась быть всегда рядом, полезной для маленьких школяров.

После 26 лет работы появилось чувство, что нужно что-то менять, в городе стало тесно, некомфортно. Возможно, сказались родственные гены. Родное село Садыковых – Андреевка Ульяновской области. Отец служил в Витебске, был кавалеристом, там многодетную уже семью застала война. После 1945 года Садыковы поселились в Куйбышеве, где и родилась наша героиня. Садыков-старший всю свою жизнь трепетно относился к лошадям. Бывало, что увидит по телевизору и плачет, особенно если кони военные. Вот и Миннисе захотелось переехать поближе к земле, тем более что в стране вышло постановление о выслуге лет для педагогов, в котором говорилось, что после 25 лет работы можно уйти на пенсию. Дом в Новом Буяне уже был, его использовали как дачу, и оставалось только собрать вещи и уехать.

Правда, новую, деревенскую жизнь Минниса абсолютно не знала. Окунулась в нее, как в омут с головой. Она просто хотела спокойно, размеренно жить на земле, вести небольшое хозяйство, общаться с соседями, любоваться природой. Мама, кстати, была против переезда дочери в Новый Буян, сказала –





Одновременно, но от случая к случаю, он делал переводы на русский и для журнала «Татарстан», руководство которого ввело его в состав редколлегии. В «Чаяне» Валеев трудился до 1996 года, после чего, видимо, стал наконец-то реальным персональным пенсионером республиканского (РСФСР) значения. Правда, неизвестно, когда он завершил деловые контакты с «Татарстаном». По крайней мере, осенью 2006 года главный редактор этого СМИ Р. Фаттахов, поздравляя юбиляра с 85-летием, отметил: «Шаукат Валеев даже в столь почтенном возрасте поддерживает связь с редакцией и имеет современные взгляды на жизнь». А годом ранее эти взгляды и опыт позволили нашему земляку выступить с сообщением на научно-практической конференции журфака КГУ.

Как ветеран Великой Отечественной войны он имел несколько медалей, напоминавших о трудной жизни того периода. Похожими наградами обладала и его супруга, но как участница упомянутой войны. Уроженка Астрахани Асма Ахметовна Нурмухаметова училась на инязе Казанского пединститута, однако окончить его не успела, так как была призвана в Красную Армию. Служила она переводчицей в Управлении контрразведки Смерш (Смерть шпионам) 4-го Украинского фронта, а после Дня Победы – в таком же управлении, действовавшем в ГСОВГ (Группе советских оккупационных войск в Германии). В качестве прикрытия, видимо, носила погоны лейтенанта медицинской службы.

По документам ГУК (Главного управления кадров) демобилизовалась Асма ханум в декабре 1948 года и тогда же соединила свою судьбу с богатой на виражи судьбой нашего героя. Как им так быстро удалось принять брачное решение – история умалчивает. Но предположение есть. Вероятно, знакомство состоялось раньше, когда переводчица приезжала экстерном сдавать госэкзамены и получать диплом.

Их союз, судя по всему, удался. Супруги не имели пристрастия к роскоши и довольствовались тем, что было заработано честным трудом. Асма апа всю жизнь прора-



О присвоении почетного звания, 1981 год




Почетная грамота Президиума ВС ТАССР, 1987 год




Поздравление от Президента России, 2006 год



Книга Ш.М. Валеева

ботала преподавателем немецкого языка в КГУ – вплоть до пенсии, на которую вышла в 1975 году. Она была активным членом общества – бессменно возглавляла кафедральную партгруппу. Чем занимался ее муж, мы уже поведали. Два деловитых и рассудительных, пунктуальных и волевых человека жили очень дружно. С дочерями они общались по-взрослому, не диктуя родительскую волю и учитывая их интересы и желания. Языком семейного общения был «великий и могучий», но с бабушкой все говорили по-татарски, так как она русского не знала.

Старшая дочь Валеевых Фарида, мечтавшая со школьных лет стать врачом, после окончания Казанского мединститута, работала сначала рентгенологом, а после выхода на пенсию – врачом-физиотерапевтом. Она и ее сестра Наиля подарили родителям по внуку. Младший из них (Ирек) жил со своей мамой в пригороде Казани, и поэтому частого общения с дедом у него не получалось. Зато старшему внуку Тимуру, жившему неподалеку, доставалась вся забота и внимание его любимого дәү әти. Не было ни одной затеи, ни одного детского «проекта», в которых бы дед охотно не принял участия, используя каждую возможность научить внука чему-то полезному, поделиться с ним богатым опытом, но и, в то же время, поддержать детский энтузиазм. Хорошо владевший плотницким инструментом, Шаукат абый с удовольствием мастерил с мальчиком, передавая ему свои навыки, полезные «в хозяйстве».

По мере взросления Тимура их совместные затеи стали меняться. Теперь уже больше времени проходило в разговорах и рассуждениях на интересовавшие внука темы, которые чаще всего возникали во время совместных прогулок. Много внимания Шаукат Мирсаяфович уделял передаче внуку умения грамотно, логично и понятно излагать на бумаге свои мысли. Он давал старшекласснику Тимуру «мастер-классы» по написанию школьных сочинений. Позже, когда внук, получив высшее образование в Казанском финансово-экономическом институте, работал над диссертацией, дәү әти просиживал с ним часами, подсказывая Тимуру, как более стройно отразить в тексте идеи и замыслы аспиранта. Со временем Т. Валеев окончил еще и юрфак КГУ и начал трудиться юристом. При этом стадия подготовки его выступлений в суде проходила с участием деда-наставника – в роли слушателя и спарринг-партнера, который указывал внуку на уязвимые места его письменных и устных заявлений.



С женой, дочерьми и внуками, 1986 год

В эти годы на полную мощь в старшем внуке «заработала» привитая дедом привычка находить ответы на все вопросы самому и не принимать на веру бездоказательные высказывания других. Вот что о зарождении такого подхода вспоминает Тимур эфенди: «Достигнув “возраста почемучек”, я обрушивал



С годовалым внуком Тимуром, 1976 год



С дочерьми в день своего 90-летия, 2011 год

на своих родных град вопросов. А у дәү әти была особая манера (и, главное, терпение!) превращать каждый мой вопрос в своего рода мини-урок. Как сейчас помню его выражение: “Хороший вопрос, Тимурик. А давай попробуем найти ответ на него вместе?” И с этими словами дед доставал с полки нужный том Большой Советской Энциклопедии (недостатка в них дома не было) и открывал на соответствующей странице, давая мне возможность самому извлечь из статьи ответ на интересовавший вопрос».

Внимание нашего героя доставалось, конечно, и младшему внуку – трудяге и эрудиту, окончившему факультет управления и автоматизации КГТУ (КХТИ). Вообще, свое свободное время Шаукат абый предпочитал заполнять разными делами и «проектами», перемежая физическую и умственную активность. Этот принцип в рамках его любви к жестко соблюдаемому распорядку дня распространялся и на рабочие часы. Даже небольшой послеобеденный отдых в выходные дни, который Ш. Валеев с присущим ему юмором называл «принять горизонтальное положение», был спланирован так, что после него следовал период повышенной активности: либо прогулка в интенсивном темпе, либо работа над новой статьей или переводом. Кроме того, в его ежедневном расписании особое внимание уделялось чтению прессы и просмотру новостей, причем всегда с ручкой и блокнотом в руке, чтобы записать пришедшую мысль – привычка, выработанная годами журналистской практики.

Каждое утро героя нашей статьи в годы, предшествовавшие уходу на пенсию, начиналось с утренней гимнастики, за которой следовали водные процедуры и растирание полотенцем. Тогда еще не была популярна концепция «10 тысяч шагов в день», но он в любую погоду ежедневно выполнял свою «норму по шагистике» с шагомером и секундомером в кармане. За счет этих упражнений Шаукат ага каждый раз восстанавливался после инфарктов и добавлял себе годы активной жизни.

Его любимой фразой, по мнению внука Тимура, было очень короткое высказывание – «Жизнь многогранна». Оно произносилось довольно часто и в разных ситуациях. Шла ли речь о выбрасывании на свалку деталей рассыпавшегося домашнего прибора, либо о планах на будущее или о чем-то еще, глава дома всегда пускал в ход данную мудрость, призывавшую его домочадцев более широко взглянуть на ситуацию, оценить сценарии ее развития и лишь потом принимать решение. В итоге, когда вдруг дома требовалась какая-нибудь «маленькая штуковина», Шаукат абый доставал из своего хранилища требуемый предмет, попавший туда в результате разбора перегоревшего два года назад утюга, который наш земляк не разрешил отнести на свалку. Такая демонстрация жизненной силы его девиза всегда впечатляла близких родственников.

В 1997 году, не дожив до «золотой» свадьбы, скончалась Асма ханум. После этого десяток лет Шаукат Мирсаяфович жил в одной квартире с членами семьи Тимура – вплоть до их переезда в другой город в 2008 году. Затем до последних своих дней он был на попечении своей младшей дочери. Почувствовать себя одиноким его дочки ему не давали даже в те редкие периоды, когда он жил один. Они ежедневно навещали отца и помогали решать все бытовые вопросы.

Осенью 2001 года упоминавшийся выше главный редактор



Дружеский шарж к 60-летию Ш.М. Валеева

журнала «Татарстан» Р. А. Фаттахов подписал приказ об установлении Ш. М. Валееву ежемесячной надбавки к пенсии за счет фонда редакции. А тот продолжал при случае переводить с родного на русский статьи и фельетоны, а также писать заметки на разные темы под псевдонимом Ш. Мирсаяпов. Среди сданных им в 2009 году на хранение в Государственный архив Республики Татарстан документов и материалов значатся рукописи переводов Валеевым следующих рассказов: М.Абдуллина «Фаргелет» (2003), Р. Муллина «Сноха» (2003), Г. Салахова «История с перцем» (2003), А. Хасанова «Какие только номера не откалывал Заки Нури» (2003) и очерков: М. Аглиуллина «Новые горизонты Новошешминска» (2002), «Выстоять в океане рыночных отношений» (2003) и З. Зайнуллина «Ребенок родился» (2004).

В 2011 году 90-летнего юбиляра поздравил с днем рождении Президент Татарстана Р. Н. Минниханов и вручил ему картину с видом Казани. Но 29 апреля 2012 года наш герой завершил свой жизненный путь. Похоронили его на Ново-Татарском кладбище Казани. К 100-летию Шауката Мирсаяфовича Государственный архив РТ организовал интернет-выставку, на которой представил документы и фотографии, составляющие часть фонда Ш. М. Валеева.


Президент РТ Р.Н. Минниханов поздравляет Ш.М. Валеева с 90-летием, 2011 год

Может быть, я заблуждаюсь, предполагая, что пренебрежительное отношение к советскому прошлому, превалировавшее в конце прошлого века и начале текущего столетия, постепенно перестает быть модным. История страны не может состоять из одних только негативов. Куда плодотворнее чтить прошлое, анализировать его, осмысливать накопленный опыт и на этой базе выстраивать день сегодняшний и грядущий.

Думается, нынешние журналисты и организаторы масс-медиа могут найти для себя много интересного в биографии героя этой статьи, спорившего с судьбой, и в его упомянутой книге. Кстати, выступая на торжественном вечере в честь своего 85-летия, он назвал проводимую в РТ политику внимательного отношения к старшему поколению и историческому прошлому народа «проявлением искренней нравственности». Уловил, стало быть, Шаукат абый, ветры перемен...

*Иҗат кешеләре белән аралашуы кызык та инде! Алар үзенчәлекле фикер йөртәләр, хис-тойгыларын яшермиләр, тормыш матурлыгы, табигатьнең күркәм мизгелләре турында ихластан сокланып сөйлиләр. Үзләрендә хәтта балаларга хас булган самимилек чагыла, дип тә әйтер идем.*

*Миләүшә Газимова*



# Фәрид Шириязданов: "Туган авылым табигате – мине иҗатка рухландыручы илһам чыганагы"

Мөхәммәтнур улы Фәрид Шириязданов да – нәкъ шундый иҗади шәхесләрнең берсе. Гомумән, ул эчке дөньясы белән генә түгел, ә тышкы кыяфәте белән дә кешеләрне үзенә җәлеп итеп тора. Нурлы күзләреннән, ихлас елмаюыннан, ачык йөзеннән үк аның саф күңелле, эчкерсез, гади булуы күренә.

Фәрид әфәнде күп еллар Самар өлкәсенең "Сәлам" газетасында эшләде. Ул – "Булгарская цивилизация на Волге", "Иске Ярмәк авылы тарихы", "Подвиг длиною в жизнь" дип исемләнгән тарихи китаплар һәм йөздән артык шигырь авторы.



Ширияздановлар гаиләсе

Февраль аенда Фәрид Шириязданов 75 яшен тутырды. Без милләттәшебез белән аның иҗатына, шәхси тормышына кагылышлы темаларга сөйләшеп алдык.

***– Фәрид абый, "без барыбыз да – балачак иленнән", диләр бит. Кечкенә чакларыгыздагы кайсы вакыйгаларны бигрәкләр дә сагынып искә аласыз?***

– Мин – Камышлы районындагы Иске Ярмәк авылының гүзәл табигать кочагында үскән кеше. Һәм, әлбәттә инде, иң якты истәлекләрем дә табигать белән бәйле – Сок елгасы, Юкәле, Чиялек таулары, Мисбах күле...

Иптәш малайлар белән бергә комлыкта кояшның шифалы нурлары астында кызынулар, су керүләр, өстебездәге күлмәкләрдән капчык ясап, шунда кузгалак, какы җыюлар, хәтфәдәй болыннарда каз бәбкәләре саклаулар, ташу карарга төшүләр, урамда аккан гөрләвекләрдә кәгазь көймәләр йөз-

деруләр, кош оялары ясап, ямьле язларда сыерчыкларны көтеп алулар...



Фәрид әфәнденең әтисе Мөхәммәтнур, әнисе Камәр

Урман аша унсигез чакрым араны җәяү үтеп, Кләүлегә поезд карарга, лимонад эчәргә йөрдек. Ундүрт чакрымны узып, Камышлы ашханәсенә кәтлит ашарга бара идек. Боларның барысы да әлегә кадәр йөрәк түрендә күңелле, күркәм, җылы хатирәләр булып саклана.

Мин – табигать кешесе. Аңардан дәрт-дәрман, кодрәт, илһам алып, сафланып, моңланып, аның матурлыгына сокланып, сихерләнеп үстем.

Бәхетле, гамьсез вакытлар иде бу. Әти-әниләр юк-бар әйбер сатып алсалар да, түбә күккә тия, булганның кадерен белә торган чаклар.

Без – хезмәт белән тәрбияләнгән буын. Әти-әниләребезгә, әби-бабайларыбызга ярдәм итәргә дә, мәктәптә бирелгән өй эшләрен эшләргә дә, уйнарга да өлгерә идек.

Безгә төпле белеп биргән укытучыларым да сагындыра. Араларында фронттан кайткан мөгаллимнәр дә бар иде. Алар күңелебезгә көчле ватанпәрвәрлек хисләре сеңдерделәр.

Гомумән, бөтен укытучыларыбыз да киңкырлы, затлы, зыялы шәхесләр, үз эшләренең осталары, югары профессионал, чын остазлар булдылар.

Минем әтием Мөхәммәтнур, әнием Камәр дә мөгаллимнәр иде. Әткәй физкультура дәресен алып барды, ә әнкәй математиканы укытты.

Үз фәненә җаны-тәне белән бирелгән әтием – мәктәптә һәм, гомумән, авылда спорт һәм физик культураны үстерүгә олуг өлеш керткән шәхес. Хәзер Иске Ярмәктә аның истәлегенә чаңгы ярышлары үткәрелеп килә.

Сигезенче сыйныфка кадәр бөтен фәннәрне дә татарча укыдык без. Әмма рус телен дә бик яхшы белә идек. Иншаларны хәтта рус малайлары миннән күчерәләр иде! Монда укытучыбыз Рәйсә апа Шәрәфетдинованың хезмәте зурдан.

Рәйсә ханым безгә рус теленнән нинди яхшы гыйлем бирсә, татар телен укыткан Әнисә апа Әхмәдуллина үз фәнен шулай ук югары дәрәҗәдә укытты. Ул шундый тәмле итеп сөйли иде ки, без аны онытылып тыңлап утыра идек. Хәтта хулиган малайларыбызның да аның дәресләрендә тыннары да чыкмый иде. Әнисә апа да җаныннән биреп укытты, без дә күңел биреп белем алдык.



Яраткан хатыны Раушания

Кечкенә чаклардагы тагын бер матур күренеш хәтергә сеңеп калган. Ул вакытларда бер нигездә берничә буын яши, балалар тулы гаиләләрдә үсәләр иде. Минем әтиемнең дә ата-анасы безнең белән бергә тордылар. Миңа әби-бабай тәрбиясен күрү бәхете татыды.

Малайларыбыз тәмәке тартмыйлар, сүгенмиләр, кызларыбыз тыйнак киенеп йөриләр иде. Олыларны хөрмәт иттек, үзебездән кечеләрне кыерсытмадык, бердәмлекнең асылын тоеп үстек. Аллаһыга шөкер, балачагыбыз бәхетле булды безнең. Хәзер аны сагынып, шигъри юлларга салырга гына калды:



Фәрид әфәнденең улы Рафаэль һәм килене Ирида

*«Сулар тарта!» дигән сүздә —*
*Тарту көче туган ягымның,*
*Сок буйлары, эзлим сездә*
*Посып калган балачагымны.*
*Мисбах күле буйларына*
*Һаман тарта чишмә сукмагы,*
*Коткы салып уйларыма,*
*Тынгы бирми хәтер тукмагы.*
*Гөрләп торган бака күлен,*
*Каз саклаган дымлы чирәмен,*
*Төшләремдә бик еш күреп,*
*Чишмә буен урап үтәмен...*

***– Авыл хуҗалыгы институтында зоотехник һөнәрен үзләштереп, үз белгечлегегез буенча эшләгәнсез. Аннары юридик белем дә алгансыз. Әмма тормыш юлыгыз кискен борылып, иҗат дөньясына чумгансыз. Бу ничегрәк килеп чыкты соң?***

– Иҗатка мәхәббәт кечкенәдән

каныма сеңгән. Әле мәктәптә укыганда ук шигырьләр язгалый идем. Укытучылар иншаларымны мактыйлар иде.

Һади Такташ, Сергей Есенин, Евгений Евтушенко, Генрих Гейне иҗатына мөкиббән булдым. Китап укырга бик яраттым. Гитарада да уйнадым, рәсем, скульптуралар да ясый идем.


Оныгы Диләра

Шигырь язучы этиемнең дә тәэсире тигәндер, аның сәләте миңа да күчкәндер, дип уйлыйм.

Әйе, иҗат белән бәйләнмәгән төрле җирләрдә, төрле эшләрдә эшләргә туры килде. Тормыш үз таләпләрен куя бит ул. Әмма гомерем буе барыбер иҗатка тартылдым, бу Аллаһы Тәгалә тарафыннан күңелемә салынган булгандыр инде.

Зоотехник булып эшләгәндә җитәкчебез: "Фарид, ты проекты приказов как стихи пишешь", – дип елмая торган иде.

Шуңа күрә дә мине Самар өлкәсенең "Сәлам" газетасына эшкә чакыргач, бу тәкъдимне шатланып кабул иттем. Аңа кадәр дә "Бердәмлек" газетасында язмаларым, шигырьләрем чыккалый иде инде. Бүгенге көндә мин "Самар татарлары" журналы белән тыгыз хезмәттәшлек итәм, төрле темаларга багышланган мәкаләләр язам.

Кемдер яшьтән үк яраткан эшен башкара, икенчеләргә бу еллар узу белән генә бирелә, ә кайберәүләрнең теләк-хыяллары беркайчан да тормышка ашырылмаска мөмкин. Миңа да күңелем тарткан хезмәт белән шөгыльләнер өчен, бәлки, башта тормыш тәҗрибәсе тупларга, дөнья күрергә, кешеләрнең асылын ачыкларга өйрәнергә, үземдә нindидер сыйфатлар тәрбияләргә кирәк булгандыр.

***– Иҗади хатын-кызлар гадәттә нечкә күңелле, йомшак, хискә бирелүчән булалар. Ә иҗади ир-атлар нинди икән?***

– Ир-атмы, хатын-кызмы ул, нечкә күңелле түгелсең икән, иҗат кешесе була алмыйсың, дип саныйм мин.

Иҗади шәхесләр, иң беренче чиратта, матурлыкны күрә беләләр, һәрнәрсәне җентекләп күзәтәләр бит. Яфракларның селкенгән тавышын да ишетеп алалар алар, кечкенә кырмысканың җан-фәрман эшләгәнен дә кызыксынып карап торалар, кышкы суык көннәрдә тәрәзәгә төшкән бизәкләргә дә чын күңелдән сокланалар. Моны бары тик нечкә күңелле кешеләр генә булдыра ала, минемчә.

Шул ук җыр язарга, рәсем ясарга да табигать ритмнарын йөрәгең аша үткәрә белергә кирәктер.

***– Сезнең өч тарихи китабыгыз дөнья күрде. Бу – галәмәт мәшәкатьле, четерекле эш. Китап язганда сезнең өчен иң авыры нәрсә булды?***

– Әйе, беренче китабым «Булгарская цивилизация на Волге» дип атала. Икенчесе – туган авылым Иске Ярмәк, ә өченчесе Кошки районының Иске Фәйзулла авылы тарихы турында.

Иң кыены халыкка моның кирәклеген аңлату иде. Күбесен кузгата алдым. Әмма битараф калганнары да булды шул. Шулай итеп, китапта тасвирланырга тиешле кешеләр, вакыйгалар турында мәгълүмат җыйганда авырлыклар да туглады.


Фәрид әфәнде һәм Гомәр Батршин. «Булгарская цивилизация на Волге» китабы өчен бүләкләр алганда

Сүз уңаеннан, китапларымны язганда зур активлык, ярдәм күрсәткән, булсын, дип тырышкан һәрбер кешегә олуг рәхмәтләремне белдерәм.


Хатыны Раушания (сулдан икенче), кызы Зөлфия (уңнан икенче), оныгы Алинә (уңнан беренче) Иске Фәйзуллада туганнары арасында

***– Басылып чыккан китапларыгыз халык тарафыннан лаеклы рәвештә бәяләнде, дип әйтә аласызмы?***

– Аллаһыга шөкер, рәхмәт әйтүчеләр булды. Китапны укып, хатирәләрен яңарталар, үткән елларны исләренә төшерәләр, үзләре өчен яңалыклар ачалар.

Кайберәүләрдән: "Синең китабыңда менә шулай язылган", "Китабыңда фәлән теманы күтәргәнсең, кешеләргә аны тагын да үстереп җиткерү турында уйлансаң иде", – дигән сүзләр ишетелгәли. Димәк, алар асылына төшенеп укыган, исләрендә калдырган! Бу инде, әлбәттә, йөрәгемә май булып ята, зур шатлык хисләре уята.

Әйтик, «Булгарская цивилизация на Волге» китабы Татарстанның беренче Президенты Минтимер ага Шәймиев тарафыннан югары бәяләнде. Миңа Болгариядән Кубрат ханның мөһере сурәтләнгән көмеш медальон бүләк иттеләр.

Иске Ярмәк тарихына багышланган китабым исә өлкәбездә генә танылып калмады, ә Бөтендөнья татар конгрессы бинасындагы күргәзмә залында татар авыллары

турындагы өч меңләп китап арасында лаеклы урын алды. Конгресс тарафыннан миңа «Татар халкына күрсәткән олы хезмәтләре өчен» дигән медаль тапшырылды.

***– Яңа китап язу турында уйламыйсызмы?***

– Бу эшкә керештем инде. Аның нәрсә турында булуы әлегә сер булып калсын (елмая).

Гомумән, иҗат эшеннән башка озак тора алмыйм мин, күңелем китек, тормышта нәрсәдер җитми сыман, җанымда бушлык хасил була.

***– Мәкаләләрдән тыш, шигырьләр дә иҗат итәсез. Бу мавыгуыгыз сезнең өчен никадәр мөһим?***



Иске Фәйзулла авылы имамы Габделхак хәзрәт Халитов белән китап турында сөйләшү алып барганда

– Күңелемдә аерым бер әһәмиятле урын алып торсалар да, соңгы вакытларда шигырьләр язганым юк. Эш шунда ки, моңа тулысынча кереп китәргә, тулысынча шуңа бирелергә, җан иркенлеге кирәк.

Бөек шагыйрь Владимир Маяковский язганча:

*«Поэзия – та же добыча радия.*
*В грамм добыча, в год труды.*
*Изводишь единого слова ради*
*Тысячи тонн словесной руды».*

Минемчә, шигырь язсаң, ул сыйфатлы, тирән мәгънәле, кешеләрдә көчле хисләр уятырлык булырга тиеш. Элгәреге елларда иҗат иткән йөздән артык шигырем бар. Аларда фәлсәфи фикерләр, үткәннәргә мәдхия яңгырый.

***– Туып-үскән авылыгыз Иске Ярмәк иҗатыгызда илһам һәм шигърият чыганагы булып торамы?***

– Әлбәттә! Саф чишмәләр, куе урманнар, йомшак үләнле болыннар, баһадирдай нык таулар, бөдрә таллар, гомумән, газиз авылым табигате мине язарга этәрә, күңелгә асыл фикерләр, тирән уйлар, кичерешләр сала.

Иҗат җимешләремнең күбесе туган җиремә багышланган:

*Уйларым сулардай агыла,*
*Сок буе талларын сагынам,*
*Чыкканда Юкәле тау ягына,*
*Кайткандай яшьлегем янына.*
*Саклагыз, изге тау яннары,*
*Балачак буйлаган эзләрне,*
*Әтәчләр уяткан таңнарның*
*Сиреньнәр тараткан исләрен.*
*Саклагыз, елганың ярлары,*
*Бирегә сөйләнгән серләрне,*
*Күңелне назлаган язларда*
*Өзелеп көзләгән йөзләрне.*
*Юкәле тау – яшьлегем сандыгы,*
*Саклый кур иң якты хисләрне,*
*Беренче тойгылар сафлыгын,*
*Иң матур хыялый кичләрне.*
*Очынып учактан чаткылар,*
*Көл булып үләнгә ятканда,*
*Уйларым яшьлеккә чаптылар,*
*Сиреньнәр күк чәчәк атканда.*

***– Иҗат кешесе булуыгызны хатыныгыз Раушания ничек кабул итә?***

– Ул моңа беркайчан да каршы килмәде. Кызыксынып, төшенеп, иҗат җимешләремә лаеклы бәя биреп, мине хуплап яши. Үзенә рәхмәтлемен.

***– Журналистка нинди сыйфатларга ия булырга кирәк?***

– Кеше күңеленә ачкыч таба белергә, дөньяга киң карашлы, әдәпле, намуслы булырга тиеш ул.

**– “Тынгысыз җан” дигән гыйбарә сезнең холкыгызга туры киләме?**

– Әйе, бик тә туры килә. Үзалдыма берәр нинди максат куйсам, шуны тормышка ашырганчы, үземә тынычлык таба алмыйм. Шул турыда уйланып, борчылып йөрим.

Гомумән, иҗади шәхесләр – тынгысыз җаннардыр инде ул. Нечкә күңелле булгач, бөтен нәрсәне дә йөрәккә якын алабыз бит без. Берәр нәрсә эшләсәк, шуңа тулысынча биреләбез, күңелебез аша үткәрәбез. Очына чыкканчы, нәтиҗәсе нинди булыр икән, дип дулкынланабыз.

***– Гомерегез буе үзегездә нинди сыйфатлар тәрбияләргә тырыштыгыз?***

– Тәвәккәллек, тапкырлык.

***– Сезне аралашучан кеше буларак беләм. Хәзерге яшегездә дә башкалардан нәрсәгә булса да өйрәнәсезме?***

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.: «Бишектән алып, ләхеткә кадәр гыйлем алыгыз», – дип әйтеп калдырган.

Һәр адәмнең күркәм яклары, үзенчәлекләре, яхшы гамәлләре, осталыгы, сәләте бар. Һәр кешедән нәрсәгә булса да өйрәнергә була. Әңгәмә барышында аңардан үзең өчен барыбер нәрсә булса да аласың.

***– Бер хәбәрчегә биргән әңгәмәгездә: “Берәүләр үз юлын бик тиз табалар, икенчеләренә байтак эзләнергә туры килә”, – дип әйткән булгансыз. Ә сезнең ничегрәк булды һәм бүгенге көндә тормышта үз юлымны таптым, дип тулы ышаныч белән әйтә аласызмы?***

– Куйган хезмәтем, омтылышларым кемгәдер кирәк, файда китерә һәм үзем дә шуңардан канәгатьлек табам икән, димәк, туры юлдан барам, дип саныйм.

Иҗат юлына чыкканчы, байтак вакыт узса да, бернигә дә үкенмим, әлхәмдүлилләһ.

Киләчәктә дә, бай тормыш тәҗрибәмне дөрес кулланып, горурланырлык халкыма файда китереп, үземә дә, кешеләргә дә иҗатымнан ямь табып яшәргә насыйп булсын иде, дип телим.

***– Амин, Фәрид абый, Аллаһы Тәгалә насыйп итсен!***

# ГЕОГРАФИЯ САЛЬКИНА

*Юрий Левичев*



Звонок от председателя Совета ветеранов Алексеевского отдела полиции Хамзи Юнусовича Салькина прозвучал аккурат перед ужином. Отложил тарелку в сторону. Вышел в другую комнату, чтобы не мешать супруге с дочкой и внучкой вкушать то, что бог послал…

– Слушай, Юрий Иванович, раньше не мог позвонить, извини. Дела, сам понимаешь…

– Святое дело, Хамзя, не нужно оправдываться. Это нормально. И правильно…

Хамзя Юнусович Салькин, полковник полиции в отставке, в определенном смысле человек легендарный в системе органов внутренних дел Самарской области. Возглавлял в разное время отстающие райотделы милиции: Большечерниговский, Большеглушицкий, Самарский районный в областном центре, Алексеевский… И вытаскивал их, подтягивал к уровню если не лидеров по раскрываемости преступлений, то уж точно в уверенные середняки в городах и районах. Причем делал это реально, а не играя с количеством уголовных дел, возбужденных, направленных в суд или прекращенных по надуманным основаниям. И везде, куда его посылало начальство, нужно было решать вопросы не только стабилизации оперативной обстановки, а пробивать подвод питьевой воды в здание райотдела, водоотведение из мест общего пользования в подразделении, газификации, ремонта помещений, строительства и благоустройства. Хватало и сил, и энергии, и опыта… И со всеми главами муниципальных образований он устанавливал исключительно деловые контакты. Ну, а два года назад ветераны отдела МВД России по Алексеевскому району избрали его своим вожаком – председателем первичной ветеранской организации.

– Хамзя Юнусович, как там твои старпёры, голосовать на выборы президента пойдут аль нет?

– Юрий Иванович, говорил практически с каждым ветераном. Пой-

дут все. Кто не сможет, направим к ним комиссии с урнами. Дома проголосуют. Мои ветераны и для СВО не скупятся с помощью, и понимают всю сложность обстановки. Им даже объяснять ничего не нужно. С собой родню приведут. С соседями переговорят, чтобы не замыкались. Мы ж не давим на выбор конкретного кандидата. Просим просто прийти на избирательный участок.

– Это правильно, Хамзя. Хорошо, если каждый сельчанин определится в выборе...

Хамзя Салькин начинал службу в далеком 1982 году оперуполномоченным ОБХСС в Алексеевском РОВД, а закончил ее в 2015-м. Выслуга составила 37 лет, из которых 23,5 года он пребывал в должности руководителя того или иного отдела внутренних дел. Нет в области других таких начальников подразделений. Своеобразный рекорд в Самарской области. А может быть, и во всей России.

Было время, когда распутывал сложнейшие дела по линии борьбы с хищениями. Человек общительный и коммуникабельный, он даже по пути из дома на службу разговаривал, да и сейчас разговаривает с односельчанами просто и доверительно. И потому «кровников» из отданных под суд себе не нажил. А вот доверие сельчан и к себе как к личности и в целом, как руководитель подразделения имел вполне осязаемое...

«Если бы заново родился, опять бы пошел в милицию» – так однажды выразился Хамзя Юнусович в одном из интервью газете «Право». Родился он в Ульяновской области в многодетной семье. В юношестве даже не мечтал о милиции. Хотел стать агрономом. После школы призвали в армию. Служил в Чехословакии наводчиком 120-мм самоходной артиллерийской установки. Был одним из первых по физической подготовке в подразделении. Да и в политической тоже не примыкал к отстающим. По совету своего командира, после демобилизации прошел оформление на службу в органы внутренних дел.

Когда он был еще капитаном милиции, руководство главка решило выдвинуть его начальником Алексеевского РОВД. К тому времени Салькин уже окончил Самарский государственный университет по специальности «правоведение». Так у 32-летнего офицера милиции начался ответственный и долгий путь руководителя милицейских подразделений. Были ротации, переброски с одного района в другой. Такая вот сложная география. Трудно было это принять и супруге, и детям. Но служба есть служба... Офицеру не рассуждать нужно при назначениях, а четко и без возражений выполнять приказы начальства.

Сын Хамзи Юнусовича нынче работник прокуратуры. Получив юридическое образование, посвятил себя правоохранной деятельности. А глава семейства и сегодня передает свой богатый опыт действующим сотрудникам полиции. А как иначе? Все должно иметь продолжение... И полковник Салькин верит, что молодежь продолжит славные традиции ветеранов. Иначе просто быть не может.

***Президиум Самарской областной общественной организации ветеранов органов внутренних дел и внутренних войск поздравляет полковника полиции в отставке Хамзю Юнусовича Салькина с юбилеем – 65-летием со дня рождения.***




Свою службу в органах внутренних дел он начал с должности оперуполномоченного ОБХСС в Алексеевском РОВД в 1982 году. Из 37 лет службы 23,5 года находился на руководящих должностях в Большечерниговском, Большеглушицком, Самарском РОВД областного центра. На заслуженный отдых ушел, будучи начальником отдела полиции МВД России по Алексеевскому району Самарской области. Зарекомендовал себя как профессионал своего дела, чуткий к нуждам и запросам личного состава подчиненных подразделений. Награжден многими ведомственными наградами МВД России.

***Ветераны органов внутренних дел Самарской области желают Хамзе Юнусовичу Салькину крепкого здоровья, большого личного счастья и успехов в общественной работе во благо каждого ветерана и нашей любимой Родины – России.***

***Пусть всё получится, дорогой товарищ полковник!***

информационный медиапортал

Самарские татары

Самар татарлары

samtatnews.ru

Самарские татарские новости

ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР



## Все журналы на одной площадке

Дорогие друзья! Спешим порадовать вас хорошей новостью. Завершена большая работа по оцифровке всех номеров журнала «Самар татарлары». В сети Интернет по адресу **tatmagazine.ru** уже сейчас можно найти все номера нашего издания начиная с 2013 года и прочитать в электронном виде любые из ранее публиковавшихся статей. Для вашего удобства разработана удобная навигация, которая позволит без особого труда выбрать тот или иной материал.
От имени нашей редакции хочется сказать огромное спасибо Руслану Шарипову за эту большую и безвозмездную работу.





# АК ӘБИ – АВЫЛ БИЗӘГЕ

***Акыллы, тәҗрибәле, догалы, нурлы ак әбиләребез, һичшиксез, тормышыбызның бизәге булып торалар. Аларны кочаклап аласы, җылы куеннарына сыенасы, йомшак кулларыннан тотасы килә.***

***Миләүшә Газимова***



Минния͡з Мәхмүтшина

Менә 82 яшьлек Минния͡з апа Мәхмүтшина да - шундый сөйкемле, үзенә җәлеп итә торган әбиләрнең берсе.

Ул, Чаллы Баш (Челно-Вершины) районының Совет Нурлаты авылында туып-үсеп, гомере буе шушында яши.

Сугыш чоры балаларының тормышын безгә, яшьләргә, хәзер күз алдына китерүе дә авыр, ә алар шул вакыттагы кыенлыкларны үз башларыннан үткәргәннәр.

“Без әбиебез, әтинең бертуган сеңелесе һәм аның гаиләсе белән бергә яшәдек.

1942 елда әтием Фәттах сугышка киткәндә миңа бер яшь тә сигез ай иде. Ә сеңелем Минниса, алты айлык булып, әни карынында калды.

1943 елда әткәебез сугышта хәбәрсез югалды. Әнкәебез Миннегөлсем дүрт баласын берүзе үстерде.

Иң олы абыебыз 12 яшендә суга батып үлде. Икенче абыем да хәзерге көндә якты дөньяда юк инде. Без 80 яшьлек сеңелем Минниса белән икәү генә калдык. Ул да үзебезнең авылда тора. Аралашып, бер-беребезнең хәлен белешеп, ярдәмләшеп яшибез, Аллаһыга шөкер.

Сугыш вакытында һәм аннан соңгы елларда тормышлар бик тә авыр иде бит инде. Ачлыкны, ялангычлыкны күп күрдек. Әтиебез булмагач, әнигә, мескенкәебезгә, бигрәк тә авырга туры килде. Көнтөн эштә иде ул. Сарык көтүе дә көтте, кул урагы белән урак урды, көлтә бәйләде, кышларын әвен сугарга да йөрде.

Әнкәй үзе дә күркәм холыклы иде, безгә дә яхшы тәрбия бирде. Кешегә каршы сүз дәшмәскә, талашмаска өйрәтте. Без аңардан алган тәрбия белән гомер итәбез, әнинең сүзләре һәрвакыт күңелдә. Әнкәебез безгә биргән тәрбияне без үз балаларыбызга да бирергә тырыштык.

Картайган көннәрендә әни сукырайды. 87 яшендә якты дөньядан китеп барды ул. Урыны җәннәт түрләрендә булсын”, - дип сөйли язмам герое.

Минния͡з апа мәктәптә дүрт сыйныф кына тәмамлаган. “Әниебезгә булышырга кирәк иде, башкача укый алмадым, яшьли эшкә керештем мин”, - ди ул.

Уналты яшендә кызны урман кисәргә җибәргәннәр! Аннары ул күп еллар колхозда сыер савучы, терлек караучы булып эшләгән һәм 50 яшендә лаеклы ялга киткән. Тырыш хезмәте өчен үзенә төрле бүләкләр, мактаунамәләр тапшырганнар. Минния͡з Мәхмүтшина – хезмәт ветераны, социалистик ярышлар алдынгысы, “Ана батырлыгы” билгесе иясе.



Ринат һәм Минния͡з Мәхмүтшиннар балалары белән



Минннияз апа үзенең нурлы йортында



Минннияз ханым бәгырь җимешләре - биш баласы арасында



Минннияз һәм Ринат Мәхмүтшиннарның яшь чагы

“24 яшемдә кияүгә чыктым. Авылыбызның иң уңган, иң матур, иң акыллы егете буларак сайлап алдым мин Ринатны. Һәм, Аллаһыга шөкер, ялгышмадым да. Никахлашканнан көннән бирле без аның белән бик тату, бәхетле яшәдек. Тик менә, кызганыч, иремнең гомере кыска булды шул, 37 ел бергә торып калдык. 23 ел элек, 59 яшендә, кинәттән вафат булды ул.

Аталары балаларыбызга яхшы тәрбия бирде, үзләрен бик яратты. Уллларыбызны ирләрчә яшәргә өйрәтте, кызларыбызга эти киңәшләрен биреп үстерде. Ә инде оныклары өчен өзелеп торды. Алар да, “бабай, бабай”, дип, янынннан да китмиләр иде. Ышанычлы ир булды, киңәшләшеп яшәдек. Балаларым әле дә әткәйләрен бик юксыналар.

Ә аның җырлаганын ишетсәгез икән! Борынгы җырларны сузып җибәрсә, күңел кыллары тибрәлеп китә иде”, - дип сагынып искә ала хәләл җефетен Минннияз әби.

Мәхмүтшиннар йортына килен булып төшкәндә аның каенанасының әнисе Бибикамал да шунда яшәгән. Шулай итеп, Минннияз апа ике бианай белән бергә торган.

“Мин килгәч, каенанамның анасы 10 елдан соң вафат булды. Ә бианам Гайшә белән 40 ел бергә гомер иттек без. Балаларыбызны үстерешергә бик ярдәм иттеләр алар. Үзләреннән бер начар сүз ишетмәдем, беркайчан да кыерсытмадылар, яратышып, әниле-кызлы яшәдек, бер-беребезнең сүзеннән чыкмадык. Акыллы киңәшләре тормыш көткәндә миңа бик кирәк булдылар. Икесенә дә рәхмәтле булып, аларны догалардан калдырмыйм.

Хәләл җефетем үлгәч, дүрт ел-

дан соң 90 яшьлек каенанамны соңгы юлга озаттым. Үзен яхшылап карадым, тәрбияләдем, ул миннән бәхил булып китте, Раббыма шөкер", - ди Минния ханым.

Бүгенге көндә милләттәшебез төп йортларында улы Рәис белән бергә яши.

Әйтергә кирәк, әлеге йортның мактаулы тарихы бар. Эш шунда ки, Совет Нурлатында мәчет булмаган вакытта җомга һәм гает намазлары шушында укылган.

"Дин тыелган заман иде бит. Кешеләр, куркып, үз өйләрен гыйбадәтханә буларак кулланырга рөхсәт итмиләр иде. Ә каенанамның әнисе Бибикамал бик дини, укымышлы, тәвәккәл иде. Шуңа күрә дә ул моңа шатланып риза булды. Бездә чиста-пөхтә, тәртип хөкем сөрә иде. Өстәвенә, өебез үзәк урамда урнашкан. Шул яктан да гыйбадәт кылучыларга бик уңай булды.

Авылыбызда мәчет төзелгәнче, күп еллар намаз укыдылар бездә. Бабайлар, рәхмәтләрен белдереп, безгә күп дога кылдылар", - дип сөйли язмам герое.

"Ул вакытларда без әле кечкенә идек, - дип сүзгә кушылды Минниаз апаның кызы Әлфия. – Бездән кеше беркайчан да өзелмәде. Әни өйне җыештыра, ашарга пешерә, килүчеләрне каршы ала, озатып кала. Бөтен мәшәкатьләр аның җилкәсендә булды. Ничек өлгергәндер инде ул! Колхозда сыер да сауды, йорт тулы эш, терлек тә күп, биш бала. Аннары инде, үсә төшкәч, без аңа ярдәм итә башладык. Җомга алдыннан өйне тулысынча җыештырабыз, әни чиста намазлыкларны әзерләп куя. Ә гает алдыннан бөтен өйне юып чыгу гадәткә кергән иде.

Дини бәйрәмнәргә әнкәй яңа яулыклар, күлмәкләр сатып ала иде. Безне, балаларын, матур итеп киендереп, мич артына кертеп утырта. Бабайларның укыганнарын тын да алмыйча тыңлап торабыз. Алар, намаздан чыккач, бала-чагага тимер акча сибәләр. Күрше-тирәдән җыелган башка балалар белән бергә шуларны җыя идек.

Аллаһыга шөкер, кечкенәдән Коръән сүрәләрен, аятьләрен тыңлап, иманлы йортта, дини әбиләребезнең тәрбиясен алып үстек. Йокыга китәр алдыннан да гыйбадәт кылган әбиебезнең пышпыш догалар укыганын тыңлап ята идек. Алар һаман да колакта яңгырый сыман. Бүгенге көндә инде, әлхәмдүлилләһ, биш вакыт намазын калдырмаган әниебез өйне догалары белән нурландырып яши".

Ринат белән Минниаз Мәхмүтшиннар биш бала үстергәннәр. Кызганыч ки, бер уллары тугыз айлык чагында вафат булган.

Олы кызлары Тәнзилә - Тольяттида, Тәскирә – Әлмәт шәһәрендә, уллары Рифкать – Совет Нурлатында, Әлфия Тупли авылында гомер итәләр. Ә иң кечкенәләре Рәис, инде алдан язганымча, әнисе янында тора.

Минниаз апаның алты оныгы, җиде туруны (правнук) бар. Кызганыч ки, Тәскирә кызының ике малае бик яшьли якты дөнья белән хушлашканнар. Шушы кайгы-хәсрәттән аларның барысының да йөрәк ярасы туктаусыз сыкрап тора...



Минниаз ханым һәм аның зур, тату гаиләсе - балалары, килен-кияүләре, оныклары, туруннары һәм туганнары

"Аллаһы Тәгаләгә мең шөкер, улларым, кызларым тәртипле, тәүфыйклы, миһербанлы. Мин алардан бик канәгать. Үземне зурлап, кадер-хөрмәттә яшәтәләр, карап-тәрбияләп торалар. Кияүләрем Мансур, Равил, Нәҗип, киленем Гүзәлия дә игелекleләр, ярдәмчелләр, мине үз әниләредәй якын күрәләр", - дип, мәрхәмәтле



Минният ханымга - 45 яшь

бала-оныклары өчен изге догалар кылып яши Миннияз әби.

"Әткәй-әнкәебез, андый булыгыз, мондый булыгыз, дип артык сөйләмәделәр. Безне күбрәк үз үрнәкләрендә тәрбияләделәр, - дип сөйләп китте Әлфия ханым. - Аларның сыйфатларын, гамәлләрен күреп үстек, һәм үзебез дә шундый булырга тырыштык.

Матур тормыш алып бардылар алар. Колхозда бергә эшләделәр. Иртән эти атны җигә дә икәү утырып китәләр, кичен шулай ук бергә кайтып керәләр.

Әни этигә карата нинди мөгамәләдә иде, без дә ирләребезгә шундый мөнәсәбәт күрсәтәбез.

Балачакта без йокыдан торганда әнкәйнең миче кабызган, ашарга пешкән иде инде. Кичен без ятканда ул әле һаман да эшләрен эшләп йөри иде.

Әниебезнең кешегә бер начар сүз әйткәне булмады, мәрхәмәтле, ярдәмчел ул. Балаларны бик ярата. Олы оныгы артыннан кабатлап, авылыбызның малайлары, кызлары аны "матур әби", дип атап йөртәләр, хәзер инде бөтен халык та аңа шулай эндәшә.

Безгә тегене эшләгез, моны эшләгез, дип гомердә дә боерганы, тавыш күтәргәне, начар чырай күрсәткәне юк әнинең. Аның киңәшләрен, сүзләрен күңел түренә сеңдереп, һәрвакыт истә тотып яшибез.

Әнкәебез – иң якын, иң яраткан кешебез, ак-кошыбыз, былбылыбыз. Безне елмаеп каршы ала, күз яшьләрен тыя алмыйча озатып кала. Җәннәт аналарның аяк астында икәнлеген белеп яшибез. Раббыбыздан әниебез исән-сау, озын гомерле була күрсен, дип сорыйбыз".

***- Тормышта сезгә кемнәр үрнәк булды?*** – дип кызыксындым Миннияз әбидән.

- Газиз әнием минем өчен иң беренче үрнәк иде. Ул ничек яшәде, мин дә шулай гомер итәргә тырыштым. Безне ялгызы үстереп, тәртипкә, эшкә өйрәтеп, олы тормыш юлына озатучы иң зур кешебез ул.

***- Бәхетле булыр өчен кеше үзе тырышырга тиеш, дип саныйсызмы, әллә ул бары тик Аллаһы Тәгаләдән генә бирелә ме?***

- Тәүфыйклы, акыллы, тырыш булсаң, дин юлыннан атласаң, бәхет шуннан килә. Әгәр инде тәртип бозып яшәсәң, булган бәхетне дә югалтырга мөмкинсең.

***- Хәләл җефетегез белән матур тормыш алып барган кеше буларак, яшь парларга нинди киңәшләр бирер идегез?***

- Аллаһы Тәгаләдән сабырлык сорап, бер-береңне хөрмәт итеп, кадерләп, санга санап, бер-береңнең сүзеннән чыкмыйча яшәү мөһим.

***- Бүгенге көндә нәрсәләргә шатланып гомер итәсез?***

- Аллаһы Тәгалә, һидаят биреп, дин юлыннан атларга насыйп итте. Намазга баскач, Раббым җиңеллекләр бирде, көнкүрешләребез җайланып китте, әлхәмдүлилләһ.

Миһербанлы бала-оныкларым тәрбиясен күрәм.

Ышанычлы дусларым, кадерле туганнарым, яхшы күршеләрем булуына сөенәм.

Кешеләр белән аралашып, кунакка йөрешеп, бергәләп яшәү – үзе бер шатлык бит ул.

***- Аллаһы Тәгалә Коръәндә: «Миннән сорагыз, җавап бирермен», – дигән. Киләчәк турында уйланганда Раббыбыздан ниләр сорыйсыз?***

- Бер Аллаһым, алга таба да шундый тыныч, рәхәт, гыйбрәтле тормышларда гыйбадәтләр кылып яшәргә язсаң иде, дип сорыйм.

Кыямәт көннәрендә җавап тотканда Үз ярдәмеңне бир, безгә җәннәтләреңне насыйп әйлә, дип үтенәм.



Ак әби - авыл бизәге

# «Свой поганый»

## Жизнь и приключения тюрка на Руси в XII веке



Черные клобуки

***Примерно со второй половины XI века в обороне южных рубежей Руси от набегов степняков участвовали воины различных тюркских племен, кочевавших в приграничье под Переяславлем и в долине реки Рось: торки, берендеи, ковуи, турпеи, отдельные роды половцев и печенегов, позднее известные под общим названием «черные клобуки». Летописи называли их «свои поганые», отличая от враждебных половцев, и даже донесли до нас часть биографии наиболее выдающегося среди них воина – хана Кундувдыя.***

*Дмитрий ГРЕКОВ*

### Предводитель мужей

Впервые это имя («Кунтувдей») встречается в летописях под 1183 годом, когда князья Рюрик Ростиславич и Святослав Всеволодович, совместно правившие Киевом, послали преследовать уходящих с полоном половцев молодых князей Владимира Переяславского и Игоря Новгород-Северского. Отряд сопровождала конница «черных клобуков» во главе с Кундувдыем и Кулдюром.

В это время Кундувдый уже был опытным и заслуженным полководцем. Вероятнее всего, он участвовал во множестве княжеских междоусобиц, которыми были богаты предыдущие годы, а также в отражении бесчисленных половецких набегов. Возможно, и в знаменитом походе на половцев киевского князя Мстислава Изяславича в 1168 году, описанном автором Ипатьевской летописи.

В следующем походе, в июле того же 1183 года, Кундувдый, скорее всего, тоже участвовал, хотя имя его и не упоминалось. Тогда отряд «черных клобуков» численностью в 2 100 копий был придан авангарду русского войска. Сам же Кундувдый, вероятно, находился при «штабе главнокомандующего», то есть с великими князьями. Его подчиненные окружали войско Кобяка, с которым схватились дружины молодых князей авангарда, но вся слава победителя досталась переяславскому князю Владимиру Глебовичу, внуку Юрия Долгорукого.

> В новом эпизоде Кундувдый предстает перед нами уже как предводитель всех «черных клобуков». Весной 1185 года хан Кончак, готовясь внезапно напасть на Переяславское княжество, подкрался к границе.

Киевские соправители решили нанести упреждающий удар. На остановившуюся в верховьях Хорола орду Святослав и Рюрик посылают двух молодых князей, а сами выступают следом. Воины авангарда, напав на стан и увлекшись грабежом кибиток, упустили главную добычу – самого Кончака, в погоню за которым соправители отправили 6 000 всадников во главе с Кундувдыем (очень большое войско по тем временам). Кончак сам по себе стоил больше любого войска – его поимка означала окончание войны, а неудача сулила неминуемые новые беды.

### «Не стерпя сорома своего»

Кончаку повезло – пока победители грабили лагерь, он выиграл время и бежал, так что организованное с опозданием преследование результатов не дало, кони торков и берендеев стали по брюхо проваливаться в отсыревший мартовский снег.

Летописи не упоминают Кундувдыя среди участников трагических событий лета 1185 года, когда Кончак снова пришел на Русь, но нет сомнения, что он выполнял свой долг, оберегая Днепровское



Женские украшения

правобережье у Заруба или Канева, возможно, ходил на выручку Переяславля, а позже участвовал в безрезультатных походах конца 1180-х годов. Впрочем, Кундувдый, видимо, уже был стар для быстрых набегов – в зимнем походе 1188 года «черными клобуками» руководил некто Роман Нездилович.

В 1190 году русские и половцы сделали перерыв в постоянных войнах и заключили мир. Теперь можно было и отдохнуть – в нейтральной полосе, между устьями рек Рось и Тясмин, Святослав и Рюрик устроили княжескую охоту, «наловив множество дичи», на которой их сопровождал и Кундувдый. Но для него развлечение сие закончилась плачевно – по какой-то непонятной причине Святослав Всеволодович приказал воеводу схватить и «заточил в поруб», то есть в темницу. От долгого заключения узника спас Рюрик Ростиславич, «ибо муж дерз и надобен в Руси», и по его ходатайству Кундувдый был освобожден.



Но, выпущенный на волю, он, «не стерпя сорома своего», ушел к половецкому хану Тоглыю. Горя желанием отомстить своими обидчиками, Кундувдый подговорил его напасть на поселения по реке Рось.

Первым объектом мести стал городок торков Чюрнаев, представлявший собой, судя по упоминаниям в летописи, подобие некоего замка. Видимо, здесь жил кто-то из личных врагов старого хана. Разорив укрепленную усадьбу, «наворопщики» собирались идти жечь другие городки и замки, но, узнав, что княживший в Торческе Ростислав Рюрикович находится поблизости, поспешили уйти восвояси. После этого всю осень, пока не легли глубокие снега, Кундувдый со своим новым союзником Тоглыем продолжали грабить пограничье.

## Возвращение блудного пограничника

Наконец старейшины «черных клобуков» упросили Ростислава Рюриковича предпринять ответный набег (формально всё еще действовали условия мирного договора, и участие русского князя в таком походе могло перечеркнуть результаты уговора с половцами) – и война вспыхнула снова.

Половцы в долгу не остались. Набег следовал за набегом, и степняков опять вел за собой Кундувдый. Ему, как никому другому, были ведомы все слабые места в системе охраны границы, тайные тропы и броды, проходы в заграждениях, расположение застав и засад – Святослав, несомненно, много раз пожалел о своем поступке.

Старому князю пришлось дважды, самому и с сыновьями, прикрывать границу в принадлежавшем Рюрику Поросье, пока его легкомысленный соправитель пировал в Овруче, женя своего еще более легкомысленного сына, не только нарушившего договор, но и уехавшего по возвращении из похода на свадьбу.

Однако всему на свете приходит конец. Ослепленный местью Кундувдый завлек своих новых друзей в ловушку.

В очередной раз отогнав половцев, Святослав изобразил ложное отступление. Он направился в Киев, но у Канева оставил засаду, в которую попались половцы. Как ни хитер был старый хан, но прорваться незамеченными на этот раз не удалось. Княжич Глеб Святославич, оставленный отцом стеречь границу, узнав, что враги перешли Рось, попытался отрезать им пути отхода. Половцы в панике выскочили на лед и «обломились». Много их утонуло здесь, сдалось в плен или было убито, только Кундувдый снова ушел.

После этого война продолжалась еще год, пока не затухла сама собой – половцы устали. Лишь тогда Рюрик, не забыв старые заслуги своего вассала, все-таки зазвал Кундувдыя к себе в Киев, обласкал старика и подарил ему во владение городок Дверен на Роси – «Русской земли деля!» Более летописи не упоминают о предводителе «черных клобуков», скорее всего скончавшемся незадолго после того от старости или болезни.

# Последний «железный канцлер»

## История и кинематограф



*Окончание. Начало в № 41*

***Продолжаем рассказ об истории Золотой Орды и ее «теневого правителя» Идигу (см. предыдущий номер)… Итак, зимой 1411–1412 годов Идигу укрылся в Ургенче, столице Хорезма, правителем которого незадолго (и весьма предусмотрительно!) до того сделал своего сына Мабарак-шаха. Тимур-хан послал в погоню за ним своего беклярбека Текне и амира Газана. Они разбили войска мангытов в битве и осадили город.***

*Дмитрий ГРЕКОВ*

### Новый взлет

Осада затянулась примерно на полгода – и за это время многое изменилось. На Новый Сарай напал очередной претендент – Джелал ад-Дин, сын Тохтамыша, который изгнал Тимур-хана. Бывший султан прискакал к своим войскам в Хорезме и собирался поднять их на «реконкисту». Но не учел того, что жена амира Газана была дочерью Тохтамыша и, следовательно, сестрой Джелал ад-Дина – и зять предпочел ради интересов шурина зарезать «совершенно постороннего ему человека».

Поначалу казалось, что воцарение нового хана, получившего в русских летописях забавное имя Зелени-Салтан Тохтамышевич, ничем не повлияло на печальное положение Идигу, даже напротив – амир Газан, назначенный беклярбеком, потребовал от темника выдать другого его сына, Султан-Махмуда, который был племянником Джелал ад-Дина (сыном от Джаныке-ханум, другой дочери Тохтамыша). Не совсем понятно, что хан и его амир хотели – то ли приблизить к себе племянника



Зелени-Салтан

(но зачем тогда гнобить его отца?), то ли казнить (опять же зачем – в Орде родство по женской линии при престолонаследии в счет не шло). Идигу притворно согласился, и Газан увел войска от Ургенча, однако Султан-Махмуд так никуда от отца не уехал.

> Разозленный «Зелени-Салтан» послал на Хорезм другого амира, Каджулай-бахадура, но с ним Идигу расправился, устроив засаду, разгромив и убив. В это же самое время (1413 год) сам Джелал ад-Дин был разбит и убит своим же братом Керим-Берды, который оккупировал Новый Сарай и стал очередным султаном Улуса.

Поскольку Керим-Берды был «московской марионеткой», против него выступил Витовт, поддержавший другого Тохтамышевича – Кебека (или Кепека), который в 1414 году разбил брата и захватил Новый Сарай. В этот момент отсиживавшийся в Хорезме Идигу

решил, что пора вмешаться – он отбил столицу, вернулся в беклярбеки и посадил на трон своего протеже, хана Тюменского юрта Чокре (Чекре, Чекри, Чогре, Чакра, Джегре), дальнего потомка Джучи, скитавшегося по дворам разнообразных Тимуридов. Вместе им еще несколько лет пришлось воевать с Кебеком, укрывавшимся в Литве, и с Керим-Берды. В 1416 году войска Идигу в ходе этой борьбы сожгли Киев.

## Конец повелителя степи

В 1416 году Кебека убил его младший брат (Тохтамыш мало того, что сам был живучий, так еще и сыновей нарожал немерено) Джаббар-Берды, который всё с той же литвинской поддержкой разбил и убил Чокре, захватив Новый Сарай. Один из сыновей Идигу, Нур ад-Дин, стал у него беклярбеком и пошел против родного отца. В отместку мангыт выдвинул нового кандидата в султаны Саид-Ахмада, но тот тоже погиб в сражении с Джаббар-Берды. В конце концов Идигу всё же победил в 1417 году – его противник бежал в Крым, где был убит уже сам. Пришлось отыскивать нового хана – им стал Дервиш, тоже Джучид (то ли Шибанид, то ли Тука-Тимурид).

Многолетняя «лавочка Идигу» закрылась в 1419 году – очередной сын Тохтамыша (и не было им конца...) Кадыр-Берды опять привел литвинов и убил Дервиш-хана. Беклярбек бежал в Крым, где попытался сделать новым султаном некоего Бек-Суфи, и даже попытался договориться с Витовтом. Но Кадыр-Берды побил их воинство, убил хана-марионетку и заставил Идигу скрываться на Яик-реке.

Собственные сыновья ворчали на него – отцу было уже примерно 67 лет, и он всё никак не умирал, продолжая цепляться за власть. И даже нашел очередного «парадного хана» – Хаджи-Мухаммада.

Но фортуна окончательно повернулась задом – «кадырбердыйцы» в одной из стычек то ли смертельно ранили последнего великого беклярбека Улуса, то ли вообще на куски изрубили... Кстати, едва ли не в тот же самый день в Крыму погиб в бою и сам Кадыр-Берды. А ставленник мангыта Хаджи-Мухаммад ушел в Среднюю Азию, где основал независимое Узбекское ханство, став его первым правителем.



Ногаецъ | Nogai (Tartare)

## Всё, что останется после

Потомки Идигу и племя мангыт образовали свою собственную Ногайскую Орду (Ногайский, или Мангытский юрт) – государственное образование, существовавшее с XV по XVII век в низовьях Волги и на Урале (реке, тогда еще называвшейся Яик), и управлявшееся биями – потомками беклярбека. Собственно, Идигу и считался первым ногайским бием, его старший сын Нур ад-Дин – вторым, а третьим – другой сын, Мансур. Столицей нового государства стал город Сарайчик (Малый Сарай – Малый Дворец) на Яике.

Ногаи пытались сперва вести агрессивную внешнюю политику – ходили походами на Казань (вместе с сибирскими татарами) и Крым, но в 1557 году из-за того, что бий Исмаил признал вассальную зависимость от Московского царства, разделились на Большую и Малую ногайские орды – первая кочевала между Волгой и Яиком, вторая – между Волгой и Азовским морем. Чуть ранее образовалась Алтыульская орда в междуречье Яика, Эмбы и Сырдарьи.

В 1580 году Сарайчик разграбили и сожгли «воровские» (то есть, не контролируемые правительством из Москвы) волжские казаки атаманов Нечая и Богдана Барбоши (того самого, чье имя в Самаре носит Барбошина поляна).

Город так и не возродился – нынешнее село Сарайчиковское в Казахстане было образовано на месте русской крепости, построенной в 2 км выше по течению Яика. После этого среди ногаев начались междоусобицы, подрывавшие Большую Орду. Последний удар в 1628–1630 году нанесли пришедшие с востока калмыки, разгромившие Мангытский юрт. Уцелевшие ногаи бежали к казахам и каракалпакам, растворившись среди них, или в Малую Орду, давно уже подчинявшуюся Крымскому ханству. Ныне ногаи (или ногайцы) – один из народов, живущих на Северном Кавказе.

***Наверное, никто из ученых и деятелей культуры не мог так сильно воздействовать на общественную жизнь города Казани, как Карл Фукс. Люди по праву называли его «светочем Поволжья». Он пользовался огромной любовью и уважением у населения, особенно среди татар.***

***Фарид Шириязданов***

# Быть благородным человеком – значит уметь любить и уважать других, как самого себя

Карл Фукс щедро дарил людям тепло и свет своей души. Он был благородным, интеллигентным человеком и образцом доброты и порядочности. Он искренне полюбил татар. Постепенно выучил татарский язык, изучил образ жизни, обычаи, историю народа. В итоге появились его уникальные труды о татарах, где он писал: «Даже после завоевания Казани татары в течение трех сотен лет бережно хранят национальные традиции и те ценные качества, какими отличались их предки. Они гордятся своим происхождением, своими моральными качествами, своей религией, культурой быта и всем тем, в чем заключаются национальные черты их характера». Отмечая его веселый нрав, остроумие и добродушие, А. И. Герцен писал: «Да как же можно было ему не любить их?! Ведь целое поколение татар родилось, выросло, заболевало и выздоровело при нем, благодаря его доброй души и целебных рук врача».

При упоминании имени Карла Фукса поражает то, каким же образом он проникся с таким огромным уважением татарскому народу. Так кем же он был и откуда родом?

Карл Фукс родился в Германии 6 сентября 1776 г. в городе Герборне в семье профессора богословия и ректора Герборнской академии. С юности он питал особый интерес к истории древних народов, к их



языкам, культуре и литературе. Он получил достойное образование в Маргбургском университете. В 1798 г. ему была присвоена степень доктора медицины и хирургии. К. Фукс, помимо родного языка, владел рядом европейских языков (английским, французским, итальянским). Оказавшись в России, он усвоил русский язык. Когда преподавал в Казанском университете, интересные лекции молодого профессора сразу же покорили студентов, которых он обучал. В «Казанском литературном сборнике» за 1878 год о нем тогда писали: «Карл Фукс – особенно любимый и увлекавший студентов профессор, который на собственном примере показал, какой чарующей силой должен обладать ученый». Он был врачом-подвижником. С раннего утра его приемная наполнялась больными, иногда приезжавшими издалека. Он не делал различия между пациентами, будь то дворянин или мужик – всех встречал приветливо и обращаясь только на «вы». С первых лет жизни в Казани Карл Фукс интересовался историей, жизнью и бытом татар. Бывая в разных домах жителей, он присутствовал и при различных обрядах. К. Фукс коллекционировал восточные монеты, археологические древности и другие памятники старины, касающиеся жизни и деятельности татар. О нем писали: «К. Фукс был одним из первых, кто смог проложить «тропинку» в духовный мир татарского народа». В таких трудах, как «Краткая история города Казани» и «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношении», содержатся не только история древнего города Казани, но и эти труды стали первой специально написанной политической историей Казанского ханства.

Опираясь на доступные источники на татарском и русском языках, он сумел составить хронологию казанских царствований. При этом он написал книгу «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях». Уникальность этой книги состоит в том, что все материалы, собранные из различных источников, сочетаются с его личным опытом и уважительным отношением к обрядам и особенностям традиций быта татарского народа. Интересна его история первого знакомства с городом Казанью. Однажды он в составе дипломатической миссии собрался из Лондона поехать в Китай. По пути на несколько дней пришлось остановиться в Казани. Здесь он присутствовал в церемонии торжественного открытия университета. Этот случай заставил его отказаться от поездки в Китай и задержаться здесь на целых сорок лет! В результате общения с татарами, здесь он увлекся изучением восточной культуры. Стал коллекцио-

нировать древние монеты и изучил арабский язык. При этом дом Карла Фукса превратился в некий культурный центр. Здесь проводились музыкальные вечера и диспуты, посвященные теме общественного развития татарского народа проблемам в области системы его просвещения. Там были слышны и высказывания, обращенные против самодержавия, говорящие о бедственном положении татарского народа, проживающего в нужде и невежестве, и об истинных причинах, приведших его к такому положению. В итоге он проникся чувством уважения к древнему татарскому народу, восхищаясь его культурой, традициями, самобытностью и его стойкостью в борьбе за сохранение своего национального достояния, даже будучи в условиях колониального гнета.

Карл Фукс, восхищаясь, изучал жизненный уклад, быт казанских татар, их нравы и обычаи, строение лица, форму одежды, питание и национальную кухню. При этом он даже критиковал то, что иные татары, подражая русским, начали пить вино. Карл Фукс был восхищен гостеприимством казанских татар и их жизнелюбием. При этом он писал: «Татары горды принадлежностью к своей нации. Они честолюбивы, гостеприимны, сердобольны и чистоплотны. Несмотря на униженное положение они довольно просвещенны, рождены для торговли, между собой дружелюбны, во всем умеренны и очень трудолюбивы».

Уважительно отзываясь о выражении лиц и строении тел казанских татар, он видел в них породистые черты великого народа: «Взор их проницателен. Плечи широкие, грудь высокая. Они довольно хорошо сложены, стан их прямой и походка уверенная и важная. Тело светлое и без волос. Такое можно сказать о людях, хорошо знающих себе цену. Иными словами, татары, несмотря ни на что, никогда не забывали о своем происхождении, и это отражалось даже в их твердой поступи и в их походке!» О женщинах он писал: «Восточные законы искусно наложили на них печать кротости. Татары живут очень опрятно. В их избах очень чисто: они имеют привычку несколько раз в году белить печь и всегда поддерживать чистоту и опрятность во всем и везде». Чем больше узнаешь о Карле Фуксе, тем больше возникает чувства уважения к нему. Он смог отчетливо увидеть, насколько пагубно влияет национальная политика государства, направленная на поголовную русификацию и христианизацию подвластных нерусских народов. Он часто говорил и писал об этом. Прогрессивная часть татарского общества, ученые, врачи, работники культуры – все, кто ратовал за сохранение генофонда народа, прониклись к нему искренним уважением и с удовольствием общались с ним. Карл Фукс посещал мечети, медресе, участвовал в проведении национальных праздников и торжественных церемоний. Будучи уникальной личностью, он с первого взгляда мог определить болезнь человека. В процессе преподавательской деятельности он руководствовался принципом: «Нельзя быть хорошим специалистом, особенно врачом, без основательного общего образования!» Поэтому и многие его воспитанники также стали знаменитыми людьми, как например, Н. И. Лобачевский, И. М. Симонов, В. И. Панаев, С. Т. Аксаков и другие.

С 1812 года Фукс открыл также врачебную практику. Зная, что простолюдины относятся с предубеждением к аптечным медикаментам, он лечил их по возможности домашними средствами и имел для этого у себя большой запас лекарственных трав. При этом он был членом Симбирской ложи «Ключи к добродетели».

Когда в 1816 году в Казани открылся местный комитет Императорского человеколюбивого общества, Карл Фукс был избран в его члены-попечители. Он обязался вносить в кассу ежегодно по 50 рублей и бесплатно лечить всех бедных, состоящих в ведении попечительства. Карл Фукс принадлежал к числу редких в ту пору бескорыстных врачей. Он не жалел для бедняков своего времени и ту плату, которую он часто неохотно брал с людей зажиточных, раздавал людям неимущим. Выражением высшего доверия ему была его медицинская печать с надписью на татарском: «Табиб Фукс» («Врач Фукс»). Результаты своих наблюдений в области самобытности казанских татар Фукс изложил в двух монографиях: «Краткая история города Казани» и «Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях». Благодаря разносторонней и просветительской деятельности семья Фукс вскоре становится интеллектуальным центром Казани. Их дом посещали также и заезжие ученые и литераторы, в числе которых был и А. С. Пушкин. За свои труды на профессиональном поприще и «действия по человеколюбию» Карл Фукс был награжден Александром I орденом Святого Владимира IV степени, а в 1824 году – орденом Святой Анны II степени, а Николаем I – алмазными украшениями на орден Святой Анны. Смерть Карла Фукса 24 (12) апреля 1846 года прервала его обширную деятельность. Весть о ней быстро разнеслась по городу. В последний путь его провожала огромная масса людей. Особое внимание привлекали большие толпы татар. При погребении присутствовали не только губернатор и все начальство университета, студенты и учащиеся, но и огромное количество жителей Казани. В 1996 году в Казани отмечали 220 лет со дня рождения Карла Фукса. Его имя было присвоено бывшей улице Городецкого, а также скверу («Фуксовскому садику») на берегу Казанки. В честь него установили памятник в городе Казани.

Тут поневоле в голову приходит мысль: а много ли сейчас среди татар найдется людей, столь нежно и искренне любящих свой народ? Знающих и уважающих историю своего народа, его культуру, традиции, ратующих за сохранение родного языка и повышение уровня национального самосознания, которыми искренне восхищался Карл Фукс?

# Открытие Аркаима – это чудо, которое переворачивает все знания и научные утверждения, основанные на философии Запада

***Чем глубже вникаешь в историю древних тюрков – тем сказочней и загадочней кажется она. Особенно поражают артефакты и археологические находки, хранящие тайны, многие из которых не поддаются разгадке до сих пор.***

***Фарид Шириязданов***

Есть и немало сооружений, которые ставят в тупик даже современную науку. Это египетские пирамиды, гигантские изваяния острова Пасхи, Стоунхендж, Аркаим и Алтайский Аржан. А какое же отношение к ним имеют наши предки – древние тюрки-булгары? Дело в том, что загадочная история тюркских народов во все времена привлекала внимание ученых всего мира. Более того, на этом пути ими уже сделано много открытий. Например, исследования английского ученого Эдуарда Паркера подтверждают, что тюркский след просматривается во всех уголках мира. Взять хотя бы историю индейцев Америки – представителей загадочной цивилизации майя. Сейчас научно доказана не только схожесть культуры, традиций и языка древних тюрков и индейцев, но и идентичность их генотипа. Известно, что древние тюрки и индейцы владели тайными знаниями о мироздании, о движении планет и об их влиянии на земную природу. К сожалению, на сегодня сохранились лишь осколки их открытий и этих знаний. Например, созданные ими животные и лунные календари, которые популярны и сегодня. Более того, все праздники, обряды и поверья древних тюрков были четко ориентированы на знания о движении небесных тел и их влияния на земную природу. Все загадочные явления пока трудно по порядку укладывать в голове. Но когда в 1986 году на границе Башкортостана и Челябинской области археологи обнаружили остатки древнего города-обсерватории Аркаима – это стало сенсацией века и событием мирового уровня. Выяснилось, что Аркаим был многофункциональным историческим объектом: научным центром-обсерваторией, оборонной крепостью и специально оборудованным святилищем (капищем) для проведения ритуальных обрядов. Здесь были созданы все условия для автономного проживания древних людей. Узнав об этом открытии, со всего мира сюда устремились многотысячные толпы ученых, туристов и паломников. Среди них были также экстрасенсы, колдуны и маги, которые говорили об особой энергетике Аркаима. Приезжали сюда также убогие и калеки, желающие получить исцеление. При этом представители многих стран, ученые были уверены и упорно доказывали факты о причастности их народа к славной истории ариев и с гордостью, громко заявляли об этом, особенно немцы и итальянцы. А на самом деле – все они правы. Потому что эти места, как и весь Алтай, считались центром арийской цивилизации. Ведь когда-то отсюда во все уголки мира устремлялись арии, то есть скифы и сарматы, с целью освоения новых территорий, в том числе в Иран и Индию. Как ни странно, западные ученые цивилизацию тюрков-ариев стали называть индо-иранской. Время доказало, насколько мощной была энергетика ариев, которая продолжает взбудораживать умы современных людей, даже пройдя сквозь тысячелетия. К сожалению, сейчас сложилось мнение, что арии были неким сказочным народом, слава о которых прогремела в веках и они растворились среди других народов. Затем совсем сошли со сцены истории.





Но время всё расставляет на свои места. Сейчас уже более ясным становится то, что скифы, сарматы, гунны и татары-булгары – все имеют тюркские корни и говорили они на тюркском языке. Однако после открытия феномена Аркаима ученые особо не акцентировали внимание на том, что 4,5 тысячи лет назад здесь жили предки современных тюркских народов. Что касается ариев, слово «ар» – на тюркском языке означало – «сын неба». А «голубое небо» тюрки воспринимали не как понятие астрономическое, а как обиталище бога Тенгре. А древних тюрков тогда называли «небесными тюрками», «сынами неба» или «детьми тенгри». Эти понятия лежали в основе веры в Тенгри и идеологии тюрков. В названиях разных ветвей татарского народа часто встречаются слова, содержащие загадочную приставку «ар». Например: татар, мишар, билар, сувар, хазар, маджар, булгар, балкар. Еще одну ветвь тюркских народов называли «асы». Например, буртасы, хакасы, осетины и другие. Аркаим – был городом-крепостью, крупным научным центром и суперобсерваторией. Из числа приборов и оборудования, которыми тогда пользовались они, до наших дней сохранился лишь инструмент, который называли «астролябией». Что характерно, с ее помощью аркаимцы изучали движение небесных тел не вертикально, не направляя ее в зенит, а горизонтально, в определенные моменты нахождения небесных тел ближе к земле, а также во время восхода и захода солнца. Аркаим одновременно был крепостью, храмом, ремесленным центром и жилым комплексом. Он схож со Стоунхеджем, который был мегалитическим сооружением на Солсберийской равнине в Англии, где также располагалась древнейшая обсерватория. Но Аркаим оказался сложней Стоунхеджа и древней его на целых тысячу лет. Возраст Аркаима – 4800 лет. Крупное сооружение Аркаима было цельной конструкцией. Общая площадь его составляет 20 000 кв. метров. План поселения напоминал два кольца оборонительных стен, вписанных друг в друга. Две кольцевые улицы жилищ были пристроены к этим стенам. В центре колец – ровная площадка в форме круга, диаметром 25–27 метров. Строение это было возведено из бревенчатых клетей, забитых грунтом с добавлением извести. Кольца жилищ были разделены на сектора радиальными стенами. В плане они выглядели как спицы колеса. Их стены были общими в отношении расположенных рядом жилых помещений. Планировка внутренних жилищ и кольцевых улиц Аркаима были сложной архитектурной конструкцией. По этим сведениям можно судить, как упорядоченно протекала жизнь большого сообщества людей и как разумно она была организована. Тут заметно, что даже сама геометрия построек таит в себе серьезные загадки. Например, почему же все это устроено в виде круга? Какова символика этих строений? Вот что говорит об этом первый исследователь Аркаима Г. Б. Зданович: «Такая планировка близка принципу Мандалы – одного из сакральных символов буддийской философии. Само слово «Мандала» переводится как «круг», «диск». Поскольку Вселенная моделируется и изображается в виде круга, квадрата и их сочетания, то жилища Аркаима, где стена одного дома является стеной другого, вероятно, отражают «круг времени», то есть символ вечности».

В «Стране городов», как назвали Аркаимскую цивилизацию, поражает не материальное богатство, а удивительная духовность. Это особый мир, где духовностью было насыщено всё – от поселенческой и погребальной архитектуры до скульптур из камня. Несмотря на то, что Аркаим и Стоунхендж разделяет расстояние в 4000 километров и тысячелетний отрезок времени, синхронность этих двух исторических памятников очевидна. Конструкция сооружений обоих имеют единую основу. При изучении Аркаимского феномена выясняется и то, что не в «дикую Сибирь» пришла цивилизация из Греции, а вот как раз наоборот. Так что открытие Аркаима перевернуло все знания и утверждения, основанные на философии Запада. Аркаим строго ориентирован по сторонам света. По точности ориентации во всем древнем мире с ним могут конкурировать лишь египетские пирамиды, но они моложе его лет на 200. Интересным фактом является и то, что Стоунхендж, Аркаим и Аржан находятся на одной географической широте и они имеют загадочные конструкции, которые до сих пор хранят много тайн. Но еще большие тайны содержат дольмены, кажущиеся совсем простыми и напоминающие обыкновенные скворечники. А ведь их называют входными воротами в другие миры и другие временные измерения! Открытие Аркаима – это прорыв через толщу веков в неведомый нам и сложно устроенный мир прошлого. Он просто завораживает и восхищает нас. Ведь мы стали свидетелями чуда, которое произошло не где-нибудь на конце света, не среди пустынь Ближнего Востока, а тут, на границе Башкортостана и Челябинской области! Здесь открылась «Страна городов» – остаток одной из древнейших цивилизаций человечества, о котором упоминаются и в древних описаниях истории Волжской Булгарии, как «Гардарика». Теперь уже стало точно известно то, что именно здесь была прародина ариев, которую так долго искали ученые. Над раскрытием тайн Аркаима сейчас работают многие русские и иностранные ученые. Правда, и башкиры проявляют определенную активность в этом направлении. Хочется узнать: интересуются ли этой темой татарские исследователи? Ведь это напрямую касается нашей древней истории.

***«Ләйсән» сүзе борынгы фарсы теленнән «апрель», дип тәрҗемә ителә. Димәк, безгә ничәмә еллар дәвамында дәртле биюләр, яхшы кәеф, биюче кызларның язгы кояштай балкып торган елмаюларын бүләк иткән ансамбльнең нәкъ шушы айда барлыкка килүе очраклы түгел.***

***«Ләйсән» башкорт бию ансамбле 2004 елның апрелендә Самар шәһәренең башкортлар корылтае (конгрессы) иҗтимагый оешмасы каршында Рәүдә Данияловна Шаймәрданова тырышлыгы белән оештырыла һәм бүгенге көнгә кадәр үзенең алыштыргысыз җитәкчесе канаты астында яшәп килә.***

***Эльмира Сәйфуллина***

# «Ләйсән» башкорт бию ансамбленә – 20 яшь!



«Ләйсән» ансамбле башкорт милли бәйрәмнәрендә, милләтара фестивальләрдә, милли традицияләрне саклауга, Самар өлкәсендә яшәүче халыклар арасында дуслыкны ныгытуга юнәлдерелгән конфессияара чараларда актив катнаша. Ел саен үткәрелә торган «Карга туй», «Йыйын», «Талантлар Салават күпере» өлкә башкорт бәйрәмнәрендә катнашу ансамбль өчен матур гадәткә әверелде. Моннан тыш, коллектив ел саен Россия Федерациясенең Җиңү көне (9 май), Россия көне (12 июнь), Дәүләт флагы көне (22 август), Халыклар бердәмлеге көне (4 ноябрь) кебек истәлекле даталарына һәм дәүләт бәйрәмнәренә багышланган чараларда чыгыш ясый.




«Ләйсән» ансамбле җитәкчесе Рәүдә Даниял кызы Шаймәрданова.

Актив ансамбльнең тынгы белмәс җитәкчесе Рәүдә ханым 2007 елның маенда Халыклар дуслыгы йорты оештырган «Үзешчән сәнгать коллективының иң яхшы җитәкчесе» конкурсында беренче урынны яулый. 2008 елның июнендә «Ләйсән» коллективы Башкортостанда узган V төбәкара яшьләр Сабан туенда халык биюләре конкурсында икенче урынны яулый. Ә 2009 елдан башлап,



Шәймәрдановлар гаиләсе «Күпмилләтле Самар» фестивалендә

ансамбль «Халык үзешчән коллективы» («Народный самодеятельный коллектив») дигән мактаулы исем йөртә. 20 ел эшләп килгән дәвердә «Ләйсән», төрле масштабтагы бәйге-фестивальләрдә катнашып, күпсанлы җиңүләргә һәм мактаулы исемнәргә лаек булды. Самар өлкәсе губернаторы Администрациясенең, Самар Губерна Думасының, «Бөтендөнья башкортлар корылтае» халыкара иҗтимагый берләшмәсенең, Башкортостан Республикасы Мәдәният һәм милли сәясәт министрлыгының, Самар өлкәсе Мәдәният министрлыгының, Самар шәһәре мәгариф департаментының, Халыклар дуслыгы йортының күп кенә дипломнары һәм Рәхмәт хатлары белән бүләкләнде. Аларның барысын да санап узарга, кызганыч, мөмкинлек юк. Ике дистә еллык актив иҗади эшчәнлеге дәвамында «Ләйсән» башкорт ансамбле Самар губернасында гына түгел, ә аннан читтә дә зур мәхәббәт һәм танылу яулады. Ансамбльнең күп кенә катнашучылары үзләренең иҗади юлларын Башкортостан Республикасында дәвам иттеләр.

«Ләйсән» башкорт бию ансамбле Самар җирендә башкорт милли мәдәниятен популярлаштыруга зур өлеш кертә. Ансамбль җитәкчесе Рәүдә Данияловна Халыклар дуслыгы йортында җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча белгеч булып эшли. Ул өлкәнең башкорт халкы арасында да, башка милли-мәдәни берләшмәләр һәм коллективлар җитәкчеләре арасында да зур абруйга ия. Аның белән таныш булган һәркем Рәүдә апаны белемле һәм инициативалы белгеч, тәҗрибәле һәм ышанычлы хезмәткәр, ярдәмчел кеше буларак тасвирлыйлар.

Күп еллар дәвамында Рәүдә Данияловна зур иҗтимагый эш алып бара, балаларга башкорт биюләрен өйрәтүгә күп көч һәм энергиясен бирә, аларда башкорт мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияли. Аралашучан, шат күңелле, ул тирә-юньдәгеләргә үзенең оптимизмын һәм иҗади омтылышын йоктыра. Профессиональ җитәкче буларак, аны нечкә зәвыгы һәм югары сәнгать культурасы аерып тора. Эш сөючәнлек, тырышлык, үҗәтлек, үзешчән сәнгатькә тугрылык, оештыру таланты – Рәүдә Данияловнаның төп сыйфатлары.

Рәүдә ханым Шәймәрданова Самар өлкәсенең Большечерниговский районы Кочкиновка авылында гади гаиләдә туып-үскән. Мәктәптә көннең беренче яртысында ул - рус телендә, ә өйгә кайткач, башкорт телендә сөйләшә торган булган. Өченче сыйныфка кадәр ул авыл мәктәбендә укыган, аннан соң аларны район мәктәбенә автобуста йөрткәннәр.

***- Бию белән кайчан шөгыльләнә башладыгыз?***

– Мин балачактан ук биергә ярата идем. Әле хәзер дә бер күренешне бик ачык хәтерлим: миңа 4 яшь иде, безнең өйдә туй булды һәм мине биергә чакырдылар. Бик кечкенә булсам да, кунаклар алдына чыгып биергә курыкмадым, минем чыгышымны алкышларга күмделәр. Мин үзем бик оялчан булсам да, халык алдында биергә беркайчан да курыкмадым.

Безнең күршедә гармунчы абый яши иде. Ул еш кына безгә керә дә сыздырып гармунында уйнап җибәрә иде. Ә мин шунда ук бии башлыйм. Ул һәрвакыт төрле – кайвакыт тиз, дәртле, кайвакыт талгын көйләр уйный иде. Һәм мин һәрбер көйгә туры китереп бии идем, – дип искә ала әңгәмәдәшем.

Рәүдә мәктәптә укыганда да биюгә тартыла. «Бию түгәрәкләренә чакыру турында белдерүләр күрсәм, йөрәгем ашкынып куя иде, әмма мәктәп автобусы укучыларны дәресләр тәмамлануга ук алып киткәнгә, кичен генә узган түгәрәкләргә йөри алмадым», – дип сөйли ул. Шуңа күрә мәкаләм ге-



«Байык» конкурсында җиңүчеләр, Башкортостан Республикасы

рое үзешчән сәнгать коллективы булган җирле Мәдәният йортында шөгыльләнә башлый. Сәхнәгә биюләрне ул һәрвакыт үзе куя. Иң яратканнары Һиндстан биюләре була. Шулай итеп, мәктәптә узган бер генә чара һәм концерт та Рәүдә катнашыннан башка узмый. Нинди генә бәйгедә катнашса да ул призлы урыннар яулап килә. Ә чыгышлар өчен костюмнарны аңа апасы теккән.

Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Рәүдә ханым Куйбышев шәһәре мәдәният мәгариф училищесының хореография бүлеген, аннары педагогика институтын тәмамлый. Ул вакытта инде безнең шәһәрдә "Ялкынлы яшьлек" татар ансамбле гөрләгән. Биюче кыз шул коллективка эләгергә озак хыяллана һәм максатына ирешә.

– Бу ансамбль составында мин зур сәхнәнең "тәмен" татыдым, биюгә чын-чынлап гашыйк икәнемә тагын бер кат инандым һәм гомерем буе бу шөгылемнән аерылмавымны аңладым. "Ялкынлы яшьлек" белән мин Казан сәхнәләрендә чыгыш ясау бәхетенә ирештем, рәхмәтле тамашчыларның көчле алкышларына күмелү рәхәтен тойдым. Мин Рәшит Әнвәрович Гыйззәтуллин һәм Альберт Закирович Гаязов кебек талантлы хореографлар кул астында эшләдем, Ринат Вәлиев, Әминә Мусина, Рузалия Әхмәдуллина, Гүзәл Хәйруллова, Наилә һәм Тәнзилә Әхмәтовалар, Мидхәт Әминов, Рәсим Таишев, Хәким Камалетдинов, Рамил Зөбәеров белән парлап биедем.

2002 елда Самар шәһәрендә «Башкортлар корылтае» иҗтимагый оешмасы барлыкка килде. Халыклар дуслыгы йортына мине корылтай методисты Гөлсара Хәбиб кызы Садовник чакырды. Миңа шунда ук башкорт коллективын оештырырга тәкъдим иттеләр һәм ярты ставкалы бию коллективы җитәкчесе вазифасын бирделәр. Әлбәттә, мин бераз каушап калдым һәм балачактан җыр-моңга гашыйк булган, бик матур итеп җырлаучы, мәдәният, сәхнә тормышын әйбәт белүче тормыш иптәшем белән киңәшләшергә булдым. Ирем эшне башлап карарга киңәш итте. Минем зур, танылган коллектив булдыру максатым юк иде, мине бу эшкә биюгә булган мәхәббәтем этәрде, һәм ул үз ролен уйнады да.

Беренче төркем башкорт авылларыннан килгән балалардан җыелды, алар бию элементлары белән бөтенләй таныш түгелләр иде. Беренче чыгышларыбыз иң гади биюләрдән башланды. Шул вакыттан бирле коллектив әкренләп үсте һәм менә инде 20 ел дәвамында яши. Мин мондый ансамбль оештыра алырмын, һәм ул «Халык коллективы» исеменә лаек булыр, дип хыялланмаган да идем. Репертуарыбызда нигездә башкорт би-



юләре, әмма кайвакыт татар биюләрен дә башкарабыз. Һичшиксез, авырлыклар да булды, әмма барысы да хәл ителде, без алга атладык. Бернинди кыенлыкларга һәм киртәләргә дә карамастан, «Ләйсән» ансамбле яши һәм остара!

***– Төркемнәргә ничә яшьтән кабул итәсез?***

– Элек мин өч төркем алып бардым һәм биш яшеннән җыя идем, әмма хәзер кече төркемгә җиде яшьтән җыям. Өлкәннәр төркемендә югары сыйныф укучылары, студентлар һәм эшләүчеләр дә бар.

***– Ансамбльдә нинди атмосфера хөкем сөрә?***

- Олы төркем белән мин үземне кырысрак тотам. Мин алар алдына һәрвакыт бурыч куям һәм барысын да әйбәтләп аңалатам. Чөнки без башкорт мәдәниятен генә түгел, ә Самар өлкәсен дә тәкъдим итәбез. Без лаеклы чыгыш ясарга тиеш, һәм кызлар моны аңлыйлар. Әлбәттә, мин һәр бала белән уртак тел табарга тырышам, чөнки һәркем үзенә бер төрле, үзенчәлекле. Аңлашылмаучанлыклар да, үпкәләүләр дә булгалый, әмма бу инде баланың тәрбиясенә бәйле. Мин гаиләгә кагылмыйм, ләкин коллективның үз кагыйдәләре һәм тәртибе бар. Тәҗрибәмә таянып, каршымда нинди бала басып торганны шунда ук аңлыйм: үпкәләүчәнме яки тыңлаучанмы, эш сөючәнме, ялкаумы. Бөтен җаны-тәне белән биергә теләгән бала аерылып тора ул. Мондый балалар, үзсүзлелек һәм теләк аркасында, табигый талантлары булмаса да, үз тырышлыклары белән тумыштан талантлылардан да югарырак күтәрелә алалар.

Кечкенәләр белән мин үземне йомшаграк тотам. Урыны белән иркәлим, тәртип турында да онытмыйм.

***– Ансамбль җитәкчесе нинди булырга тиеш -катгый һәм таләпчәнме яки мәрхәмәтле һәм канатландыручымы? Сез нинди җитәкче?***

– Минемчә, уңышка ирешер өчен дисциплина булу мөһим, ә җитәкче кирәк чакта кырыс булырга тиеш.

Үземә килгәндә, кайвакыт кырыслыгым җитеп бетми кебек.

Олы төркемгә мин кисәтүләрне дә катырак әйтә алам, ә менә бәләкәчләр белән алай булдыра алмыйм. Мин алар белән балаларым белән сөйләшкәндәй аралашам. Шул ук вакытта алга таба үсеш алыр өчен җитәкче катгый һәм таләпчән булырга тиеш икәнне дә аңлыйм.

***– Ансамбль сезнең өчен нәрсә ул - эшме, хоббимы?***

- Минем өчен ул балам кебек. Мин, һичшиксез, бөтен эчке дөньям белән "Ләйсән", дип яшим, – дип елмая Рәүдә Шаймәрданова.


И. Гатауллин чыгышында күрсәткән хәситәләр. Музей фондыннан.

# ХӘСИТӘ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

***Хәситә - хатын-кызларның алтын-көмеш акчалар, ука һәм кыйммәтле ташлар белән бизәлгән, күлмәк өстеннән күкрәккә киеп куела торган бизәнү әйбере, дип язылган "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә.***

***Әлфия Фәрит кызы Ямаева.***
Төбәк тарихын өйрәнүче.
Әлмәт шәһәре.

Ибраһим җизни Туйкинның "Зәй-Каратай авылы тарихы" китабының "Җир" бүлегендә хәситәнең нинди зур хәзинә булуын аңлатучы урыны бар:

– Мин баштагы елларда, биш душның җирен чәчеп бетерә алмыйча, бер дисәтинәне Кәҗәбаш мукшысына 2 сумга сата идем. Мукшының акчасы 2 сумга тулмый гына. Ул ары йөгерә, бире йөгерә, 2 сумга тутырырга 30 тиен тапмый. Күршеләргә закладка самавырын да күтәреп керде – булмады. "Алдагы атнага әзерләп куярмын", - дигәч, кайтып киттем. Уйланып кайтам: "Мукшы ничек тырыша 1 дисәтинә җирне алыр өчен. Тукта әле, үзем чәчим, орлыгы да табылыр", – дим. Сары бияне җиктем дә җирне сукалап-тырмалап куйдым. Чәчү орлыгы юк. Ат җигеп, инәйдән хәситәсен алып, Ялтанга киттем (бу урында шуны искәртәсем килә, аның әнисе Бәдриҗамал Җәләлетдин мулла кызы (1860–1909) бөек мәгърифәтчебез Габдерәхим Утыз Имәнинең оныкчасы була. Ул Габдерәхим хәзрәтнең кызы Бибиҗамал абыстай белән Куакбаш мулласы Гыймадетдин Котлыбай улының оныгы). Бер белеш бай чуашка кердем. Көз көне пот башына биш кадак арттырып түләү шарты белән, бер дисәтинәгә җитәрлек карабодай алып, хәситәне закладка салып, кайтып киттем. Шул орлыкны чәчтем. Ул елны карабодай бик уңды. Ялтандагы чуашка бурычны да түләдем, инәйнең хәситәсен дә алып кайттым.

Бу Утыз Имәнинең данлыклы Туйкиннар белән бәйләнгән тармагы турында мин "Габдерәхим Утыз Имәни нәселе шәҗәрәләре" китабымда яздым. Монда без хәситәнең ни җитте генә әйбер түгел икәнен күрәбез. Йөз ел элек кулланыштан төшеп калган милли киемебезне искә төшерик әле.

2021 елның язында ТНВ каналыннан 21 мартта һәм 17 апрельдә хәситә турында ике тапшыру булды. Аны Башкортостаннан Илдар Гатауллин дигән сәнгать белгече, художник-этнодизайнер алып барды. Рәхмәт, Илдар кардәшебез, афәрин! Мин бик кызыксынып, ул тапшыруны берничә мәртәбә карадым һәм шушы эшкә алындым. Чөнки ул кызыксыну минем балачагымнан килә – Әлмәт авылы мулласы Мортаза кызы Хөббелбанат әбиемнең (1885–1975) хәситәсен 1930 елда, аларны сөргенгә куганда, Бигәш авылының ярлы коммунарлары тартып алганнар. Самар губернасы Бөгелмә өязе Әлмәт волосте Бигәш авылында туган Әбелгата бабам Рәфиков (1870–1940) мәчеттә азанчы булган. Ул - Ризаддиннең әтисе Фәхретдиннең бертуган энесе Җәләлетдиннең оныгы. Әмма 1997 елда архивтан соратып алынган, тартып алынган әйберләр исемлегендә хәситә язылмаган иде. Металл әйберләрен һәм асылташларны



Әбелгата бабам Рәфиков гаиләсе Богырысланда сөргендә. 1936.



Әтием Фәрит җибәргән архив белешмәсендә йорт, 2 келәт, мунча, капка, лапас һәм тегү машинасы бар.

Уралда завод-фабрикалар, тимер юллар төзегәндә кулланганнар, дип тә сөйлиләр. Егерме биш елдан соң, Бигәш авылына кайтып яши башлагач, әбине бер аштан да калдырмадылар, “абыстай” дип олылап, түр башына утыртып сыйладылар. Аштан әби боегып кайта иде: “Бүген үземнең чулпыларымны кешедә күрдем, өстәл ашъяулыклары минеке иде, яки беләзегемне саклап кимәгәннәр, кашлары төшкән”, – дип. Ә хәситәсен беркемдә дә күрмәде. Менә шул серле хәситә минем балачагым хатирәсе белән бәйле.

Аны ничек, нәрсәдән ясарга икән? - дигән сорау туды. Җәй көне Казанга баргач, керәшеннәрнең Емельянов исемендәге үзәгендә Кукмара районының музей экспозициясе бара иде. Шунда мин беренче чын хәситәне күрдем. Ул эрелеваклы көмеш тәңкәләрне биш рәт итеп, куе кызыл бәрхеткә тегеп куеп эшләнгән иде.Ваклары иң өстә. Ә соңгы рәттә иң эреләре арасында Ленин бабай башы төшкән, без элек кулланган бер тәңкәлекләр дә бар. Таныш акчалар! Мин алардан 1985 елларда кеше башын кырдырып алып, озын чәчемне үрергә чулпылар ясаган идем. Рәхмәт Людмила Белоусовага – ул миңа музейдагы хәситәнең өлгесен төшереп алырга рөхсәт бирде. Хәситәнең бизәлгән алгы өлеше яңа туган ай рәвешендә була икән.

Күбрәк белергә теләп, мин үземнең китапханәмнән татар милли киемнәре турындагы китапларымны актарып утырдым. Нурзия Сергееваның 2008 елда басылган китабында хәситә турында сүз бөтенләй бармый. Димәк, аны онытканнармы, әллә чигүле хәситәләр гел булмаганмы? Ә хәзер сатыла торганнарын чигәләр дә бит! Аннан иртәрәк, М. К. Завьялованың 1996 елда басылган ТР Дәүләт музеендагы татар киемнәре китабына күз салыйк. Бик хуш булып 10, 36, 39, 41, 45, 66, 74, 78, 109, 226 һәм 228 битләрдә хәситәнең борынгы рәсемнәрен яки фотосурәтләрен карап утырдым. Кайбер сораулар да туды: аны һәрчак сул җилкәдән кияләрме? Камзул (жилет) өстеннән киеләме? Илле ел элек сатып алынып, инде якын дустыма әйләнгән, күп тапкырлар кулланган “Казан татарларының киемнәре”н актарам. Аның да авторы татар түгел – рәссам Л.Сперанская. Ул бик матур итеп милли киемнәребезне барлаган. Китапның 47,49,55,81,85 һәм 89 битләрен хәситә кигән хатын-кыз рәсемнәре бизи. “Ярты гасыр элек әле хәситәне яхшы белгәннәр”, - дигән фикер туды миндә.

И.Гатауллин үзләре иҗат иткән, бик күп конкурсларда җиңгән башкорт хатын-кызлары киемен күрсәтте. Анда да хәситә (күкрәкчә) һәм баш киеме көмеш тәңкәләрдән ясалган. Ул үзе үк әйтә: “Тәңкәләр белән бизәү күбрәк крестьяннарда киң таралган”, – дип. Баерак хатынкызларның хәситәләре зәркәнчылар тарафыннан асылташлар: фирүзә, топаз, аметист, гранат, аквамарин, тау бәллүре һ.б. куеп, алтынкөмештән ясалган, ука белән чигелеп, чеканка, чылбырлар кулланып эшләнгән булган. Кыз балаларныкы гадирәк: сынган алка сыңарын, брошка, көмеш тәңкәләр, матур төймәләр, каптырмалар куелып ясалган. Җиткән кызлар хәситәсенә һәркем, үз зәвыгына, кесәсенең калынлыгына карап, хәленчә тырышкан. Йортта һәр хатын-кызның үзенең бәйрәм күлмәге белән кияргә





хәситәсе, калфагы, изүе, камзулы, асылмалы колак алкалары, чәч япмалары булган. Чулпыларны чәчләренә кушып үргәннәр.

Хәситәне киюче хатын-кызның яшенә карап бизәгәннәр. Яңа туган ай формасындагы хәситә, сул як җилгәгә куелып, күкрәк турысын каплап, уң якта билдән өстә тәмамланган. Арка ягындагы тоташтыручы өлеше бизәлмәгән. Кайчагында аны тасма да алыштырган. Иң түбәнге өлешенә, уң як күкрәк астына, кечкенә генә кесә тегеп куелган – хәситәне җан сакчысы итеп, анда кечкенә генә Коръән китабы йөрткәннәр. Элек аны көмештән тартма итеп тә ясаганнар. Хәзерге телефоннар өчен дә бик уңайлы әйбер икән – һәрвакыт янында!





Бер турысы аңлашылып җитми миңа! Менә миңа, олыгаеп килүче әби кешегә, нәрсә белән бизәргә соң хәситәмне? Ирем миңа бәйрәмнәрдә алтын бүләк итәргә ярата иде, ә көмешләрен мин үзем сатып алдым. Минем аны хәзинәмдәге алтын, я булмаса, көмеш зәркан әйберләре белән бизәргә мөмкинчелегем бар. Әмма бу алтыннарымны (алка, йөзек, беләзек, брошка, кулон, сәгать, чылбыр һ.б.) хәситәгә тезеп, тегеп куйсам, кешеләр миннән көләчәкләр – мактанчык! – дип. Аларның бит һәрберсенең кию урыны башка! Аннары ялгызың калгач, аны кию куркыныч та бит әле – тән сакчысы кирәк! Казанда Париж Коммунасы урамындагы “Эбиволь” кибетендә ука белән чигелгән, берничә генә асылташны уртага куеп, матур чәчәкләр чигелгән хәситәне дә күрдем. Матур, бәясе дә яхшы, сигез мең сум. Сулъяк иңбашыннан күкрәк аша уңга таба билгә кадәр үк төшкән. Ничә яшьлекләр өчен икәнен әйтә алмадылар, “акчаңа карап”, диделәр. Гатауллинның хәситәләре өстәрәк бетә, күкрәк астына кадәр генә иде. Чөнки Коръән-Кәримне билдән түбән йөртергә ярамый!

Хәситә киюне матурлык өчен һәм элек күз тиюдән, бозымнан, төрле авырулардан саклый, дип ышанганнар. Асылташларның шул үзенчәлекләрен искә алып кулланганнар. Ике йөз ел элек Казан тарихын өйрәнүче профессор Карл Фукс татар ирләренең хатыннарына өчәр мең сумлык хәситә алып бирүләрен язып калдырган. Эш атлары ул чорда 50–100 сум торса, хәситәнең бәясе хәзерге чәшке тун бәясе кебек булгандыр, әй?!

Нинди тукымадан тегәргә? – дигән сорауга җавап: бәрхет, парча яки ефәктән. Киеп йөргәндә формасын тотсын өчен эченә каты материал куеп калдырырга кирәк. Чөнки минем хәситәләрнең авырлыгы 300–500 граммга җитә.

Нинди төсне сайларга? Тапшыруда сылу кызлар киеп күрсәткән 6–7 хәситәнең күбесе кызгылт-сары төстә иде. Модага хәзерге караш белән “күлмәгем зәңгәр, хәситәм дә шундый булырга тиеш”, дигән сүз юк. Чөнки аны төрле күлмәк белән кияргә туры киләчәк. Күлмәге кызыл, камзулы зәңгәр, калфагы башка төсле булырга мөмкин. Киемдәге төсләрне бергә берләштерүче изүнең функциясе шунда: ул күкрәкнең ачык өлешен капларга, ә төсе киемдәге төсләрне берләштерергә тиеш. Гәрчә, мин аңлаганнары шулар. Берничә тапкыр күреп кенә бөтен нечкәлекләрен белеп тә, аңлап та бетереп булмый.

Кадерле милләттәшләрем, туташ-ханымнар! Югалып бөтенләй юкка чыкканчы, борынгы әниәбиләребезнең горурлыгы булган шушы хәситәне яңадан торгызыйк әле! Кызларыбызга күрсәтеп, өйрәтеп калдырыйк! Теләгебез булса, бу - безнең кулдан килә торган эш бит. Калфакны да бит башта белмәдек ничек, нинди итеп тегәргә, кая кияргә икәнен. Кем ука белән чигеп, кем сәйләннәр белән бизәп, кем аппликация ябыштырып ясадык һәм киябез бит! Әйе, үзебезчә камилләштердек, үзгәрттек. Мин үзем ковидтан сакланыр өчен кия торган маскаларымны да чигеп куйдым. Туймазыда татар үзәгендә күреп кайттым, ошаттым һәм чиктем. Хәситә ясау буенча милли киемнәребез белгечләреннән киңәшләр, ярдәмнәр көтәбез. Артист халкы да кия хәзер хәситәне. “Самар татарлары” журналында да бар хәситә киеп төшкән кызлар. “Сөембикә” журналы да читтә калмас, дип өметләнәм. Элек “Азат хатын” журналын-



Айсылбану Шәрипова нәсел шәҗәрәләре белән кызыксына.



Онычым Айселбану бәйрәмнәргә шулай киенергә ярата




Айсел дипломы >

да калфак-түбәтәйләр тегәргә өйрәтәләр иде бит.

Элеккеге әдәбиятта күз күргән, колакка ишетелгән сүз булса да, ни өчен аны бүгенгә кадәр беркем дә текмәгән һәм кимәгән соң? Бу сорауга җавап өлешчә сүз башында булган иде инде. 1930 елларда татар байларын, муллаларын, укымышлыларын сөргенгә озаткан вакытта аларның барлык байлыкларын талап калганнар. Татарстанда бик көчле булган ул экспроприация дигән нәрсә. Күрше чуаш, мукшы, керәшен халкының милли киемнәре чагыштырмача күбрәк сакланган. Шул вакытларда иң затлы, иң кыйммәтле кием һәм җиһазларны ярлы, надан халык үзләштергән. Ләкин аларны киеп барырлык урыннары һәм горурлыклары да булмау сәбәпле (кеше әйберенең кадере, бәрәкәте булмый бит!), алар таралып юкка чыккан, балалар уенчыгына әйләнеп югалган. Ә, бәлки, оялганнардыр сәләмә күлмәк өстеннән затлы хәситә кияргә?!

Бүгенге көндә үзем өчен хәситәнең иң кулай булган вариантын – чехлар бижутериясен кулланып эшләдем, чөнки алар олы кызымның сандыгында бар иде. Бәлки, дөрес тә түгелдер, әмма шунысы күңелемә якын булды. Сары төслектә сары металл начар күренгәнлектән, калфагым төсендәге зәңгәр бәрхетне сайладым. Зәңгәр камзулым һәм күлмәгем дә бар. Үзем киеп бетерә алмасам, кызларым бар. Бәлки, "әбием истәлеге", дип онычым Айселбану кияр. Чүлмәкчедән күрмәкче, дус кызым Минзифа да үзенә хәситә ясарга булды. Ул үзенә көмеш төсендәге ак металл эшләнмәләрен сайлады. Мөслимгә конференциягә һәм Сабан туена да икебез дә хәситә киеп бардык. Һәм иң кызыгы шунда: Казаннан килгән нумизматлар да бик кызыксынып, ошатып, килеп тотып карап, сорашып тордылар. Әстерхан шәһәреннән килгән Сабан туе кунаклары - ир-атлар да, хәситәне танып, сокланып яныбызга килделәр. Ә хатын-кызларны әйткән дә юк инде – каян табып була, сатмыйсызмы? - дип кызыксындылар, өлгесен алдылар. Иптәш кызымның авылда абыстай булып, Коръән укып йөрүче апасы да акчасы барын, хәситә кирәклеген каткат искәртте. Санкт-Петербургтан килгән «Ак калфак» кызлары да бик яраттылар хәситәне. Аларга хәситәне ничек ясарга кирәген видеога төшереп җибәрдем.

Әлмәттә Саҗидә Сөләйманова исемендәге үзәк китапханәгә мине хәситә ясау буенча остаханә уздырырга чакырдылар. Анда «Ак калфак» кызлары һәм әдәби марафончылар килгән иде. Ике сәгать буе аны ясау серләренә төшендердем: аның башы-азагында киңлеге - 5 см, уртасында - 12 см тирәсе. Озынлыгы - 40–50 см (буй озынлыгына карап), формасы яңа туган айга охшаган. 4–5–6 рәткә тезелгән бизәкләре өске рәттә ваграк, аска табан зураялар. Кызлар хәситә ясауны башыннан ук күрсеннәр өчен сары тафтадан яңа хәситә кисеп ясадым. Аны көмешсыман ак эшләнмәләр белән бизәдем. Алсу күлмәккә сары хәситә бик килешә икән.



Әлмәттә төбәкчеләр конференциясендә. 25.03.22.



Омскида «Каз өмәсе»н күрсәтәбез. 06.09.21.

Безнең татар хатын-кызлары гомергә матур киенергә яратканнар. Кат-кат балаитәкле матур күлмәк, затлы камзул, чигүле ак батист яулык, өрфия шәл, купшы калфак, изү, тезмә чәчкаплагыч, яка чылбыры, зеңгелдәп торган чулпылар – әллә каян ишетелеп торган хатын-кыз килүе. Ә хәзер нәрсә? Без күреп һәм киеп үскән балаитәкле ситсы күлмәк, чиккән алъяпкыч белән чөеп бәйләгән яулык әле ул татар кызларының эш киемнәре генә булган икән! Әйе, авылда кичке уеннарга шулай чыкканнар. Без шушы матур киемнәребез белән бергә хатын-кызның асыл сыйфатларын, нәфислеген һәм серлелеген дә югалтабыз түгелме, кызлар?! Үз кулларың белән тегеп, чигеп, үреп ясалган затлы эшләнмәләр кызларыбызга, оныкларыбызга да мирас булып калсын!

***На протяжении многих веков татары и чуваши живут бок о бок в мире и согласии. История и культура этих двух братских народов глубоко переплетена и взаимосвязана. Чуваши, как и татары, являются прямыми потомками волжских булгар. Сегодня этот дружный и трудолюбивый народ занимает пятую позицию по численности населения в нашей стране.***



# ПЕВЕЦ ИДЕАЛОВ И НРАВСТВЕННОСТИ

В нашем журнале мы достаточно часто рассказываем об истории и культуре народов России. На этот раз мы хотим познакомить вас с творчеством поэта, писателя и композитора, председателя Русского отделения Союза писателей Чувашской Республики Анатолия Николаевича Аринина. Поводом для этого послужило также и то, что совсем недавно Анатолий Николаевич был награжден медалью «За труды в культуре и искусстве» за вклад в развитие отечественной культуры и многолетнюю плодотворную деятельность. Эту медаль на торжественной церемонии в Большом театре ему вручила министр культуры Российской Федерации Ольга Любимова.



Анатолий Аринин является создателем и руководителем многих общественных организаций: ВИА «Данс-рок-капелла», Академии нравственности, Комитета творческих инициатив, членом Ассоциации композиторов Чувашской Республики. Много лет он бескорыстно помогает молодому поколению в реализации их талантов, а также ведет социально полезную и благотворительную деятельность по всей России, в том числе провел множество культурных мероприятий и в нашей Самарской области.

